Татарстанда
# ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ
№1 МАРТ 2018
МЕСТНОЕ САМОУПРАВЛЕНИЕ В ТАТАРСТАНЕ
ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ П2268



## СТАРТ БИРЕЛДЕ!
38 бит

*Татарстанда*
# ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ
**МЕСТНОЕ САМОУПРАВЛЕНИЕ В ТАТАРСТАНЕ**

№1, март 2018
Мәгълүмати-аналитик, иҗтимагый-сәяси басма

**БАШ МӨХӘРРИР**
Нияз Равильевич ӘХМӘДУЛЛИН, e-mail: redaktorms@gmail.com

**БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЫ**
Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ

**ЧЫГАРЫЛЫШ МӨХӘРРИРЕ**
Фәридә ӘХМӘТҖАНОВА

**АВТОРЛАР**
Резеда Вәлиева, Вахит Шәрипов

**ФОТОГРАФ**
Андрей Титов

**ВЕРСТКА**
Евгений Курьянов

**КОРРЕКТОР**
Айсылу Корманова

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт Идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү турындагы таныклык ПИ №ТУ 16-00621, 29.09.2011.

Журнал татар һәм рус телләрендә нәшер ителә.
Гомуми тираж: 3 166 данә

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстанда җирле үзидарә» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

**РЕДАКЦИЯ:**
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2нче йорт
Тел.: (843) 293-60-15

«Печатный двор» ҖЧҖ типографиясендә басылды.
Казан ш., Мөхәммәдьяров ур.,31
Заказ № А-215Т
Офсет басма
Басарга кул куелды: 21.03.2018
Басылып чыгу датасы: 28.03.2018

16+

**Гамәлгә куючы һәм нәшер итүче:**
**«Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе, 420014, Татарстан Республикасы, Казан, Кремль**

# ЭЧТӘЛЕК



*РЕСПУБЛИКА муниципаллары форумы* **8 БИТ**



*КИЛӘЧӘККӘ юнәлтелгән бурычлар* **14 БИТ**



*ҖИРЛЕ хакимият: илебез тәҗрибәсе* **18 БИТ**

**РЕДКОЛЛЕГИЯ:**
РӘИС –
**Әгъзам Самат улы Гобәйдуллин** – «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе рәисе

**Андреева Людмила Николаевна** – Казан шәһәр Думасы секретаре

**Белов Александр Николаевич** – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департамент җитәкчесе

**Воропаева Татьяна Васильевна** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе урынбасары

**Гарипов Илнур Мәхмүтович** – ТР Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары – ТР Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы

**Гусева Любовь Акимовна** – сәясәт фәннәре кандидаты, КФУның дәүләт һәм муниципаль идарә кафедрасы доценты

**Ратникова Римма Атласовна** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары

**Хәбибуллин Альберт Галимҗанович** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе



*Илсур МЕТШИН: «Казан – киләчәк драйверы»*
**24 БИТ**

*БАШКАЛА: бүген һәм иртәгә*
**28 БИТ**






*ТАТАРСТАН саннарда*
**32, 46, 52 БИТ**

*АЛГАРЫШЛЫ үсешкә ия кала*
**34 БИТ**





*ПРЕЗИДЕНТ белән бер көн*
**38 БИТ**

*АСИҮТ формуласы*
**40 бит**





*КЕЧКЕНӘ дә төш кенә*
**48 БИТ**

*БИЕКТАУ климаты: эшлекле һәм актив*
**54 БИТ**





*ҖИРЛЕ хакимият: проблемалар һәм чишелешләр*
**58 БИТ**

*КАНУН яңалыклары*
**60 БИТ**






## МУНИЦИПАЛЬ СОВЕТ ПРЕЗИДИУМЫ УТЫРЫШЫ

14 февральдә Казанда ТР Муниципаль берәмлекләре Советының быелгы беренче утырышы булып узды. Чарада ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТРның беренче вице-премьеры Рөстәм Нигъмәтуллин, ТР Куркынычсызлык советы секретаре Айрат Шәфигуллин, ТР Президент Аппаратының, ТР Дәүләт Советының, ТР Министрлар Кабинетының, министрлык һәм ведомстволарның җаваплы хезмәткәрләре, муниципаль район һәм шәһәр округлары башлыклары урынбасарлары катнашты. Президиум эше традицион рәвештә видеоконференция режимында, урыннарда район башкарма комитетлары һәм шәһәр округлары, шәһәр һәм авыл җирлекләре җитәкчеләре катнашында алып барылды.

Утырышны ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Әгъзам Гобәйдуллин үткәрде. Утырышта катнашучылар дүрт төп мәсьәләне карадылар, аларны тикшерү республиканың барлык муниципалитетларының катнашуын таләп итте. Төп мәсьәләләр арасында: ТР муниципаль районнарында һәм шәһәр округларындагы торак секторларында видеокүзәтү системаларын урнаштыру һәм тәэмин итү; Гаиләгә теләктәшлек үзәген булдыру проекты; «Эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына карата муниципаль контрольне камилләштерүнең «юл картасы» чаралары планы; ТР Муниципаль берәмлекләре Советы эмблемасы проекты.

Муниципалитетларда видеокүзәтү системаларын урнаштыру мәсьәләсендә ТР төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Алексей Фролов чыгыш ясады. Аның мәгълүматы буенча, 2015 елдан башлап, республикада 193 миллион сумга 1180 камера урнаштырылган. Камераларга ел буена хезмәт күрсәтү бәясе якынча 91 млн сум тәшкил итә. Күп фатирлы 13 235 йортның (өч катлы һәм аннан күбрәк) 4 595е видеомониторинг системалары белән тәэмин ителгән, йорт яны территорияләрендә 14 011 видеокамера урнаштырылган. Видеомониторинг системалары белән Актаныш һәм Сарман районнарының күпфатирлы йортлары – 100 %ка, Бөгелмә районы – 91,5 %ка, Азнакай районы – 83 %ка, Нурлат һәм Баулы районнары 70 %тан артыграк ка тәэмин ителгән. Спас (1,3 %) һәм Минзәлә (0,58 %) районнары аутсайдер булып тора. Утырышта катнашучылар видеокүзәтү системаларын урнаштыру һәм аларны тәэмин итү өчен түләүне оешмалар балансына кую мәсьәләсен тикшерделәр. Ахыр чиктә вазгыятьне өстәмә рәвештә өйрәнергә, урыннардан килгән тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм аны агымдагы елның беренче кварталы ахырында кабат тикшерергә карар иттеләр.

Муниципаль контроль буенча чаралар планын («Юл картасы») ТР икътисад министры урынбасары Айрат Шәмсиев бәян итте. План 2018 елда республика җирле үзидарә органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата тормышка ашырылырга тиешле чараларны күздә тота.

Президиум әгъзалары, муниципалитетлар һәм дәүләт хакимияте органнары вәкилләре тикшерелә торган мәсьәләләрне үз форматларында ничек күзаллаулары белән уртаклаштылар. Эш нәтиҗәләре буенча Президиум муниципаль хакимият органнарына туры килә торган тәкъдимнәрне күздә тоткан карарлар кабул итте.

## УЗГАН ЕЛ САБАКЛАРЫ

Республикада гыйнвар-февраль айларында муниципаль берәмлекләрнең йомгаклау сессияләре булып узды, аларның барышында депутатлар шәһәр һәм районнарның узган елгы үсешенә нәтиҗәләр ясадылар. Муниципаль совет сессияләре киңәйтелгән составта, Татарстан Республикасы җитәкчелеге, республика министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре, дини һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре катнашында уза. Муниципаль хакимият органнарының социаль-икътисадый үсеш, федераль һәм республика программаларын тормышка ашыру өлкәсендәге эш нәтиҗәләренә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Премьер-министры Алексей Песошин, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Премьер-министр урынбасарлары бәя бирде. Йомгаклау сессияләре эшендә шулай ук ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Әгъзам Гобәйдуллин актив катнашты.

Мәсәлән, 7 февральдә Әлмәт муниципаль районы Советы утырышы булды. Утырышта катнашкан ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов болай дип билгеләп үтте: «Без Әлмәтнең ролен һәм әһәмиятен республиканың нефть башкаласы буларак күрәбез. Барыннан да элек, бу «Татнефть» компаниясе һәм кече нефть компанияләре. Безнең барлык төп программалар, исәпләп карасаң, нефть комплексының, нефть сәнәгатенең тотрыклы эшләве нәтиҗәсендә тормышка ашырыла». Шәһәр һәм район үсешен югары бәяләп, республика башлыгы шул ук вакытта кимчелекләргә дә игътибар итте, алар арасыннан авыл хуҗалыгындагы, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендәге түбән нәтиҗәләрне билгеләп үтте. «Сәламәтлек саклау мәсьәләсендә сез муниципаль районнар арасында 9 нчы позициядә, ә гражданнарның канәгатьлеге ягыннан 40 нчы позициядә торасыз, – диде Татарстан Президенты. – Әлбәттә, монда кешеләр таләпчәнрәк карый. Сәламәтлек саклауда хәл башка урыннардагыга караганда күпкә яхшырак. Әмма белгечләр кирәк, хастаханә биналары гына түгел. Медицина учреждениеләрендә квалификацияле табиблар булырга тиеш». Белем бирү өлкәсендә район республикада 19 нчы урында тора. Рөстәм Миңнеханов район




җитәкчелеген әлеге юнәлешләргә аеруча зур игътибар юнәлтергә чакырды.

Шушы ук көндә Бөгелмә районы Советы утырышы булды. Тормыш дәрәҗәсе һәм гомуми белем бирү сыйфаты буенча Бөгелмә районы Татарстанда әйдәп баручы буларак танылган, дип билгеләп үтте ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов депутатлар алдында чыгыш ясаганда. Шул ук вакытта ул сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү зарурлыгына игътибар итте. Бөгелмәдә үзәк район хастаханәсе һәм балалар йогышлы авырулары хастаханәсе биналары ремонт таләп итә. Рөстәм Миңнеханов район өчен әһәмиятле булган әлеге ике сәламәтлек саклау объектын яңартырга ярдәм итү мөмкинлеген карарга кушты. Бөгелмә районының авыл хуҗалыгында зур потенциалы бар, дип басым ясады Татарстан Президенты, әмма ул тиешенчә тормышка ашырылмый. «Сездә тәүлеклек тулай сөт саву күләме нибары 23 тонна тәшкил итә. Бу күрсәткечләре моннан 10



тапкырга артыграк районнар бар», – дип белдерде ул һәм район җитәкчелеген әлеге мәсьәләләргә игътибар итәргә чакырды.



## КӨНДӘШЛЕКЛЕ ӨСТЕНЛЕКЛӘР

Ютазы муниципаль районы Советы сессиясендә ТР Премьер-министры Алексей Песошин катнашты. Ютазы районының көндәшлекле өстенлекләре турында сөйләгәндә, Алексей Песошин, сату базарлары буларак, күрше төбәкләрнең, эре торак пунктларның (Октябрь, Туймазы) якынлыгын; уңайлы транспорт һәм тимер юл инфраструктурасын; үсештә булган сәнәгатен күрсәтте. Моннан тыш, районда яңа перспективалы предприятиеләр пәйда булган, ә мондый җитештерүләрнең булуы – яңа эш урыннары, тотрыклы хезмәт хакы, җирле бюджетка салым керемнәре дигән сүз.

Премьер-министр шулай ук райондагы проблемалы мәсьәләләргә дә тукталды. Мәсәлән, ул терлекчелекне үстерү темпларын тизләтү зарурлыгына игътибар итте – 2017 елда районда МЭТнең баш саны кимүе күзәтелгән. Предприятиеләр һәм физик затларның салым түләүләре буенча бурычлары барлыгын билгеләп үтте. Узган ел башы белән чагыштырганда, бурычларның күләме 53 процентка арткан һәм 15 млн сумнан артыграк сумманы тәшкил иткән, аның 10 миллионы – физик затларның милек салымнары. «Салым бурычлары белән начар эшләү – бу куелган бурычларны үтәүне куркыныч астына кую, – дип ассызыклады Алексей Песошин. – Салым хезмәте һәм башка хезмәтләр белән бердәм рәвештә актив эшләүне дәвам итү зарур».

Фотолар www.tatarstan.ru сайтыннан алынды.

## ХАЛЫК ҖЫЕЛЫШЛАРЫ

Ел башы – республиканың авыл җирлекләрендә традицион гражданнар җыелышларын үткәрү чоры. Аларда катнашучылар узган ел башкарылган эшләр турында җирлек башлыгының хисабын тыңлау, киләчәккә планнар белән танышу, сораулар бирү һәм тәкъдимнәр кертү, хакимият вәкилләре белән бәхәскә керү мөмкинлегенә ия. Гражданнарның хакимият эше турындагы фикерләрен ачыклый торган мондый форматка республика җитәкчелегенең игътибарын күрсәтүче әһәмиятле момент – халыкның бөтен таләпләре һәм тәкъдимнәре турында беркетмә алып барыла һәм алга таба район һәм республика дәрәҗәсендә анализлау өчен гомумиләштерелә.

Җирлек башлыкларыннан тыш, халык белән очрашуларда, һичшиксез, җирлек һәм район советлары депутатлары, муниципаль район башлыклары һәм урынбасарлары, башкарма комитетларның җитәкчеләре һәм урынбасарлары, ТР Дәүләт Советы депутатлары, республика министрлыклары һәм ведомстволарының җаваплы хезмәткәрләре, идарәче компанияләрнең, муниципаль предприятиеләрнең, ТИҮ җитәкчеләре һ.б. катнаша. Гражданнар җыелышлары асылда хакимиятнең гражданнар белән турыдан-туры элемтәсенең бер формасы булып тора. Халык аеруча еш күтәрә торган мәсьәләләр – авыл һәм бистәләр эчендә юллар төзү, яшь белгечләрне торак белән тәэмин итү, эш урыннары булдыру, территорияләрне яхшырту һ.б.га кагыла.





## ТУКАЙ ОФЫКЛАРЫ

15 февральдә депутатларның Тукай районы Советының хисап сессиясе булды, аның эшендә ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Әгъзам Гобәйдуллин, республика парламенты депутатлары катнашты.

Тукай районы республикада муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеше рейтингында дүртенче урынны били һәм авыл районнары арасында әйдәп баручы булып тора. Районда узган ел сәнәгать һәм агросәнәгать комплексының динамик үсешен чагылдырган лаеклы күрсәткечләр белән билгеләп үтелгән.

Тукай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Фаил Камаев районның узган елгы үсеш нәтиҗәләрен «тотрыклы» дип сыйфатлады: «Эшсезлек дәрәҗәсе 0,54% тәшкил итә, бу 2017 ел башындагы күрсәткечләрдән түбәнрәк. Предприятиеләрдә массачыл кыскартулар һәм эштән азат итүләр күзәтелми. Безнең бурыч – лаеклы хезмәт хакы түләнгән эш урыннарын саклап калу һәм арттыру».



Сессиягә йомгак ясап һәм Тукай районы үсешенең яңа офыкларын билгеләп, Фәрит Мөхәммәтшин тукайлыларның эш нәтиҗәләрен югары бәяләде. Аның фикеренчә, бүген район «хәрәкәттә», күрсәткечләренең төп критерийлары буенча – алдынгы позицияләрдә. Шуңа да карамастан, хәл итүне сораган мәсьәләләр дә бар. Аерым алганда, Тукай районы автоградка бик якын торганлыктан, инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр белән тәэмин ителергә тиешле яңа торак территорияләре барлыкка килеп тора. Кайбер эре авыл җирлекләрендә канализация челтәрләре шул дәрәҗәдә тузган, аларны тулысынча алыштыру яисә модернизацияләү таләп ителә. «Сөт саву күләмен һәм сөт продукцияләрен җитештерүне арттыру белән бәйле мәсьәләләр дә бар, алар район өчен актуаль». «Гомумән алганда, район, эш дәвамында, шул исәптән, Яр Чаллы җитәкчелеге белән тыгыз хезмәттәшлек итеп, үз территориясен үстерү өчен яхшы мөмкинлекләргә ия», – дип басым ясады Фәрит Мөхәммәтшин.

## ЯҢА ВАЗЫЙФАЛАРГА БИЛГЕЛӘНҮЛӘР

### ГЫЙНВАР-ФЕВРАЛЬ АЙЛАРЫНДА РЕСПУБЛИКАНЫҢ ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ХАКИМИЯТЛӘРЕ СТРУКТУРАЛАРЫ КАДРЛАРЫ БУЕНЧА ҮЗГӘРЕШЛӘР БУЛДЫ. БИШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНДА ҺӘМ РЕСПУБЛИКАНЫҢ ДҮРТ МИНИСТРЛЫГЫНДА ҖИТӘКЧЕЛӘР АЛЫШЫНДЫ.

• 17 гыйнварда Балык Бистәсе муниципаль районы Советы сессиясендә район башлыгы Илһам Вәлиев отставкага китте. Шулай ук районның Башкарма комитеты җитәкчесе Рашат Хәбибуллин да вазыйфаларыннан азат ителде. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча ТР Премьер-министры Алексей Песошин Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын моңа кадәр «Алабуга» Махсус икътисадый зонасы» АҖнең генераль директоры урынбасары булып эшләгән Илдар Таҗетдиновка йөкләү турындагы тәкъдимен кертте. Депутатлар әлеге тәкъдимне хуплады.



**ИЛДАР РӘШИТ УЛЫ ТАҖЕТДИНОВ, ТР БАЛЫК БИСТӘСЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ.**

1977 елның 1 октябрендә ТАССРның Балык Бистәсе районында туган. Казан финанс-икътисад институтын, Казан дәүләт университетын тәмамлаган, икътисадчы, юрист. Икътисад фәннәре кандидаты.

ТР Инвестицион үсеш агентлыгы, ТРның Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитеты рәисенең беренче урынбасары, «Алабуга» МИЗ» АҖ генераль директорының эксплуатацияләү буенча урынбасары булып эшләгән. Хәзерге вакытта – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе.

• Питрәч муниципаль районы Советының 17 гыйнварда узган чираттан тыш утырышында район башлыгы Эдуард Дияров вазыйфаларыннан азат ителде. Ул бу вазыйфада биш ел дәвамында эшләгән иде.
«Депутатлар корпусының кадрлар составын игътибар белән өйрәнгәннән соң, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов миңа Питрәч районы башлыгы вазыйфасына Илһам Кәшәповны сайлау тәкъдимен депутатлар хөкеменә тапшырырга кушты», – дип хәбәр итте ТР Премьер-министры Алексей Песошин. Хөкүмәт башлыгы Ленино-Кокушкино авыл җирлегеннән Питрәч Советы депутаты булган Илһам Кәшәповның шушы районда туып-үсеп билгеләп үтте. 17 елдан артык район предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләгән. Совет депутатлары тавыш бирү юлы белән Илһам Кәшәпов кандидатурасын хупладылар һәм районның яңа башлыгын сайладылар.



**ИЛҺАМ МИҢНЕХАН УЛЫ КӘШӘПОВ, ТР ПИТРӘЧ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ.**

1972 елның 13 апрелендә ТАССРның Питрәч районы Ленино-Кокушкино авылында туган. Мәскәү ветеринария академиясен тәмамлаган. Авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты.

«Казан» кошчылык фабрикасы» ААҖ директорының урынбасары һәм беренче урынбасары, «Ак Барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖнең генераль директоры, «Ак Барс» «Кошчылык комплексы» ҖЧҖнең Яшел Үзән җитештерү мәйданчыгының директоры булып эшләгән. 2018 елның гыйнварыннан – ТР Питрәч муниципаль районы башлыгы.

• 8 февральдә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов яңа министрлар билгеләү турында Указларны имзалады. ТР урман хуҗалыгы министры итеп Нурлат муниципаль районының элекке башлыгы Равил Кузюров билгеләнде.



**РАВИЛ АФРАИМ УЛЫ КУЗЮРОВ, ТР УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЫ.**

1973 елның 9 гыйнварында ТАССРның Аксубай районы Аксубай бистәсендә туган. Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясендә «инженер-төзүче-технолог» белгечлеген алган. Шәхси эшкуар, Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль заказ хезмәте» МУПнең генераль директоры, Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы, Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, ТР Президентының территорияләр белән

Фотолар www.tatarstan.ru сайтыннан алынды.


эшләү идарәсенең баш киңәшчесе, ТР экология һәм табигать ресурслары министрының инвестицияләр һәм инновацияләр эшчәнлеге буенча урынбасары, ТР Нурлат муниципаль районы башлыгы булып эшләгән. 2018 елның февраленнән – ТР урман хуҗалыгы министры.



**АЛМАЗ СӘЛИМ УЛЫ ӘХМӘТШИН, ТР НУРЛАТ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ.**


Нурлат муниципаль районы Советының 7 февральдә үткән сессиясендә районның Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы итеп Алмаз Сәлим улы Әхмәтшин расланды. Алмаз Әхмәтшин 1967 елның 11 мартында Нурлат районының Биккол авылында туган. 2010–2016 елларда ТР төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрының урынбасары булып эшләгән. 2016–2018 елларда «Энергопрогресс» инженерлык үзәгенең генераль директоры булып хезмәт иткән.

• Татарстанның экология һәм табигый ресурслар министры итеп Александр Шадриков билгеләнде. Моңа кадәр ул республиканың Чүпрәле муниципаль районы башлыгы вазыйфасын биләгән.



**АЛЕКСАНДР ВАЛЕРЬЕВИЧ ШАДРИКОВ, ТР ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАР МИНИСТРЫ.**


1977 елның 1 гыйнварында туган. Казан педагогика институтын тәмамлаган, физика һәм информатика укытучысы. Чуваш дәүләт университетында «юрист» белгечлеген алган. Саклык банкының Чүпрәле бүлекчәсендә – инженер-программист, ТР Икътисад һәм сәнәгать министрлыгының Чүпрәле районындагы икътисад бүлеге башлыгы, Чүпрәле районы Техник инвентарьлаштыру бюросы башлыгы, ТР Чүпрәле районы башлыгы урынбасары, Ульяновск шәһәренең Засвияжск районы хакимияте башлыгы урынбасары һәм башлыгы, ТР Чүпрәле районы башлыгы булып эшләгән. 2018 елның февраленнән – ТР экология һәм табигый ресурслар министры.



**МАРАТ РИНАТ УЛЫ ГАФАРОВ, ТР ЧҮПРӘЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ.**

Марат Ринат улы Гафаров 1977 елның 2 апрелендә ТАССРның Яшел Үзән районы Карашәм авылында туган. Казан финанс-икътисад институтында укып, «икътисадчы» белгечлеге алган. ТР Дәүләт Советы Аппаратында, ТР Президенты Аппаратында эшләгән, Нурлат районы хакимияте башлыгы урынбасары, Нурлат, Азнакай, Балык Бистәсе районнарының Башкарма комитетлары җитәкчесе, ТР хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары булган. 2018 елның февраленнән – ТР Чүпрәле районының Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы, җитәкчесе.


• 8 февральдә ТР Премьер-министры Алексей Песошин Икътисад министрлыгы коллективына яңа җитәкчесен – моңа кадәр ТР экология һәм табигый ресурслар министры булып эшләгән Фәрит Габделганиевны тәкъдим итте. 2014 елдан бирле ТР Икътисад министрлыгы башлыгы вазыйфасында эшләгән Артем Здунов алдагы көнне Дагыстан Республикасы Хөкүмәте рәисе итеп билгеләнде.



**АРТЁМ ЗДУНОВ, ДАГЫСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХӨКҮМӘТЕ РӘИСЕ.**

ТР Премьер-министры элекке министрның казанышларын билгеләп, алар арасында кече һәм урта бизнесны үстерү программаларын, бизнеска булышлык итү өчен инфраструктур объектлар булдыру һәм аларны үстерү, республика шәһәрләренең АСИҮТ статусы алуларын аерып күрсәтте. Хөкүмәт башлыгы республиканың Стратегия-2030 эшләнүен, федераль үзәк белән конструктив мөнәсәбәтләр урнаштыруны искә алды. «Республика шушы вакыт эчендә шактый ташламалар һәм акчалар алды, бу безгә икътисадый потенциалны күтәрергә мөмкинлек бирде», – диде Алексей Песошин.

Фәрит Габделганиевны котлап, ул биргәләп эшләгәндә генә перспективалы проект һәм программаларны тормышка ашырып була, дип ассызыклады.



**ФӘРИТ СОЛТАН УЛЫ ГАБДЕЛГАНИЕВ, ТР ИКЪТИСАД МИНИСТРЫ.**

1976 елның 13 мартында туган. Казан финанс-икътисад институтын, Россия халыклар дуслыгы университетын тәмамлаган. Казан шәһәре Башкарма комитетының икътисадый үсеш комитеты рәисе урынбасары, Универсиада Авылы мэры, «2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасының башкарма дирекциясе» АКБОның генераль директоры урынбасары, ТР экология һәм табигый ресурслар министры булып эшләгән. 2018 елның февраленнән – ТР икътисад министры.


• 14 февральдә ТР Президенты Указы белән ТР сәламәтлек саклау министры Гадел Вафин вазыйфасыннан азат ителде. Әлеге вазыйфага моңа кадәр Казанның 7 нче клиник хастаханәсендә баш табиб булып эшләгән Марат Садыйков билгеләнде.



**МАРАТ НАИЛ УЛЫ САДЫЙКОВ, ТР СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЫ.**

1970 елның 27 гыйнварында Буа шәһәрендә туган. Казан дәүләт медицина институтында «педиатрия» белгечлеген алган. Медицина фәннәре кандидаты. КДМУның дәваханә педиатриясе кафедрасы ассистенты, 18 нче шәһәр клиник хастаханәсенең баш табибы урынбасары, Казан онкология диспансерының баш табибы, 7 нче шәһәр клиник хастаханәсенең баш табибы булып эшләгән.

• 20 февральдә ТР Дәүләт Советы депутатлары ТР Президенты ярдәмчесе Ләйлә Фазлыеваның кандидатурасын ТР Премьер-министры урынбасары вазыйфасына расладылар. Яңа вице-премьер социаль өлкәне кайгыртачак, социаль өлкәнең эшләве мәсьәләләре буенча хөкүмәт комиссияләренең эшләрен координацияләячәк.



**ЛӘЙЛӘ РИНАТ КЫЗЫ ФАЗЛЫЕВА, ТР ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЫ УРЫНБАСАРЫ.**

1975 елның 29 маенда Кыргызстанның Кант районы Кант бистәсендә туган. 1997 елда Казан дәүләт университетын тәмамлаган (филолог, рус теле һәм әдәбияты укытучысы). Урта белем бирү системасында эшләгән. 2007–2011 елларда – Казанның Совет районы хакимияте башлыгы урынбасары, 2011–2014 елларда – Казан Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары. 2014 елның октябреннән – ТР Президенты ярдәмчесе.

• 22 февральдә ТР Алексеевск районы Советының сессиясе булды. Анда район башлыгы Владимир Козонков, ТР Муниципаль берәмлекләре Советына эшкә күчү сәбәпле, үз теләге белән вазыйфасыннан азат ителде. Районның Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы итеп Сергей Демидов расланды, моңа кадәр ул ТР җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгының беренче урынбасары булып эшләде.



**СЕРГЕЙ АНАТОЛЬЕВИЧ ДЕМИДОВ, ТР АЛЕКСЕЕВСК РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ.**

1978 елның 1 гыйнварында ТР Лаеш районының Никольское авылында туган. «Юриспруденция» белгечлеге буенча – Казан дәүләт университетын, «маркетинг» белгечлеге буенча Икътисад, идарә һәм хокук институтын (Казан шәһәре) тәмамлаган. 2005–2009 елларда –



**КОЗОНКОВ ВЛАДИМИР КОНСТАНТИНОВИЧ, ТР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫ РӘИСЕ УРЫНБАСАРЫ.**

ТР Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгының күчемсез милек идарәсе башлыгы, 2009 елдан – урынбасар, ә 2012 елдан ТР җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгының беренче урынбасары.



# РЕСПУБЛИКА муниципаллары форумы

**РЕСПУБЛИКА МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕНЕҢ УЗГАН ЕЛ АЗАГЫНДА ҮТКӘН ЧИРАТТАГЫ XII СЪЕЗДЫНДА ТР МУНИЦИПАЛЬ БЕРГӘЛЕГЕНЕҢ 2017 ЕЛДАГЫ ЭШ НӘТИҖӘЛӘРЕ ҺӘМ 2018 ЕЛГА БУРЫЧЛАР КАРАЛДЫ. АСЫЛДА, МУНИЦИПАЛЛАР ҮЗ СӘГАТЬЛӘРЕНЕҢ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ БЕЛӘН ДӨРЕСЛЕГЕН ТИКШЕРДЕ. НӘТИҖӘ КАНӘГАТЬЛӘНЕРЛЕК БУЛЫП ЧЫКТЫ: СӘГАТЬЛӘР СИНХРОН ЙӨРИ. ФОРУМ ДЕЛЕГАТЛАРЫ БЫЕЛГЫ ЭШ ПЛАНЫН ДА ШУҢА ЯРАШЛЫ БИЛГЕЛӘДЕ.**

Казанда үткән зур форумга республика муниципалитетлары башлыкларының күпчелеге (956 башлыкның 946 сы) килде. Традиция буенча, съездда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Премьер-министры Алексей Песошин, министрлык һәм ведомстволар, предприятие һәм оешмалар җитәкчеләре, ТР парламенты һәм РФ Дәүләт Думасындагы Татарстан депутатлары, территориаль иҗтимагый үзидарә советлары хәрәкәте, төрле иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре катнашты. Делегатлар һәм чакырылган кунаклар саны, катнашучыларның статусы буенча муниципаль берәмлекләр съезды, мөгаен, республикадагы иң күләмле иҗтимагый-сәяси чара булып торадыр.

Съездның беренче өлешендә делегатлар оешты-ру мәсьәләсе буенча карар кабул итте. ТР Муниципаль








**Мандат комиссиясе докладыннан: «Татарстан Республикасында 2 шәһәр округы, 43 муниципаль район, 39 шәһәр җирлеге (шул исәптән 22 шәһәр, 17 шәһәр тибындагы бистә), 872 авыл җирлеге бар. Шул рәвешле, Татарстан Республикасында 956 муниципаль берәмлек исәпләнә. Муниципаль берәмлекләрдән XII съездга 946 делегат килде. Съезд делегатлары арасында 27 муниципаль берәмлек башлыгына әле 30 яшь тулмаган, 326 башлык җирле үзидарә органнарында төрле вазыйфаларда 10 елдан артык эшләгән, 6 башлык инде 25–30 ел, 3 башлык 30 елдан артыграк муниципаль берәмлек белән җитәкчелек итә».**

берәмлекләре Советының элеккеге рәисе, оешманы 2006 елдан бирле җитәкләгән Минсәгыйть Шакиров вакытыннан алда үз вәкаләтләреннән баш тартты. Советның яңа рәисе итеп ТР Тәтеш муниципаль районының Олы Шәмәк авыл җирлегеннән депутат Әгъзам Гобәйдуллин сайланды. Аны сайлау турында карарны делегатлар бертавыштан кабул итте.





**Әгъзам Самат улы Гобәйдуллин, «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе рәисе**

ТАССРның Чүпрәле районы Иске Кәкерле авылында туган. 1975 елда – Н.Э.Бауман исемендәге Казан ветеринария институтын, 2009 елда РФ Президенты каршындагы Россия дәүләт хезмәте академиясен тәмамлаган.

1975 ел – ТАССРның Югары Ослан районы «Ленин байрагы» совхозы баш зоотехнигы. 1975–1976 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1976–1981 елларда – Яшел Үзән районы «Комсомолец» колхозы баш зоотехнигы. 1981–1986 елларда – Яшел Үзән районы «Искра» колхозы рәисе. 1986–1991 елларда – Яшел Үзән районы агросәнәгать берләшмәсе рәисе. 1991–1992 елларда – Яшел Үзән авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы. 1992–1995 елларда – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары, беренче урынбасары. 1995–1998 елларда – ТР Мамадыш районы хакимияте башлыгы. 1998–2005 елларда – ТР Президенты Аппараты җитәкчесе. 2005–2012 елларда – Россия Федерациясе Федераль Җыены Федерация Советы әгъзасы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы вәкиле. 2012–2017 елларда – ТР Үзәк сайлау комиссиясе рәисе. 2017 елның 12 сентябреннән – ТР Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлеге советы депутаты.

2017 елның 21 декабрендә «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе рәисе итеп сайланган.

ТР Спорт көрәше федерациясе президенты. Авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, биология фәннәре кандидаты.

***«Социаль объектлардан нәтиҗәле файдалану һәм вакыйгаларда катнашу активлыгын арттыру җирле үзидарә органнарының төп бурычы булып тора. Безнең бүгенге эшләребезнең барысы да – спорт мәйданчыклары төзү, җәмәгать урыннары булдыру – әлеге территориядә яшәүчеләргә хезмәт итәргә тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Республика программалары территорияләрне үстерү бурычларын системалы хәл итүгә, шулай ук объектларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең, яшәү урыннарына бәйсез рәвештә, барлык гражданнар өчен дә уңайлы булуын тәэмин итүгә юнәлтелә».***

ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе сыйфатында тәүге чыгышында Әгъзам Гобәйдуллин республика муниципалларына үзенә ышаныч күрсәтүләре өчен рәхмәтен җиткерде һәм Татарстанда җирле үзидарә системасын киләчәктә дә камилләштерү өчен бөтен көчен куячагына ышандырды.

Яңа җитәкче алда торган төп бурычларны да атап китте – муниципаль берәмлекләрнең, җирле үзидарә вазыйфаи затларының һәм хезмәткәрләренең мәнфәгатьләрен яклау, муниципаль берәмлекләр үсешенә булышу, проблемалы мәсьәләләрне хәл итү һәм халыкның тормыш сыйфатын яхшырту.

Әгъзам Гобәйдуллин: «Республикадагы җирле үзидарә системасы үз алдына куелган бурычларны уңышлы хәл итәргә сәләтле. Мин моны яхшы беләм, чөнки җирле хакимият органнарында эшләү һәм муниципаль берәмлекләрнең проблемалары миңа таныш. Бүгенге съездның күп кенә делегатлары һәм кунаклары белән без үз вакытында җирле советлар системасыннан җирле

***ТР Премьер-министры Алексей Песошин чыгышында республиканың социаль-икътисадый үсешенә, муниципаль берәмлекләр территорияләрендә республика программаларын гамәлгә кертү барышына тәфсилле анализ бирелде. Хөкүмәт башлыгы әйтүенчә, шәһәр округлары һәм муниципаль районнарның 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеше стратегияләре белән беррәттән, барлык муниципалитетларда җирлекләрнең үсеш планнары расланган. Алар «Стратегия-2030» республика планының аерылгысыз өлеше булып тора һәм максат-бурычлары да уртак.***

үзидарә системасына кучүдә турыдан-туры катнашкан идек. Татарстан җитәкчелеге һәм шәхсән Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның муниципаль берәмлекләр мәсьәләсенә күрсәткән игътибары һәм ярдәме республикабыздагы җирле үзидарәнең уңышлы эшләве өчен иң мөһим фактор булып тора, дип саныйм», – дип, үз фикерен белдерде.

Ул шулай ук форум делегатларының игътибарын республикадагы дәүләт һәм муниципаль хакимиятләрнең үзара хезмәттәшлегенең югары сыйфатлы булуына да юнәлтте. Әгъзам Гобәйдуллин фикеренчә, ирешелгән дәрәҗә күтәрелә барырга тиеш, бу муниципаль берәмлекләрнең «Татарстан Республикасының 2030 елга кадәрге социаль-икътисадый үсеше стратегиясен»дә катнашуына, өстәмә икътисадый зоналар, кластерлар, субкластерлар һәм алгарышлы үсеш территорияләре булдырылуга бәйле.

Аннары съезд делегатлары ТР җирле үзидарә системасы үсешен анализлау, уңай тәҗрибә алмашу һәм киләчәккә төп бурычларны билгеләү буенча эшен дәвам итте. Съездда катнашучылар каршында ТР Премьер-министры Алексей Песошин, ТР вице-премьеры, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов, Казан мэры Илсур Метшин, Бөгелмә муниципаль районы башлыгы Линар Закиров, Чүпрәле муниципаль районы башлыгы Александр Шадриков, Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Фәрит Садриев, Баулы муниципаль районы Новозареченск авыл җирлеге башлыгы Светлана Багижева чыгыш ясады.



ТР Премьер-министры Алексей Песошин чыгышында республиканың социаль-икътисадый үсешенә, муниципаль берәмлекләр территорияләрендә республика программаларын гамәлгә кертү барышына тәфсилле анализ бирелде. Хөкүмәт башлыгы әйтүенчә, шәһәр округлары һәм муниципаль районнарның 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеше стратегияләре белән беррәттән, барлык муниципалитетларда җирлекләрнең үсеш планнары расланган. Алар «Стратегия-2030» республика планының аерылгысыз өлеше булып тора һәм максат-бурычлары да уртак. Кайбер муниципалитетларның, шул исәптән Казанның, Чистай һәм Менделеевск районнарының стратегияләре федераль дәрәҗәдә югары бәяләнү дә бик мөһим.

Муниципаль берәмлекләрне уңышлы үстерү, стратегик һәм бюджет планлаштыруларын тагын да якынайтуны тәэмин итү максатыннан республикада бөтен тармакларның үсеш стратегияләре эшләнгән, 33 дәүләт программасы (2017 елгы мәгълүматлар буенча) кабул ителгән, аларны гамәлгә ашыру чыгымнары республика бюджетының 95 проценттан күбрәген тәшкил итә. Алексей Песошин, фикерен куәтләп, программалар комплексын тормышка ашыруның муниципалитетлар үсешендәге аерымлыклардан системалы рәвештә котылу мөмкинлеге һәм, бусы да бик әһәмиятле, барлык муниципаль берәмлекләр үсеше өчен тигез шартлар булдыру мөмкинлеге бирүенә дә тукталды.

ТР вице-премьеры, ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов чыгышы авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә – аерым алганда, шәхси хуҗалыкларга, КФХ, гаилә фермаларына һ.б. булышу про-













граммаларына күзәтү ясауга багышланган иде. Нәкъ менә хуҗалык итүнең кече формаларын үстерү эше нәтиҗәсендә авылда җирлекләрнең икътисадый нигезен ныгыту, салым салына торган базаны киңәйтү, яңа эш урыннары булдыру мөмкинлеге саклана. Министр мәгълүматлары буенча, кече формаларга ярдәмгә, авыл халкының эш активлыгын арттыруга гына да республика бюджетыннан ел саен 2 миллиард сумнан күбрәк акча бүленә. Әгәр инде финанслауның тулаем күләмен (социаль инфраструктураны да кертеп) исәпкә алсаң, әлеге сумма ел саен дистәләрчә миллиард сумга җитә.

Съезд ахырында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов сүз алды. Ул үз чыгышында тулаем Татарстанның һәм кайбер муниципаль берәмлекләр үсешенең төп нәтиҗәләренә тукталды. Республика башлыгы депутатларның игътибарын гамәлдәге проблемаларга юнәлтте һәм 2018 елда дәүләт һәм муниципаль хакимият бергәләп хәл итәргә тиешле өстенлекле бурычларны билгеләде.

«Социаль объектлардан нәтиҗәле файдалану һәм вакыйгаларда катнашу активлыгын арттыру җирле үзидарә органнарының төп бурычы булып тора. Безнең бүгенге эшләребезнең барысы да – спорт мәйданчыклары төзү, җәмәгать урыннары булдыру – әлеге территориядә яшәүчеләргә хезмәт итәргә тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Республика программалары территорияләрне үстерү бурычларын системалы хәл итүгә, шулай ук объектларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең, яшәү урыннарына бәйсез рәвештә, барлык гражданнар өчен дә уңайлы булуын тәэмин итүгә юнәлтелә. Муниципаль берәмлекләр башлыкларына шәһәрләр һәм районнардагы актуаль мәсьәләләрне гамәлгә кертелә торган программалар кысаларында хәл итүне планлаштыру зарур».

Фикерен куәтләп, ул планнарның республикадагы икътисад һәм сәнәгать потенциалы нәтиҗәсендә уңышлы үтәлүенә басым ясады. Республиканың ил күләмендә позициясе турында сөйләгәндә, Рөстәм Миңнеханов Татарстанның авыл хуҗалыгы буенча 3 нче урында, төп капиталга инвестицияләр буенча – 4 нче, сәнәгать җитештерүе, шулай ук торакны файдалануга тапшыру буенча 5 нче урында торуын хәбәр итте. Тулай төбәк продукты һәм төзелеш күләмнәре буенча республика 6 нчы урынны, ваклап сату әйләнеше буенча 8 нче урынны били. Социаль-икътисадый үсешнең төп күрсәткечләре буенча Татарстан Идел буе федераль округында беренче урында бара.





Татарстан Президенты хезмәт хакының түбән булуына да тукталды, республикада хезмәткә түләүнең минималь күләменең (МРОТ) 2018 ел башында ук артачагын хәбәр итте. Бүген Татарстан әлеге күрсәткеч буенча Идел буе федераль округында 4 нче урынны били. Республика башлыгы халыктан үзара салым җыю программасын гамәлгә кертүгә, территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерүгә бәйле мәсьәләләргә дә игътибарны юнәлтте.

Чыгышын тәмамлаганда, ТР Президенты җирле үзидарәнең республиканың нигезен тәшкил итүен кабат искәртте, чөнки муниципалитетлар җитәкчеләре гражданнар белән турыдан-туры аралаша бит. «Яхшы нәрсә тиз онытыла, начарлык онытылмый. Сезгә барлык тискәре хисләрне үзегезгә кичерергә туры килә, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Әмма без ничек тә тормышның сыйфатын яхшыртырга, урыннардагы проблемаларны хәл итәргә тырышырбыз. Тик сезнең яктан да төгәл системалы эш алып барылырга тиеш. Уртак эшебез өчен минем һәркайсыгызга рәхмәт әйтәсем килә».

Съезд эше, республика җитәкчелеге, форум делегатлары чыгышлары нәтиҗәләре буенча дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының уртак чаралар планы эшләнде. Әлеге документ Татарстан Республикасы хакимиятенең барлык баскычлары һәм тармаклары килешеп эшләүгә күрсәтмә булып тора.

## МУНИЦИПАЛЛАР ӨЧЕН 100 МАШИНА

**ТР муниципаль берәмлекләренең XII съезды алдыннан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республиканың иң яхшы авыл җирлекләре һәм муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренә автомобильләр бүләк итте. Муниципалларга 93 Chevrolet NIVA автомобиле ачкычы тапшырылды, моннан тыш, Казан вәкилләренә – 4, Яр Чаллы учреждениеләренә 3 Ford Transit автобусы бүләк ителде. Муниципаль бергәлек съездлары алдыннан автомобиль бүләк итү республикада игелекле традициягә әйләнде. Соңгы җиде елда муниципалитетларга 1770 машина тапшырылган инде.**




**Бүләкләү тантанасында чыгыш ясаганда, Рөстәм Миңнеханов: «Гади кеше өчен федераль һәм республика хакимиятләре арасында берниндн аерма да юк, шунлыктан сезнең эшегез югары сыйфатлы булырга тиеш», – дип белдерде, муниципалитет җитәкчесенең роле һәм статусы матди-техник базаны ныгытуга да бәйле булуын искә төшерде. Шунлыктан Татарстанда һәр муниципалитетта авыл җирлеге биналарын ремонтлау, яңа транспорт бирү, яңа объектлар ачу кебек уңай үзгәрешләр булдырырга омтылалар. «Без нәкъ менә сезнең хакимияткә терәк булуыгызны яхшы аңлыйбыз», – диде Рөстәм Миңнеханов.**



ТАТАРСТАННЫҢ БӨТЕН МУНИЦИПАЛИТЕТЛАРЫН БЕРЛӘШТЕРГӘН ТР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫ РЕСПУБЛИКАДАГЫ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ СИСТЕМАСЫН ҮСТЕРҮ ҺӘМ НЫГЫТУ ПРОЦЕССЫНДА МӨҺИМ РОЛЬ УЙНЫЙ. СОВЕТ РӘИСЕ ӘГЪЗАМ ГОБӘЙДУЛЛИННАН БЕЗ БЕРЛӘШМӘ АЛДЫНА КУЕЛГАН БУРЫЧЛАР, ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ХАКИМИЯТ ОРГАННАРЫ УРТАК ЭШЕНЕҢ НИЧЕК ОЕШТЫРЫЛУЫ ТУРЫНДА СӨЙЛӘВЕН ҮТЕНДЕК.

# *КИЛӘЧӘККӘ юнәлтелгән бурычлар*

**– Әгъзам Саматович, быел ТР Муниципаль берәмлекләре Советы алдына нинди төп бурычлар куела?**

– Совет эшенең төп юнәлешләре, җитди игътибар таләп иткән аеруча мөһим мәсьәләләр республика муниципаль берәмлекләре съездында билгеләнә. Былтыр чираттагы XII съезд булды, анда барлык муниципаль берәмлекләрдән делегатлар бар иде. Бүген республикада 956 муниципалитет исәпләнә, без – Россиядә иң зур Совет. Форум эшендә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Премьер-министры Алексей Песошин, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, депутатлар корпусы, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты. Съездда еллык эшчәнлеккә нәтиҗәләр ясалды, Совет эшенә бәя бирелде, алдагы елга максат һәм бурычлар билгеләнде, җирле үзидарә органнарындагы хакимиятнең барлык баскычлары тырышлыгын таләп итә торган проблемалар тикшерелде.

Съезд карарларын һәм муниципалитетларга республика Президенты куйган бурычларны тормышка ашыру эшебезнең мөһим элементы булып тора. Берничә ел

*ТР Муниципаль берәмлекләре Советы, бөтен шәһәр һәм районнар һәр бистә, авыл, һәр шәһәрне һәм тулаем төбәкне үстерүне иң өстенлекле бурычлары итеп саный. Без барыбыз да конкрет муниципалитетларда яшибез. Һәм, шуңа бәйле рәвештә, федераль һәм республика социаль-икътисадый үсеш программалары әлеге муниципалитетлар территорияләрендә гамәлгә кертелә. Советның бурычы – муниципалитетларга оештыру, методик ярдәм күрсәтеп, барлыкка килгән проблемаларны республика хакимият органнары белән берлектә тиз арада хәл итеп, әлеге программаларны уңышлы үтәү өчен урыннарда шартлар тудыру.*

***Социаль объектларны нәтиҗәле файдалануга съездда аеруча игътибар бирелде. Әлеге бурыч бик актуаль. Инфраструктураны яңартуга һәм төзүгә республика гаять зур акча кертте. Соңгы елларда барлык муниципалитетларда дистәләрчә төрле социаль объект – мәдәният йортлары, ФАПлар, спорт мәйданчыклары, мәктәпләр һәм балалар бакчалары төзелде, парклар һәм скверлар ачылды. Бүген бездәгедәй программалар башка төбәкләрдә дә кабул ителә. Бу бик сөенечле факт. Без исә, үз ягыбыздан, барлык объектларның буш тормавын, эшләвен һәм халыкка файда китерүен тәэмин итәргә тиеш.***

дәвамында барлык бурычлар гомумиләштерелә һәм бер документта – Дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының уртак чаралары планында туплана. Планны ТР Премьер-министры һәм ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе имзалый, аннары республика Президенты раслый. Федерациянең шактый субъектларындагы коллегаларыбыз бүген безнең әлеге планны әзерләү һәм аның буенча эшләү тәҗрибәсен өйрәнә.

ТР Муниципаль берәмлекләре Советы, бөтен шәһәр һәм районнар һәр бистәне, авыл, һәр шәһәрне һәм тулаем төбәкне үстерүне иң өстенлекле бурычлары итеп саный. Без барыбыз да конкрет муниципалитетларда яшибез. Һәм шуңа бәйле рәвештә федераль һәм республика социаль-икътисадый үсеш программалары әлеге муниципалитетлар территорияләрендә гамәлгә кертелә.

Советның бурычы – муниципалитетларга оештыру, методик ярдәм күрсәтеп, барлыкка килгән проблемаларны республика хакимият органнары белән берлектә тиз арада хәл итеп, әлеге программаларны уңышлы үтәү өчен урыннарда шартлар тудыру. Безнең мондый мөмкинлекләребез бар, чөнки без Татарстанның башкарма һәм закон чыгару хакимияте белән тыгыз элемтәдә эшлибез.

Татарстанда эшли торган барлык 37 программа да авыл халкының эшлеклелеген активлаштыру, авыл халкы, яшь гаиләләр өчен торак төзү, җирлекләрдә юллар салу һәм аларны карап тоту, гражданнарның үзара салым җыюын оештыру, авыл җирлекләренә грант ярдәме күрсәтү кебек һәм башка бик күп кичектергесез проблемаларны һәм бурычларны хәл итүгә юнәлтелгән.

Әлеге юнәлешләрнең кайберләре инде берничә ел буена гамәлгә кертелә, кайберләре әле яңа.

Социаль объектларны нәтиҗәле файдалануга съездда аеруча игътибар бирелде. Әлеге бурыч бик актуаль. Инфраструктураны яңартуга һәм төзүгә республика гаять зур акчалар кертте. Соңгы елларда барлык муниципалитетларда дистәләрчә төрле социаль объект – мәдәният йортлары, ФАПлар, спорт мәйданчыклары, мәктәпләр һәм балалар бакчалары төзелде, парклар һәм скверлар ачылды. Бүген бездәгедәй программалар башка төбәкләрдә дә кабул ителә. Бу бик сөенечле факт. Без исә, үз ягыбыздан, барлык объектларның буш тормавын, эшләвен һәм халыкка файда китерүен тәэмин итәргә тиеш. Кеше аларның чыннан да файдалы булуын тойсын.

Социаль инфраструктураны төзү һәм яңарту быел да дәвам итә. Әлеге программалардан берсе – авыл җирлекләре башкарма комитетлары биналарын төзү һәм ремонтлау. Программаны безнең Совет 2015 елда тәкъдим иткән һәм аны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов хуплаган иде. 2016 елда аның кысаларында – 78, былтыр исә 42 бина ремонтланды һәм 11 бина салынды. Быел 38 бинаны капиталь ремонтлау һәм 10 яңа объект төзү планлаштырыла. Әлеге максатларга ел саен республика бюджетыннан 100 миллион сум акча бүленә. Бу программа – республикада муниципалитетларга күрсәтелә торган гаять зур ярдәмнең бер өлеше.

Соңгы елларда бездә парк һәм скверлар күп төзелә һәм үзгәртеп корыла. Муниципалитетларга әлеге объектларны тиз арада инвентарьлаштыру бурычы куела.

Авылда кече эшкуарлыкны үстерү, авыл җирлекләренең

Быел 38 авыл җирлеге башкарма комитеты бинасын капиталь ремонтлау һәм 10 яңа объект төзү планлаштырыла.



икътисадый базасын ныгыту, яшь белгечләрне һәм яшьләрне авыл җирлегендә калдыру өчен безгә әле күп эшләргә кирәк. Барлык бу юнәлешләр безнең өчен өстенлекле булып тора.
Без быел да территориаль иҗтимагый үзидарәләре (ТИҮ) белән актив хезмәттәшлекне дәвам итәчәкбез. ТР Президенты да аларга булышу зарурлыгына игътибарны юнәлтте. Быел ТИҮләр арасында инде дүртенче тапкыр республика конкурсы үткәреләчәк. Аны безнең Совет тәкъдим иткән һәм ТР Президенты һәм Хөкүмәте тулысынча хуплаган иде. Бәйгенең бүләк фонды 50 миллион сумны тәшкил итә. Бүген Татарстанда 360 ка якын ТИҮ эшли. Аларның эшенә тел тидерерлек түгел, әмма, саннарын ишәйтү артыннан кумыйча, эчтәлегенә дә җитди игътибар бирү зарур. Совет каршында моннан ике ел оештырылган ТИҮләрне Координацияләү советының якын арада узачак утырышын без ТИҮләр эше тәҗрибәсен тикшерүгә багышларга җыенабыз.
Барлык бурычлар да өстенлекле. Аларны бер-бер артлы хәл итү муниципалитетлар үсешенең нигезе булып тора. Эшнең уңышы исә күп очракта халыкның активлыгына, аларның үз территорияләре белән идарәгә ничек җәлеп ителүенә бәйле. Муниципаль һәм дәүләт хакимиятләренең республика гражданнарына, аларның инициативасына таянуы ахыр чиктә һәр татарстанлының көндәлек тормышын яхшыртыр, дип ышанам.

**– Республикадагы дәүләт һәм муниципаль хакимиятләрнең үзара хезмәттәшлеген Сез ничек бәяләр идегез?**

– Бүген республикабыз социаль-икътисадый үсешнең күп күрсәткечләре буенча илнең күпчелек төбәкләре арасында әйдәп бара. Хакимиятнең барлык баскычлары һәм тармаклары тотрыклы һәм көйле эшләмәсә, Татарстан уңышка ирешә алмас иде. Минем фикеремчә, республикадагы дәүләт һәм муниципаль хакимиятләрнең үзара аңлашып эшләве илебездәге теләсә кайсы субъект үсеше форматының оптималь нигезе була ала. Татарстанның бу өлкәдәге тәҗрибәсе Муниципаль берәмлекләрнең гомумроссия конгрессы Гомуми җыенында катнашучыларда тикмәгә генә зур кызыксыну уятмагандыр инде.
Муниципаль хакимият органнарын республика җитәкчелеге тулысынча хуплый. Эштә килеп туган проблемалар позицияләрне килештерү барышында тиз арада хәл ителә. Мондый эш алып барыла торган мәйданчыклар – ТР Муниципаль берәмлекләре Советы Президиумы утырышлары һәм «түгәрәк өстәлләр», алар эшендә ТР Президенты Аппараты, ТР Министрлар Кабинеты һәм ТР Дәүләт Советы вәкилләре, республиканың министрлык һәм ведомстволары җитәкчеләре катнаша. Шундый үзара хезмәттәшлек нәтиҗәсендә байтак проблемалар хәл ителә. Җирлек башлыкларын контрольдә тоту инстанцияләренең чамадан тыш активлыгы, муниципалитетларга салына торган штрафлар санының артуы мәсьәләсен хәл итү моның ачык мисалы булып тора. ТР Президенты күрсәтмәсе буенча төзелгән республика комиссиясе эше нәтиҗәсендә әлеге проблемаларны хәл итү юллары табылды. Комиссиягә барлык кызыксынган яклар кертелгән иде.
Авыл җирлекләре башлыклары арасында узган ел азагында үткәрелгән социологик сораштырулар нәтиҗәләре кызыклы. «Дәүләт һәм җирле хакимият органнары арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне ничек бәялисез?» дигән сорауга аларның 21,5 %ы, барлык мәсьәләләрдә дә килешеп эшлибез, дип, 60,8 %ы, күпчелек сорауларда килешәбез, дип җавап биргән. Һәм сораштырылганнарның нибары



Муниципалларның квалификациясен күтәрү максатыннан Совет ТР Президенты Аппараты белән берлектә ел саен семинарлар үткәрә, аларда барлык авыл җирлекләре башлыклары, муниципаль район башлыклары урынбасарлары белем ала.

Соңгы елларда барлык муниципалитетларда дистәләрчә социаль объект – мәдәният йортлары, ФАПлар, спорт мәйданчыклары, мәктәпләр һәм балалар бакчалары төзелде, парклар һәм скверлар ачылды.





Быел ТИҮләр арасында инде дүртенче тапкыр республика конкурсы үткәреләчәк.

***Хакимиятнең барлык баскычлары һәм тармаклары тотрыклы һәм көйле эшләмәсә, Татарстан уңышка ирешә алмас иде. Минем фикеремчә, республикадагы дәүләт һәм муниципаль хакимиятләрнең үзара аңлашып эшләве илебездәге теләсә кайсы субъект үсеше форматының оптималь нигезе була ала. Татарстанның бу өлкәдәге тәҗрибәсе Муниципаль берәмлекләрнең гомумроссия конгрессы Гомуми җыенында катнашучыларда тикмәгә генә зур кызыксыну уятмагандыр инде.***

10,3 %ы гына килешеп эшләү җитәрлек түгел, дип саный. Җирлек башлыкларының 7,3 %ы җавап бирмәгән. Әлеге саннар үзара хезмәттәшлекнең гамәлдәге механизмнары нәтиҗәле булуын күрсәтә һәм муниципалитетларга үз вәкаләтләрен тоткарлыксыз башкарырга мөмкинлек бирә.

**– Урыннардагы идарәче кадрларның һөнәрмәндлеге проблемасы күп еллардан бирле тикшерелә. Муниципаль хакимияткә карата әлеге сорау бүген республика өчен никадәр актуаль?**

– Җирле үзидарә системасы формалашып кына килгәндә кадрлар белән проблемалар чыннан да булды. Билгеле бер дәрәҗәдә алар хәл ителгән, әмма кадрлар мәсьәләсе актуальлеген барыбер югалтмый. Бу дәвердә республикада кадрлар әзерләү һәм белгечләрнең белемен күтәрүнең куәтле системасы булдырылды. Әгәр моннан ун ел элек муниципалитет башлыкларының 59 %ы гына югары белемле булса (еш кына – профиль буенча түгел), бүген муниципалитет җитәкчеләренең 77 %ы – югары белемле белгеч, шулардан чирегенә якыны – юрист һәм икътисадчы.

Бүген безнең җирле үзидарә системасында 15 меңгә якын кеше эшли – депутатлар корпусы, сайланган вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр, ТИҮ активистлары. Бу – җирле территорияләрне үстерү буенча катлаулы мәсьәләләрне хәл итүче зур һөнәри төркем. Һәм безнең бурычыбыз – аларга булдыра алганча оештыру, хокукый, методик, консультацион ярдәм күрсәтү.

Муниципалларның квалификациясен күтәрү максатыннан безнең Совет ТР Президенты Аппараты белән берлектә ел саен семинарлар үткәрә, аларда барлык авыл җирлекләре башлыклары, муниципаль район башлыклары урынбасарлары белем ала. Семинарларда министрлык һәм ведомстволар хезмәткәрләре, экспертлар катнаша. Җирле үзидарә системасы өчен белгечләр әзерләү буенча КФУ каршындагы Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе зур эш башкара. Хезмәткәрләребез дә уку процессында катнаша, курсларда тыңлаучылар каршында лекцияләр укый.

Кадрлар әзерләү һәм белгечләрнең белемен күтәрүдән тыш, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы идарәче кадрларның һөнәрмәндлеген үстерүне стимуллаштыруга зур игътибар бирә. 2006 елдан бирле һәр елны без муниципаль хезмәткәрләр һәм республиканың җирле үзидарә темасын яктыртучы гаммәви мәгълүмат чаралары арасында республика конкурслары уздырабыз.

Җирле үзидарә системасының нәтиҗәлелеге елданел арта бара. Моның нигезе – муниципалитет хезмәткәрләренең һөнәрмәндлеге үсүдә. Безнең бурыч исә – әлеге процессның тотрыклылыгын тәэмин итү.

Муниципаль Совет Президиумы утырышлары киңәйтелгән составта уздырыла.





# ҖИРЛЕ хакимият: илебез тәҗрибәсе

УЗГАН ЕЛ АХЫРЫНДА МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ ГОМУМРОССИЯ КОНГРЕССЫ «РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНДӘ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ТОРЫШЫ, АНЫҢ ҮСЕШ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ ҺӘМ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ҺӘМ ОЕШТЫРУНЫ ХОКУКЫЙ ҖАЙЛАУНЫ КАМИЛЛӘШТЕРҮ БУЕНЧА ТӘКЪДИМНӘР» ДИП АТАЛГАН ДОКЛАДНЫ РФ ХӨКҮМӘТЕНӘ КАРАЛУГА КЕРТТЕ. РОССИЯДӘ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ СИСТЕМАСЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛЕ АСПЕКТЛАРЫН АНАЛИЗЛАГАН КҮЛӘМЛЕ ДОКУМЕНТ, ИЛНЕҢ ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРЕНДӘГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР СОВЕТЛАРЫ БИРГӘН МӘГЪЛҮМАТКА ТАЯНЫП, ЭКСПЕРТЛАР ТӨРКЕМЕ ТАРАФЫННАН ӘЗЕРЛӘНГӘН ИДЕ.

Шунысы мөһим: федераль хөкүмәткә кертү өчен доклад әзерләү турында карар МБГКның 2015 елда Казанда үткән Гомуми җыелышында кабул ителгән иде. Әлеге докладны әзерләгәндә безнең республика турындагы материаллар – Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерү тәҗрибәсе буенча ТР Муниципаль берәмлекләре Советы тарафыннан ясалган анализ нәтиҗәләре дә кулланылды. Документның тулы тексты белән МБГК сайтында танышырга мөмкин. Сезнең игътибарга безнең фикеребезчә Россиядә, һәм аерым алганда Татарстанда бүгенге көндә муниципаль идарәдә эшләүчеләрне борчыган көнүзәк сорауларга багышланган өземтәләрне тәкъдим итәбез.

Ил күләмендәге вазгыятькә анализ бирер алдыннан документ авторлары Россиядә җирле үзидарәнең ике ягын билгеләп үтәләр. Бер яктан, җирле үзидарә органнары урыннарда гавами хакимиятнең тулы системасы буларак кабул ителә. Дәүләт һәм муниципаль дәрәҗәләр тарихи яктан һәм РФ законнарына ярашлы рәвештә ил территорияләре белән идарә итүнең бердәм системасын барлыкка китерә. ҖҮИ органнарының гомумдәүләт менеджменты системасының аерылгысыз өлеше буларак кабул ителү факты шуның белән аңлатыла да. Шуңа күрә муниципаль һәм дәүләт вәкаләтләрен төгәл чикләү һәм муниципаль вәкаләтләрне аерым реестрда системалаштыру күпмедер дәрәҗәдә авыр да. Икенче яктан караганда, РФ Конституциясенең 12 нче маддәсенә ярашлы рәвештә, ҖҮИ органнары дәүләт хакимияте органнары системасына керми. Шул ук вакытта әлеге нигезләмәнең практикада кулланылышы муниципаль идарәнең дәүләт идарәсе системасының бер компоненты булып торуы шартларында бара.



**Россия Президенты Владимир ПУТИН: «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципларын төгәлләштерүне, урыннарда көчле, бәйсез, финанс ягыннан бай хакимиятне үстерүне иң мөһим бурыч дип саныйм».**

## ИКЪТИСАДНЫ СТИМУЛЛАШТЫРУ МЕХАНИЗМНАРЫ

Җирле үзидарә үсешендәге төп проблемаларның берсе сыйфатында җирле бюджетларны формалаштыруга һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләүгә якын килүләрнең ҖҮИ органнары башкарырга тиешле бурычларга туры килмәвен атарга була. РФ бюджет системасы принципларының берсе булып бюджетларның мөстәкыйльлеге принцибы тора. Ул ҖҮИ органнарының бюджет процессын гамәлгә ашырудагы мөстәкыйльлеге хокукын һәм бурычын билгели, шул исәптән җирле бюджет акчаларын тоту юнәлешләрен һәм формаларын билгеләүдә дә (башка дәрәҗәдәге бюджетлар хисабына финанслана торган чыгымнардан тыш). Шул ук вакытта сүз шартлы мөстәкыйльлек турында бара, чөнки беренче чиратта җирле бюджет акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә кирәк.

131-ФЗ номерлы Федераль законның 19 нчы маддәсе ҖҮИ органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен тапшыруны күз уңында тота, әлеге вәкаләтләрне финанслар белән тәэмин итү тиешле дәрәҗәдәге бюджеттан күчерелгән субвенцияләр хисабына алып барыла, дип билгеләнә. Муниципаль районнар һәм алар территориясендә урнашкан җирлекләр арасында вәкаләтләрне авыл җирлеге дәрәҗәсеннән алып бирү турында килешүләр төзү тәҗрибәсе шактый таралган. 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 нче маддәсе 4 нче пунктына ярашлы рәвештә, вәкаләтләрне тапшыру тиешле бюджетлардан күчерелә торган субвенцияләр формасындагы финанслар белән бергә башкарыла. Муниципалитетларга тапшырыла торган аерым дәүләт вәкаләтләре өчен субвенцияләрне исәпләүнең үз методикасы эшләнгән. Шулай да ҖҮИ тарафыннан башкару өчен тапшырыла торган вәкаләтләрнең шактый өлеше аларны тәэмин итүдә чыгымнарны исәпләүнең бердәм методикасына ия түгелләр. Нәтиҗәдә муниципалитетлар тарафыннан үз вәкаләтләрен һәм үтәү өчен тапшырылганнарын башкаруның төрле (фактта – индивидуаль) оештыру-финанс модельләре гамәлгә ашырыла.

Дәүләт вәкаләтләрен төбәк дәрәҗәсеннән муниципаль дәрәҗәгә тапшырганда РФ субъектларының дәүләт хакимияте органнары әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатына бирелергә тиешле субвенцияләр күләмен объектив исәпләргә һәм аларның нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирүче методикаларны кулланырга тиеш, моны закон дәрәҗәсендә беркетергә кирәк.

Бюджетара трансфертлар җирле бюджетларның төп керем чыганагы булып кала бирә, шул исәптән гамәлдәге федераль һәм төбәк программалары кысаларында да. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: бюджетара мөнәсәбәтләрнең гамәлдәге традицияләре икътисадый муниципаль инициативаларны мотивацияләүне киметә. Сәбәп җирле хакимиятләрнең пассивлыгына караганда, мөстәкыйль икътисадый карарлар хисабына җирле бюджет керемнәрен шактыйга арттыру перспективаларының булмавында. Җирле салымнар һәм НДФЛдан кергән керемнәрнең үсеше кайчак җирле бюджетның икътисадый үсешкә дип тәгаенләнгән чыгымнарын капларга җитми. Әйтик, яңа предприятиеләр төзү һәм аларны эшләтеп җибәрү муниципаль берәмлекнең социаль, коммуналь-энергетик һәм юлтранспорт инфраструктурасына йөкләнешнең артуына китерә. Хуҗалык итүче субъектларның икътисадый эшчәнлегеннән кергән керемнәрне төбәк бюджетлары ала. РФ Бюджет кодексының 58 нче маддәсе нигезендә төбәкләр аерым федераль һәм төбәк салымнарыннан һәм махсус салым режимнары тарафыннан каралган салымнар, җыемнардан җирле бюджетка күчерелә торган акчаларны исәпләүнең бердәм нормативларын билгели алалар. Кызганычка каршы, муниципаль икътисадый инициативаны стимуллаштыруда әлеге мөмкинлекне РФ субъектларының барысы да (51 субъект) кулланмый. Тәҗрибә күрсәткәнчә, барыннан да ешрак РФ субъектлары муниципаль берәмлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләү өчен дотацияләр бирүне НДФЛдан акча күчерүнең өстәмә нормативына алыштыру механизмын кулланалар. Әмма атап үтелгән өстәмә нормативтан кергән акчалар һәрвакытта да нормативны исәпләгәндә планлаштырылган күләмнәргә туры килеп бетмиләр. Башка сүзләр белән әйткәндә, җирле бюджетлар бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә бирелергә тиешле дотациянең күпмедер өлешен югалталар. Нәтиҗәдә җирле бюджетларга финанс ярдәме күрсәтү шактыйга кыскарырга мөмкин.

## КОНТРОЛЬ-КҮЗӘТЧЕЛЕК ЭШЧӘНЛЕГЕН КАМИЛЛӘШТЕРҮ

Үз вәкаләтләрен үти торган ҖҮИ органнарына карата контрольлек функцияләрен гамәлгә ашыруның кирәклеге бәхәссез. Шулай да, кызганычка каршы, дәүләт контроле һәм күзәтчелеге органнары, ҖҮИ органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына карата тикшерүләр үткәргәндә һәм карарлар кабул иткәндә, һәрвакытта да муниципалитетта барлыкка килгән шартларны, ҖҮИ органнарының реаль мөмкинлекләрен һәм халыкның көнүзәк ихтыяҗларын игътибарга алып эш итмиләр. Кайвакыт әлеге муниципалитетта контроль-күзәтчелек органнары күрсәтмәләрен һәм алга таба суд карарларын тормышка ашыру мөмкин түгел. Һәм ул вакытта ҖҮИ органнарына салынган җәзаларга билгеләнгән срокта суд карарларын үтәмәгән өчен салына торган штрафлар да өстәлә. Болар барысы да җирле бюджетларның муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый максат һәм бурычларга ярашлы рәвештә башкарылуын тоткарлый, һәм шуңа күрә ахыр чиктә ҖҮИ органнары үз вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкара ал-



Хөкүмәткә кертү өчен доклад әзерләү турында карар Казанда үткән МБГКның Гомуми җыелышында кабул ителде. (Уртада – МБГК президенты Виктор Кидяев).

мый. Төп мәсьәлә – вәкаләтләрнең үтәлмәве сәбәпләрен ачыклау. Еш кына аерым затларның субъектив позициясе түгел, чынлыкта ҖҮИ органнары тарафыннан вәкаләтләрне үтәүне финанслау мөмкинлегенең булмавы (җирле бюджет акчалары җитми) шундый сәбәп булып тора. Тикшерү чараларының артуы проблеманы хәл итү түгел, бәлки аны тагын да катлауландыра гына. Тикшерүләр артканда идарә ителүдә дә куркыныч арта.

Тагын бер фактны күрсәтеп китәргә кирәк. РФ Административ хокук бозулар кодексында җирле бюджетта акча булмау сәбәпле үтәлмәгән вәкаләтләргә бәйле җаваплылыктан вазыйфаи затны азат итү (әгәр тиешле акчалар бүлеп бирүне сораган гариза алдан бирелгән булса) турындагы норма барлыкка килгәннән соң, судлар актив рәвештә юридик затлар – ҖҮИ органнарын җаваплылыкка тарта башладылар. Бу очракта штрафлар җирле бюджетлардан түләнә. Димәк, моңардан беренче чиратта ел өчен планлаштырылган эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне ала алмаган халык зыян күрә. Шуңа басым ясарга туры килә: ҖИҮ органнарына һәм аның вазыйфаи затларына карата кулланыла торган тикшерүләрнең саны, җәза төрләренең һәм размерларының күбәюе контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең беренчел максатына, ягъни гавами вәкаләтләрне башкарганда нәтиҗәлелекне арттырырга ярдәм итми. Җирле үзидарә һәм аны башкару хокукына бәйле сораулар суд практикасында актив тикшерелә. ҖҮИ хокукларын судта яклау үрнәкләре булса да, аларның муниципаль эшнең нәтиҗәлелегенә бары тик формаль яктан юнәлдерелгән массакүләм суд практикасы гына булуларын атарга кирәктер. Суд эшләренең реаль нәтиҗәләре, кызганычка каршы, мактанырлык түгел. Әйтик, соңгы вакытларда судлар җирле бюджетларга билгеле бер чыгым йөкләмәләре салган бик күп карарлар кабул итәләр. Өстәвенә, кайбер очракларда мондый чыгымнарның күләме җирле бюджетлар күләменнән артып китә. Мондый суд карарларын үтәүнең реаль мөмкинлеге турында шактый законлы сорау туа.

Шундый үтәп булмаслык суд карарларын алган һәм «җил тегермәннәре» белән көрәшүнең файдасыз икәнлеген аңлаган вазыйфаи затлар ҖҮИ эшеннән китә. Нәтиҗәдә муниципаль берәмлекне үстерү белән кызыксынган профессионалларны югалтабыз. Хәзерге вакытта судлар эшчәнлегенең РФндә һәм муниципаль дәрәҗәдә ҖҮИ торышына йогынтысы күләмен бәяләү авыр, чөнки әлеге сораулар беркем тарафыннан да гомумиләштерелмәгән. Югарыда аталганнарны исәпкә алып, Конгресс муниципаль идарәнең сыйфатын арттыру максатында Россия Юстиция министрлыгына ҖҮИ органнарына һәм аның вазыйфаи затларына карата суд практикасын һәм аның нәтиҗәләрен ел саен уртак мониторинглауны (карала торган эшләр категориясенең үзенчәлеген, аларның судка бирелү мөмкинлеген һәм ведомствога караганлыгын исәпкә алып) үткәрергә тәкъдим итә.


## ҖҮИНЕ ҮСТЕРҮ БУЕНЧА РОССИЯ ТӨБӘКЛӘРЕННӘН КИЛГӘН ТӘКЪДИМНӘР

МБГК докладының кушымтасында РФ субъектларындагы Муниципаль берәмлекләр Советларыннан һәм муниципалитетара хезмәттәшлек буенча төбәкара ассоциацияләрдән алынган тәкъдимнәр тупланган. Кайсыбер тәкъдимнәр федераль мәйданчыкларда бер генә мәртәбә яңгырамады. Кайберләре яңа тәкъдимнәр, һәм алар бүгенге социаль-икътисадый вазгыять куйган таләпләргә җавап булып тора. Бер-берсенә капма-каршы тәкъдимнәр дә бар, бер-берсен тулыландыра торганнары да очрый. Кайбер тәкъдимнәр шәһәр округлары мәнфәгатьләреннән чыгып эшләнгән, икенчеләре – муниципаль районнар өчен, өченчеләре авыл җирлекләре ихтыяҗын күздә тота. Авторлар билгеләп үткәнчә, урыннардан килгән тәкъдимнәр доклады тыш та кызыксыну уяталар, чөнки реаль хокук кулланылышы тәҗрибәсеннән чыгып эшләнгәннәр. Безнең фикеребезчә, муниципалларның муниципаль хакимиятнең икътисадый базасын реформалауга юнәлдерелгән фикерләре бигрәк тә кызыклы.

## ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЕ

1. Муниципаль берәмлекләрнең елдан-ел үз-үзләрен тәэмин итә һәм үз-үзләрен финанслый алуының кимүгә таба баруы җирле бюджетка салым керемнәренең азаюы, «финансланмый торган мандатларның» саны күбәюе һәм җирле әһәмияттәге сорауларны һәм дәүләт тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле чыгымнар белән чынлыкта бюджет күтәргән чы-

## ФЕДЕРАЛЬ ОКРУГЛАР БУЕНЧА КАРАГАНДА МУНИЦИПАЛЬ БУРЫЧ КҮЛӘМЕ, МЛРД СУМНАРДА




гымнар арасындагы аерманың даими рәвештә арта баруы белән аңлатыла. ҖҮИ органнары башкара торган вәкаләтләрнең күләме чынлыкта алына торган акчаларга туры килергә тиеш.

2. Дәүләт хакимиятенең контроль-күзәтчелек органнары, судлар карарлар кабул иткәндә, муниципаль берәмлекнең әлеге карарны үти алу мөмкинлеген исәпкә алырга тиешләр; җирле бюджет чыгымнарын билгеләү хокукы муниципаль хакимиятнең вәкиллекле органнарына бирелгән, бу юнәлештә аларны дәүләт хакимияте органнары алыштырырга тиеш түгел, моны закон рәвешендә тыярга кирәк.

3. Федераль һәм төбәк дәрәҗәләрендә кабул ителә торган дәүләт программалары җирле бюджетларның керем базасын арттыруда шактый җитди ярдәм булып тора. Шулай да әлеге программалар муниципаль берәмлекләрнең барлык типлары өчен туры килми. Мондый программаларда шәһәр округларына гына түгел, авыл җирлекләренә дә катнашу мөмкинлеге тудыра торган механизм уйлап табу максатка ярашлы булыр иде.

4. Җирле бюджетларның керемнәрен арттыруда иң яңа механизмнарның берсе буларак гражданнарның үзара салым акчаларын атарга булыр иде. Шуның белән бергә практикада хокукый нормалардагы җитешсезлекләр һәм гамәлдәге законнардагы коллизияләр нәтиҗәсендә әлеге механизмны куллану авырлык тудыра. Җыемны түләүче субъектның кем булуын (мисалга, әлеге очракта муниципаль берәмлектә яшүчегә кем керә; әлеге нормалар иждивениедә булучыларга, балигъ булмаганнарга һ.б.ларга кагыламы), әлеге карарны үтәү механизмының нинди булуын төгәлләштерергә кирәк. Гавами-хокукый бурычларны гражданнарга гына йөкләмәс өчен, җирле һәм төбәк бюджетлары акчаларын кушып, мәҗбүри уртак финанслауны алдан уйлап кую максатка ярашлы булыр иде. Үзара салым акчалары җирле салымга яисә җыемга әйләнергә тиеш түгел, чөнки әлеге акчалар ҖҮИ органнары эшчәнлеген финанслауга түгел, бәлки максатчан рәвештә муниципаль берәмлекләрнең конкрет проблемаларын хәл итүгә юнәлдерү өчен җыела.

5. ҖҮИнең икътисадый нигезен ныгыту өчен түбәндәгеләр таләп ителә:

физик затларның керемнәренә салымнан җирле бюджетларга күчерелә торган акчаларның даими нормативын арттырырга;

оешмалар мөлкәтенә салымнан муниципаль берәмлек бюджетына күчерелә торган акчалар нормативын билгеләргә, моны акчаларның әлеге мөлкәт урнашкан урындагы җирле бюджетка күчерелүен күздә тотып эшләргә;

транспорт салымын (аның физик затлар тарафыннан түләнә торган өлешендә) җирле салымнарга кертү һәм аннан кергән керемнәрне җирле бюджетка күчерү турындагы сорауны тикшерергә;

җирле салымнарны түләү буенча бирелә торган ташла-

маларны компенсацияләүне федераль бюджет, РФ субъектлары бюджетлары (тиешле ташламаларның кайсы дәрәҗәдә бирелүенә бәйле рәвештә) хисабына башкаруны билгеләргә;

мөлкәткә салым түләү вакытын 1 декабрьдән 1 октябрьгә күчерергә; гамәлдәге законнарда билгеләнгән срок (1 декабрь) җирле бюджетларның баланслылыгына тискәре йогынты ясый, ел дәвамында акчаларны куллануда тигезсезлек тудыра, муниципалитетның җыелма бюджетының керем өлешен үтәү буенча да, чыгым йөкләмәләрен вакытында башкару буенча да кыенлыклар тудыруга сәбәп булып тора;

РФ субъектларына төбәк бюджетына, җирле бюджетларга күчерелергә тиешле салым һәм җыемнардан алына торган акчалар буенча өстәмә (дифференсацияләнгән) нормативларын билгеләү мөмкинлеген бирергә; муниципаль районның ҖҮИ органнарына шәһәр һәм авыл җирлеге бюджетларына күчерелә торган салым булмаган керемнәрдән алына торган акча нормативларын билгеләү вәкаләтен бирергә;

РФ субъектлары һәм муниципаль берәмлекләренең вәкаләтләрен финанслар белән тәэмин итү нормативын яисә аны билгеләүнең методикасын ачыкларга;

муниципаль район органнарын җирле бюджетларны төзү һәм үтәүне оештыручы шәһәр һәм авыл җирлекләренә карата эчке муниципаль финанс контролен үткәрү буенча вәкаләтләрне тапшыру өлешендә Бюджет кодексының 265 нче маддәсенә үзгәрешләр кертергә;

131-ФЗ номерлы Федераль законда беркетелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә туры килүне тикшерү максатларында тармак федераль законнарында каралган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча каралган вәкаләтләргә инвентарьлаштыру үткәрергә;

ҖҮИ сорауларын җайлаучы законнар һәм норматив-хокукый актларның торышына мониторинг үткәрергә; аларның максаты – иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең әлеге сферасындагы хокукый кырдагы бушлыкларны, коллизияләрне һәм кимчелекләрне юкка чыгару, һәм шулай ук норматив-хокукый актларны вакытында әзерләү һәм кабул итү, иң беренче чиратта, аларны кабул итү федераль законнардагы тиешле нормаларында (сылтама нормаларында) каралган очракларда;


муниципаль дәрәҗәгә тапшырыла торган аерым дәүләт вәкаләтләренең максималь күләмен чикләүнең оештыру һәм финанс критерийларын билгеләү өлешендә РФнең аерым закон актларына үзгәрешләр кертергә;

территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, муниципаль берәмлек территорияләрен һәм халкын табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау буенча чараларны оештыруны һәм гамәлгә ашыруны дәүләт вәкаләтләренә кертергә һәм РФ дәүләт органнары тарафыннан тормышка ашырырга;

ҖҮИ органнарының берьяклы тәртиптә башкарыла торган җирле әһәмияттәге сорауларын хәл итү буенча ҖҮИ органнарының вәкаләтләрен яңадан бүлү муниципаль мөлкәтне, ҖҮИнең икътисадый базасын тәшкил иткән башка элементларны автоматик рәвештә тартып алуга китерергә тиеш түгел;

«Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 135-ФЗ номерлы Федераль законга муниципаль берәмлекләргә Салым кодексының 31 һәм 32 нче бүлекләре нигезләмәләренә таянып алынырга тиешле салым салына торган мөлкәтнең кадастр бәясенә карата ризасызлык белдерү мөмкинлеген бирү өлешендә үзгәрешләр кертүне күздә тотарга, чөнки җир кишәрлеге ияләре тарафыннан аның кадастр бәясен төшерү җир салымын, физик затлар милегенә салымны билгеләгәндә салым базасын шактый киметүгә китерергә мөмкин, әлеге ике салым да 100% күләмендә җирле бюджетларга күчерелә. Шул ук вакытта законнарда муниципалитет тарафыннан тиеш-

## ҖҮИ ОРГАННАРЫН ТИКШЕРҮНЕҢ ГОМУМИ САНЫ (56 субъект өчен)



ле дәгъва белдерү рөхсәт ителгән җир кишәрлегенең кадастр бәясен киметүдәге «шактыйга» төшенчәсен билгеләүнең төгәл критерийларын атарга кирәк;

«Күчемсез милеккә һәм аның буенча сделкаларга дәүләт теркәве турында» 122-ФЗ номерлы Федераль законда милек ияләренә закон тарафыннан билгеләнгән срокта күчемсез милекне дәүләт кадастр исәбенә кую һәм (яисә) күчемсез милеккә хокукка дәүләт теркәве үткәрү турында гариза китерү йөкләмәсен билгеләргә;

ызанлау планын һәм күчемсез милеккә хокукка дәүләт теркәве үткәрү өчен кирәкле башка документацияләр әзерләү буенча кадастр эшләрен финанслауны дәүләт хакимияте органнарына (җир мөнәсәбәтләрен хокукый көйләү эшен РФ һәм РФ субъектлары уртак алып барырга тиеш) йөкләргә кирәк;

131-ФЗ номерлы Федераль законның 11 нче маддәсе 1 нче өлеше 11 нче пунктыннан авыл җирлеге чикләрен барлык торак пунктлар халкы өчен эш көне дәвамында административ үзәккә җәяү бару һәм кайту мөмкинлеген исәпкә алып билгеләү таләбен юкка чыгарырга;

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 53 номерлы Федераль законның 8 нче маддәсенә хәрби комиссариат подразделениесе булмаган территорияләрдә хәрби исәпне алып бару вәкаләтен муниципаль районнарның ҖҮИ органнарына тапшыру мөмкинлеген күздә тоткан үзгәрешләр кертергә;

федераль законнарда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм исәпкә 2005 елның 1 гыйнварыннан соң баскан инвалидларга һәм инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләргә торак бирүнең анык тәртибен билгеләргә һәм әлеге чыгымнарны финанслау чыганагын ачыкларга;


шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларының максатчан чыгым маддәләренең исемлеген һәм кодларын төзү буенча Бюджет кодексының 21 нче маддәсе 4 нче өлешендә каралган хокукны составына әлеге җирлекләр кергән муниципаль районнарның финанс органнарына бирергә;

көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны җыюны һәм чыгаруны оештыру, һәм шулай ук ритуаль хезмәтләрен күрсәтү һәм күмү урыннарын карап тотуны оештыру буенча вәкаләтләрне авыл җирлеге дәрәҗәсенә тапшырырга, чөнки чынлыкта конкрет территорияләрне төзекләндерү кысаларында авыл җирлекләре җирле үзидарәләре органнары тарафыннан нәтиҗәлерәк хәл ителәләр;

6. Су һәм җылылык белән тәэмин итүнең аерым объектларын тапшыру бары тик концессион килешүләр буенча гына башкарылырга тиешлеге турындагы нигезләмәне законнардан («Су белән тәэмин итү һәм калдык суларны чыгару турында» 416 нчы ФЗ, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 190 нчы ФЗ) юкка чыгарырга, чөнки мондый чикләү, муниципаль берәмлекләрнең тармак законнарында аталган объектларга теркәлгән хокуклары булмау сәбәпле, ҖҮИ органнарының су белән һәм җылылык белән тәэмин итүне оештыру буенча вәкаләтләрен үтәргә мөмкинлек бирми.

7. Муниципаль берәмлекләрнең кайбер кооперация һәм интеграция формалары законнар дәрәҗәсендә һәрьяклап эшләнмәгән һәм системалы рәвештә беркетелмәгән яисә көйләнеп бетмәгән. Муниципальара хуҗалык җәмгыятьләрен төзү тәртибе, аларның аерым хокукый статусын исәпкә алып, өстәмә хокукый көйләүне таләп итә. Мондый җәмгыятьне гамәлгә куючыларның составы, аларның устав капиталларын формалаштыру тәртибе, уставта каралган эшчәнлеккә контрольлек итү ысуллары турындагы сорауларны закон дәрәҗәсендә хәл итәргә кирәк.

## СУД КАРАРЛАРЫН ҮТӘҮ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ АКЧАЛАРНЫҢ ЯКЫНЧА КҮЛӘМЕ, МЛРД СУМНАРДА (56 субъект өчен)






Фотолар «Казан шәһәре» МБнең матбугат хезмәтеннән алынды.

ХӘЗЕРГЕ ЗАМАНДА ЭРЕ ШӘҺӘРЛӘРНЕҢ БҮГЕНГЕСЕН ДӘ, КИЛӘЧӘГЕН ДӘ АНЫҢ КОЯШ АСТЫНДА ТОТКАН УРЫНЫН ТӨГӘЛ БИЛГЕЛӘМИЧӘ, КӨЧЛЕ ҺӘМ ЙОМШАК ЯКЛАРЫН БӘЯЛӘМИЧӘ, КИЛӘСЕ ДИСТӘ ЕЛЛАРГА АЛГАН ЮНӘЛЕШЕН АНАЛИЗЛАМЫЙЧА КҮЗАЛЛАУ МӨМКИН ТҮГЕЛ. 2030 ЕЛГА КАДӘРГЕ СТРАТЕГИЯНЕ КАБУЛ ИТКӘНДӘ, КАЗАН НИНДИ ЮЛ САЙЛАГАН? БУ ТУРЫДА «ТАТАРСТАНДА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ» ЖУРНАЛЫНА ШӘҺӘР МЭРЫ ИЛЬСУР МЕТШИН СӨЙЛӘДЕ.

# *Илсур МЕТШИН: «Казан – киләчәк драйверы»*

**– Стратегия-2030 буенча эш нидән башланды? Аның тарихы нинди?**

– Шәһәрнең 2015 елга кадәрге стратегик планлаштыру документы 2003 елда ук кабул ителде. Шул вакытта ук инде шәһәр хакимияте тарафыннан башкала халкының ихтыяҗларына һәм замана таләпләренә нигезләнгән төп үсеш юнәлешләре билгеләнгән иде. Безнең шәһәр өчен динамик үсештәге икътисад, тотрыклы кала мохите һәм шәһәрлеләрне туплаган бергәлек шундый таяну нокталары булды. 15 ел узды, һәм бүген Казанда Стратегия, аның аерым блокларын һәм юнәлешләрен гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән олы үзгәрешләр яхшы шәйләнә. Белүегезчә, куелган бурычлар гамәлгә ашты, кайбер бурычлар арттырып үтәлде, бүген Казан халыкның тормыш сыйфаты рейтингларында – Россия шәһәрләре арасында алдынгылар исәбендә. Стратегия-2015нең төп казанышы, Казанның төп җиңүе – шәһәрлеләр аңындагы үзгәрешләр. Бүген казанлылар шәһәр пространствосын камилләштерүгә юнәлтелгән хәрәкәтләрдә, проектларда һәм акцияләрдә актив катнаша.

Әлеге көч-куәтне без Казанның 2030 елга кадәрге Соци-

***Казанның социаль-икътисадый үсешендә өстенлекләрне сайлау критерийларның өч төркеменә таянды. Беренчесе – шәһәр халкы кыйммәтләре, икенче төркем – ТРның үсеш приоритетлары, өченчесе – дөньядагы алдынгы тәҗрибә һәм урбанистик кыйммәтләр. Стратегиянең 18 максатын билгеләдек, аларны республика Стратегиясенә яраклаштырып, көндәшлекнең 7 юнәлешенә аердык. Аларга ирешү өчен 42 бурыч тәкъдим ителде, һәркайсы буенча без, кыска һәм озак вакытка исәпләп, хәрәкәт итү юнәлешләрен төгәлләштердек, араларыннан иң мөһимнәре буенча башкарылу дәрәҗәсен контрольлек итү өчен индикаторлар урнаштырдык.***



***Әлеге көч-куәтне без Казанның 2030 елга кадәрге Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләгәндә кулландык. Стратегия советының дискуссияләр мәйданчыкларында, семинарларда, утырышларда шәһәрне үстерү вариантлары турында фикер алышуларга меңгә якын кеше – төрле тармакларда хезмәт куючы эшкуарлар, галимнәр, экспертлар җәлеп ителде. Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталындагы интернет-сораштыруда 845 кеше катнашып, үз тәкъдимнәрен кертте.***

аль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләгәндә кулландык. Стратегия советының дискуссияләр мәйданчыкларында, семинарларда, утырышларда шәһәрне үстерү вариантлары турында фикер алышуларга меңгә якын кеше – төрле тармакларда хезмәт куючы эшкуарлар, галимнәр, экспертлар җәлеп ителде. Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталындагы интернет-сораштыруда 845 кеше катнашып, үз тәкъдимнәрен кертте.

**– Татарстан Республикасы да үз Стратегиясен кабул итте. Әлеге ике документ үзара ничек яраша?**

– Республиканың 2030 елга кадәрге Стратегиясенең лейтмотивын глобаль көндәшлеккә сәләтлелеккә йөз тоткан үсеш юнәлеше билгели, ул алгарышлы үсеш темпларына ия һәм халыкара хезмәт бүленешендә тыгыз катнашучы төбәк буларак карала. Казанның 2030 елга кадәрге Стратегиясе дә республика документына синхронлаштырылган, ул Татарстанның флагман проектларын һәм бурычларын истә тотып һәм шуңа нигезләнеп эшләнгән, формасы белән дә, эчтәлеге белән дә аңа туры килә. Казанның төп стратегик максаты республика Стратегиясенә охшатып эшләнгән: башкала Россиянең алдынгы фәнни-укыту, инновацион һәм финанс эшчәнлеге үзәге булырга омтыла, республиканың смарт-икътисад хәрәкәтендә драйвер булып тора.

**– Болар теләкләр генәме, әллә ниндидер нигезе булган бурычлармы?**

– Әлбәттә, без боларны түшәмнән алып язмадык. Киләчәктәге уңыш факторлары һәм хәрәкәт итү юнәлешләрен сайлау өстенлекләрне, мөмкинлекләрне җентекләп анализлауга нигезләнде, шулай ук шәһәр өчен ихтимал булган тәвәккәллекләр дә исәпкә алынды. Бу анализ дөнья күләмендә, Россиядә һәм төбәкләрдәге тенденцияләр, перспективалар, тулаем алганда, Казанның үсеше өчен уңайлы шартлар тудыруын күрсәтте. Үз эченә иске традицион тармакларны да, икътисадый белемнәргә карый торган яңаларын да алган диверсификацияләнгән икътисады булган һәм кеше капиталын туплау ягыннан яхшы оеткыга ия Казанның тиз арада үсү өчен барлык мөмкинлекләре дә бар.
Казанның социаль-икътисадый үсешендә өстенлекләрне сайлау критерийларның өч төркеменә таянды. Беренчесе – шәһәр халкы кыйммәтләре, икенче төркем – ТРның үсеш приоритетлары, өченчесе – дөньядагы алдынгы тәҗрибә һәм урбанистик кыйммәтләр. Стратегиянең 18 максатын билгеләдек, аларны республика Стратегиясенә яраклаштырып, көндәшлекнең 7 юнәлешенә аердык. Аларга ирешү өчен 42 бурыч тәкъдим ителде, һәркайсы буенча без, кыска һәм озак вакытка исәпләп, хәрәкәт итү юнәлешләрен төгәлләштердек, араларыннан иң мөһимнәре буенча башкарылу дәрәҗәсен контрольлек итү өчен индикаторлар урнаштырдык.
Шәһәр халкының өстенлекләре арасында – куркынычсызлыкка ихтыяҗ, уңайлы җәмгатьчелек пространстволарының булуы. Территорияләрнең тигез үсүе әһәмияткә ия. Бу яшәү урыны кысаларыннан ерак китмичә генә буш вакытны уздыру, спорт белән шөгыльләнү өчен сайлау мөмкинлеген һәм инфраструктураның бер генә районда тупланмыйча, бөтен шәһәр буйлап тигез үсүен күздә тота.
Татарстан башкаласын икътисадый роле һәм махсуслашуы күзлегеннән караганда, шәһәр кешеләре Казанны 2030 елга Европа белән Азия арасындагы бәйләнешләр үзәге, белем бирү үзәге, кунакчыл шәһәр итеп күрәләр.
Республиканың 2030 елга кадәрге Стратегиясендә территорияләрнең роле өч агломерациягә беркетелгән: Казан, Әлмәт һәм Кама. Казан агломерация үзәге итеп карала, анда республика башкаласының әйдәп баручы роле, фәннибелем бирү, инновацион һәм финанс үзәге буларак, төп магистральләрнең радиаль элементләре белән ныгытыла.

**– Дөнья тәҗрибәсе шуны раслый: шәһәрнең алга таба үсеше өчен талантларны җәлеп итү һәм аларны үзебездә калдыру өчен шартлар кирәк...**

– Нәкъ менә шуның өчен дә без карьера үсеше, эшкуарлык, инвестицияләр өчен киртәләрне киметү; икътисадны, халыкара һәм төбәкара элементләрне диверсификацияләү; шәһәр кешеләрен идарә итүгә җәлеп итү кирәклеге турында сөйлибез.
Моннан тыш, безнең шәһәрнең көндәшлектәге өстенлеге – күпмилләтле һәм күпконфессияле булуы, шулай ук бай мультимәдәни мирасы. Көнчыгыш белән Көнбатышны, Европа белән Азияне бәйләп торучы традицион табигый күпер буларак, Казан Россия үсешендә яңа тышкы сәяси һәм тышкы икътисади бурычларны хәл итүдә мөһим роль уйнарга мөмкин.

Шәһәр җәмәгатьчелеге вәкилләре һәм белгечләр белән фикер алышулар нәтиҗәсендә без максатлы рәвештә сценарий сайлап алдык, аның беренче этабын гамәлгә ашыру Казанны 30нчы елда Мәскәү белән Санкт-Петербургка көндәш итеп күрүне күздә тота, алга таба этабы максатны 50нче елга билгели. Ул вакытта инде без Казанны дөньякүләм шәһәрләр җәмәгатьчелеге арасында итеп күрәбез.

Боларны гамәлгә ашыру үзгәреп торучан шартларга карата тиз арада җавап бирүне, стратегик идарә итүне ычкындырмауны, тырышлыкларның югары концентрациясен һәм шәһәр җәмәгатьчелеге белән килешкәнлекне күздә тота. Яңа Стратегияне эшләгәндә, шәһәрнең социаль-икътисадый үсешенең барлык аспектлары да өч юнәлештә каралды: «Кеше капиталы», «Икътисад һәм идарә», «Пространство». Алар төп өч сорауга җавап эзләүне күз уңында тота: Казан халкы 2030 елга нинди булыр, халык ни белән шөгыльләнер һәм алар нинди мохиттә яшәячәк?

**– Ягъни Стратегиядә һәрнәрсә кеше тирәсендә әйләнә?**

– Әлбәттә, кеше капиталын җәлеп итү һәм формалаштыру мәсьәләләре беренче урында тора. Сәламәт, укымышлы, актив кеше төп ресурс булып тора, алар өчен шәһәрләр, төбәкләр ярыша. Уңышлы көндәшлек өчен озак вакытлар сәламәт һәм актив булып калырга мөмкинлек тудыра торган төрле һәм сыйфатлы шәһәр мохитен булдыру кирәк. «Казан-2030 – сәламәтлек территориясе» проектының безнең эшчәнлектә өстенлекле булуы очраклы түгел. Ул спорт инфраструктурасының алга таба үсешен һәм сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү системасы сыйфатын камилләштерүне, җәмәгать урыннарын, шул исәптән күп хәрәкәтләнү мөмкинлеге булмаган гражданнар өчен дә уңайлы итеп ял һәм физик активлык зоналарын оештыруны үз эченә ала. Проектның максаты: 2030 елга Казанны Бөтендөнья сәламәтлек оешмасының алдынгы тормыш сыйфаты стандартларына һәм критерийларына яраклаштырып «сәламәтлек территориясенә» әйләндерү.

Әмма нинди генә инфраструктура булмасын, шәһәрдәге сәламәт климат, беренче чиратта, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр белән билгеләнә. Моңа бәйле рәвештә игътибарыгызны шуңа юнәлтәсем килә: «Игелекле Казан» проекты берничә елга гына түгел, озак елларга исәпләнгән. Объектлар төзергә дә эшне тәмамладык, дип хисап бирергә була. Ләкин игелек белән кешеләр арасындагы гамьле мөнәсәбәтләрне статистика белән генә күрсәтеп, алар буенча йомгак ясап булмый.

«Игелекле Казан»ның беренче адымнары ясалды инде – өлкән кешеләрнең кызыксыну даирәсенә карап, «Тормыш сөючеләр» клублары барлыкка килде, алар шәһәрнең барлык районнарында да бар. Без өлкәннәрнең тормышы чыннан кайнап торсын, тулыканлы булсын өчен барысын да эшләргә тиеш. Без пенсияләрне арттыра алмыйбыз, әмма муниципаль дәрәҗәдә олы яшьтә дә актив калу, шәһәр тормышында катнашу өчен шартлар тудыра алабыз.

«Икътисад» һәм «Кеше капиталы» юнәлешләре арасында «Мәгариф» бүлеге тора, Стратегиядә аңа зур игътибар бирелә. Казанның фәнни һәм уку-укыту потенциалы куәтле. Шәһәр Идел буе яшьләре өчен магнитка әйләнде инде, ирешелгәннәрне ныгытырга кирәк.



***«Административ киртәләр» дигән сүзтезмә 2030 елга архаизмга әйләнергә, шәһәр эшкуарларга гади, аңлаешлы һәм тулысынча үтә күренмәле эш кагыйдәләре һәм стандартлары тәкъдим итәргә тиеш. Нәтиҗәдә, 2030 елга шәһәр икътисадына инвестицияләр ике тапкырга артачак, тулай территориаль продукт күләмендә кече һәм урта эшкуарлыкның өлеше – 50 %ка кадәр, инновацион продукция күләме – 30 %ка кадәр, ә туристлар агымы күләме 5 млн кешегә җитәчәк.***

Шәһәр халкының һәм хакимиятләренең үзара хезмәттәшлеге балаларга мәктәптә һәм мәктәпкәчә белем бирү сыйфатын күтәрүгә юнәлтелергә тиеш. Мәгариф системасын бүген кертелгән инвестицияләр – иртәгә көндәшлеккә сәләтле икътисадка кертелгән инвестицияләр ул.

**– Сез эре предприятиеләр турында әйттегез. Стратегия кече һәм урта бизнеска нинди урын бирә?**

– Совет чорыннан ук эшләп килгән эре предприятиеләр бүген Казан икътисадының нигезен тәшкил итә, әмма



елдан-ел кече һәм урта бизнесның әһәмияте үсә бара. Кече һәм урта бизнес предприятиеләре Казанның тулай территориаль продуктының өчтән берен бирә.

Киләчәк икътисады актив рәвештә заманча технологияләрне кулланып, өстәмә хак өлеше югары булган һәм үзмәшгульлек нигезендә эшләп, инновацион продукция чыгаручы зур булмаган диверсификацияләнгән җитештерүләргә таба хәрәкәт итә.

2030 елга без Казанны яңа икътисадлар һәм технологик башлангычлар форсайты урыны итеп күрәбез, WorldSkills-2019 бирәчәк мөмкинлекләрне исәпкә алып, чиктәш һөнәри компетенцияләр урыны итеп күрсәтәбез. «Административ киртәләр» дигән сүзтезмә 2030 елга архаизмга әйләнергә, шәһәр эшкуарларга гади, аңлаешлы һәм тулысынча үтә күренмәле эш кагыйдәләре һәм стандартлары тәкъдим итәргә тиеш.

Нәтиҗәдә, 2030 елга шәһәр икътисадына инвестицияләр ике тапкырга артачак, тулай территориаль продукт күләмендә кече һәм урта эшкуарлыкның өлеше – 50 %ка кадәр, инновацион продукция күләме – 30 %ка кадәр, ә туристлар агымы күләме 5 млн кешегә җитәчәк.

Югары кеше капиталының, төзекләндерелгәнлекнең Европа дәрәҗәсе һәм җир, хезмәт хаклары, хезмәт күрсәтүнең чагыштырмача түбән дәрәҗәсенең уникаль катнашмасы белән Казан әлеге вазгыятьне безнең икътисадка көндәшлекле шартларда керү өчен федераль һәм халыкара дәрәҗәдәге компанияләр өчен магнит итеп файдаланырга омтыла. Берлинга ияреп болай дияргә була: «Без бай түгел, әмма җәлеп итәбез». Бүген үк инде безнең шәһәрдән бөтен Россиягә Росреестр белән Кадастр палатасының колл-үзәкләре эшли, Россия Почтасының логистика үзәге безгә күчеп килде, «АйСиЭл-КПО ВС» ИТ-компаниясе бөтен дөньядан йөзләрчә заказчыны читтән торып хезмәтләндерә. Икътисадны «культурация»ләү бара, ул креатив индустрияләрне үстерү белән бәйле: Казанда беренче булып гамәлгә ашырыла торган мәгълүмати технологияләрдән башлап, оупен-спейслар, коворкинглар һәм «ЭдМи» (AdMe) кебек федераль дәрәҗәдәге интернет-проектларга кадәр.

Алдагы этапта яңа акыллы икътисадта югары түләүле эш урыннарын булдырганнан соң, без шәһәр халкының тормыш сыйфатын һәм керемнәренең үсүен күрәбез, ТТПны кеше башына 75 %ка үстерергә планлаштырып, торак белән тәэмин ителешне бер кешегә 30,5 кв. метрга җитүенә һәм халыкның керемен ике тапкырга артуына йөз тотабыз.




**– Җәмәгать урыннарын үстерү буенча Стратегиядә тагын нинди чаралар каралган?**

– Башта шуны билгелисем килә: соңгы елларда Казанның шәһәр мохитендә уңай үзгәрешләр күп булды. Шәһәрне яшелләндерүдә, парклар һәм скверларны яңартуда, яр буйларын төзекләндерүдә һәм яңа җәмәгать урыннары булдыруда шәхси-дәүләти партнерлыкның роле зур. Шуңа карамастан, яшелләндерү дәрәҗәсе һәм җәмәгать урыннарының саны, транспорт белән тәэмин ителеш ягыннан без дөньядагы лидер-шәһәрләрдән, шулай ук Мәскәү белән Санкт-Петербургтан калышабыз.

Стратегиядә җәяү үтә торган бердәм яшел каркас булдыру һәм шәһәр өстенлекләрен үзгәртү – шәхси автомобильдән уңайлы җәмәгать транспортына күчү планлаштырыла. Без яшеллекнең шәһәр мәйданындагы өлешен 40 %ка җиткерергә тиеш.

**– Шәһәр үзеген ни көтә? Аны үзгәртеп корырга кирәкме, кирәк икән, ничек итеп?**

– Безнең тикшеренүләр күрсәткәнчә, Казан чынлыкта җиде шәһәр-районнан тора, һәркайсының үзенә генә хас үзенчәлеге бар. Шуңа да 2030 елга максат һәм бурычларны куйганда, без күпүзәкле шәһәр моделенә басым ясадык. Безнең караулы, төзек үзәктән тыш локаль үзәкләр челтәрен булдырырга, шулай ук тарихи үзәктән сәнәгать предприятиеләрен чыгару эшен дә дәвам иттерергә кирәк. Казан инновацияле шәһәр мәдәнияте үсешенә йөз тота, яңа идеяләр, продуктлар һәм технологияләр булдырыла, капиталга әйләндерелә торган белемнәр икътисадын формалаштыруга ставка ясый. 2030 елга креатив индустрияләр – интернет һәм компьютер технологияләре, кино, башкарма сәнгать, музыка, сынлы сәнгать, галерея бизнесы, мода, нәшрият эше, реклама, дизайн, архитектура, мәдәни туризм – Казанның тулай территориаль продуктының 12 %н һәм эш урыннарының гомуми саныннан 15 %ны тәшкил итәргә тиеш.

**– Казан кебек мегаполис гармонияле төстә үсешкә ирешәсе килсә, күрше районнар һәм шәһәрләр белән дә хезмәттәшлек итми кала алмый. Стратегиядә моны да исәпкә алдыгызмы?**

– Әлбәттә. Безнең һәм Казан агломерациясен формалаштыручы районнарның җилкәсенә йөкләнгән бурыч шундый: агломерациянең күпфункцияле структурасын һәм бердәм бәйләнешле пространство булдыру. Безнең стратегия бердәм планлаштыруны күздә тота, шул исәптән инде бүген Казаннан читтә барган торак төзелешен дә искә алып, агломерациянең транспорт системасын да, җәмәгать транспортына басым ясап, юллар төзелешен дә.

Моннан тыш, без үз алдыбызга рекреацион зоналарны саклау һәм бүлеп калдыру, экологик яктан чиста авыл хуҗалыгы җитештерүләре үсешенә булышлык итү һәм Казан халкына арадашчылардан башка гына Татарстан фермерларының продукциясен китерүнең тотрыклы коридорын җайлау бурычларын да куябыз.

Стратегия-2030га ярашлы, Казан – киләчәк драйверы улы. Казанны дөнья шәһәрләре дәрәҗәсенә чыгару иң яхшы үрнәкләргә иярүне һәм үзләре яшәгән шәһәрне яраткан һәм якты киләчәкне якынайтуда катнашырга әзер булган казанлыларның активлыгына таяна торган муниципаль идарәнең яңа практикаларын булдыруны күздә тота.



Вахит ШӘРИПОВ тексты.

# БАШКАЛА: бүген һәм иртәгә

РОССИЯ КИҢЛЕКЛӘРЕНДӘ КАЗАННЫҢ МЕГАПОЛИС БУЛАРАК ӘҺӘМИЯТЕ ЗУРМЫ? ШУНЫ АЧЫКЛАП КАРЫЙК ӘЛЕ. СУГЫШТАН СОҢГЫ ЕЛЛАРДА УК, КАЗАН ӘЛЕ УЛ ВАКЫТТАГЫ ИКСЕЗ-ЧИКСЕЗ ИЛНЕҢ БАШКА ШӘҺӘРЛӘРЕННӘН ӘЛЛӘ НИ АЕРЫЛЫП ТОРМАСА ДА, АКШТА СОВЕТЛАР СОЮЗЫНА КАРШЫ 1945 ЕЛДА ТӨЗЕЛГӘН БЕРЕНЧЕ СУГЫШ ПЛАНЫНА («TOTALITY») ЯРАШЛЫ РӘВЕШТӘ, УЛ СССР ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘГЕ АТОМ БОМБАСЫНА ТОТЫЛЫРГА ТИЕШЛЕ ЕГЕРМЕ ӨСТЕНЛЕКЛЕ МИШЕНЬ ИСЕМЛЕГЕНӘ КЕРТЕЛГӘН, АННАН СОҢГЫ ПЛАННАРГА ДА КЕРТЕЛМИ КАЛМАГАН. ШУННАН СОҢ УЗГАН ДӘВЕР ЭЧЕНДӘ КАЗАН ХАЛЫК САНЫ БУЕНЧА ИЛДӘ АЛТЫНЧЫ УРЫНГА КҮТӘРЕЛДЕ ҺӘМ ҖЫЕЛМА КҮРСӘТКЕЧЛӘР БУЕНЧА РӘСМИ БУЛМАГАН «РОССИЯНЕҢ ӨЧЕНЧЕ БАШКАЛАСЫ» СТАТУСЫН АЛДЫ. ӘЛЕГЕ ДӘРӘҖӘ ӨЧЕН ТҮБӘН НОВГОРОД БЕЛӘН ЯРЫШКАНДА, ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫ ФАЙДАСЫНА ИҢ САЛЛЫ ДӘЛИЛЛӘРНЕҢ БЕРСЕ – «1738 ЕЛГЫ ҖАНИСӘП АЛУ МӘГЪЛҮМАТЛАРЫ БУЕНЧА, КАЗАН РОССИЯДӘ ИҢ ЗУР ШӘҺӘР САНАЛА – АНДА 200 МЕҢГӘ ЯКЫН КЕШЕ ЯШИ», ДИГӘН МӘГЪЛҮМАТ БУЛА.

***Әйе, Россия бюджеты Казанның 1000 еллыгына, 2013 елгы Универсиадага шактый акча бүлде, федераль үзәк футбол буенча дөнья чемпионатына һәм WorldSkills-2019 чемпионатына әзерлек барышында да ярдәм итә. Әмма казанлылар үзләре дә шәһәрне үзгәртүгә күп көч куйды. Хәзер исә, үсеш тәгәрмәче бер әйләнә башлагач, иң зур Россия агломерацияләреннән берсе булган Казан кече һәм урта шәһәрләргә, «йоклаган» төбәкләргә караганда күпкә тизрәк үсүдән туктый алмый инде. Кеше саны миллионнан арткан шәһәрләрнең барысында бергә Россия халкының 21%ы яши, аларның эчке төбәк продуктындагы өлеше исә аз кешеле калаларга караганда күпкә зуррак. Миллионнан артык халык яшәгән шәһәрләр ТТП күләме буенча да илнең күп кенә төбәкләреннән алда бара.***

## МЕНӘ БУ БУРЫЧ ИЧМАСА...

«Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең 2030 елга кадәрге социаль-икътисадый үсеш стратегиясенең» барлык бүлекләре белән танышканнан соң, мин таң калдым. Республиканың 20 мең кеше яши торган һәм миллиард ярым сумлык тулай продуктлы район масштабындагы уртача муниципаль берәмлегенең үсешен планлаштыру бер хәл булса, миллион ярым халыклы һәм 630 миллиард сумлык тулай төбәк продуктлы башкала агломерациясенең перспективаларын фаразлау исә бөтенләй башка масштабларда эш йөртүне таләп итә бит... Киләчәктәге үсешнең төп триггерын ачыклау өчен никадәр мәгълүмат җыярга, анализларга һәм өйрәнергә кирәк! Һәм бу әле объектив, дәлилләнгән һәм ышандырыгыч та булырга тиеш. Шунлыктан мине мондый саннар бер дә гаҗәпләндермәде...

«80 нән артык чара (аралашу мәйданчыклары, интервьюлар, методологик семинарлар, Казан шәһәре Башкарма комитеты бүлекләре һәм Казан шәһәр Думасы депутатлары белән фикер алышулар, Стратегик совет утырышлары) үткәрелде, аларда 600 дән артыграк кеше катнашты. Шәһәрнең үсеш перспективалары һәм проблемалары турында 800 дән артыграк тезис, 200 дән артык проект идеясе теркәлде. Өйрәнү кысаларына берничә социологик сораштыру һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнары рәсми порталында 800 кеше катнашында үткән интернет-сораштыру нәтиҗәләре дә кертелде. Мәйданчыклардагы эш барышы алдарак күрсәтелгән рәсми порталда яктыртылды һәм 55 мәгълүмати хисапта чагылдырылды. Әлеге эш нәтиҗәсендә «Стратегия» тексты гына түгел, бәлки экспертлар дискуссияләре, мониторинг һәм халыкны сораштыру нигезендә тупланган мәгълүматлар һәм фикерләр базасы да булдырылды». Әйтергә кирәк, бу – гаять күп көч таләп итә торган, бинидһая зур хезмәт.

«Экспертлар төркемнәре 2016 елның март-июнендә атна саен берничә тармакта «Шәһәр төзелеше», «Икътисад», «Мәгариф», «Кече һәм урта бизнес», «Социаль сфера», «Транспорт инфраструктурасы», «Сәламәтлек саклау» һ.б. кебек темаларга проект мәйданчыклары үткәрде. Процесска төрле тармак экспертлары, бизнес вәкилләре, компетентлы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр, студентлар җәлеп ителде».

Болар барысы да таратып салынган пасьянсны хәтерләтә – нәрсәләребез бар һәм аларны нишләтеп була? Ә боларның барысыннан да иң мөһимен аерып алырга кирәк – «хәзинә» кайсы юнәлештә һәм кайсы тармак-сфераларда яшерелгән? Кыскасы, шәһәрнең һәм аның халкының муллыгына илтә торган юл кайсы юнәлештә ята?

Сүз уңаеннан, 2003 елда стратегик планлаштыруның беренче документы – «югары үсештәге җәмәгать институтлары бердәмлегенә ия, динамикага, нәтиҗәлелеккә ия икътисады, халкы өчен чиста һәм рәхәт яшәү мохите булган, тигез мөмкинлекле, гөрләп үскән, уңайлы шәһәр булдыруга» юнәлтелгән «Казанның 2015 елга кадәрге үсеш стратегиясе» кабул ителгән иде. Ул күпкә арттырып үтәлде, «Россиянең өченче башкаласы» исеменә лаек булу – моңа ышандыргыч дәлил. Әлеге статус белән хәзер беркем дә бәхәсләшми, бу бәйгедә Казанның көндәшләре булган Екатеринбург, Самара, Түбән Новгород, Краснодар, Ростов халкы, башкалабызны күргәннән соң: «Хәзер инде сезне куып тотып булмый! Кремльнең дә бер шәһәргә бирер өчен шулкадәр миллиардлары юк, вазгыять тамырдан үзгәрде, сез «симез» елларның соңгы вагонына утырырга өлгердегез», – дип уфтана.

Бу гыйбарәләрендә икътисад теорияләреннән ерак торган гади халык Казанның алгарышлы үсешен интуициясе белән тоепраслый. Әйе, Россия бюджеты Казанның 1000 еллыгына, 2013 елгы Универсиадага шактый акча бүлде, федераль үзәк футбол буенча дөнья чемпионатына һәм WorldSkills-2019 чемпионатына әзерлек барышында да ярдәм итә. Әмма казанлылар үзләре дә шәһәрне үзгәртүгә күп көч куйды. Хәзер исә, үсеш тәгәрмәче бер әйләнә башлагач, иң зур Россия агломерацияләреннән берсе булган Казан кече һәм урта шәһәрләргә, «йоклаган» төбәкләргә караганда күпкә тизрәк үсүдән туктый алмый инде. Кеше саны миллионнан арткан шәһәрләрнең барысында бергә Россия халкының 21%ы яши, аларның эчке төбәк продуктындагы өлеше исә аз кешеле калаларга караганда күпкә зуррак. Миллионнан артык халык яшәгән шәһәрләр ТТП күләме буенча да илнең күп кенә төбәкләреннән алда бара.

## КИЛӘЧӘК «ЭЛЬДОРАДОСЫ» КАЙДА?

Киләчәк сандыгының ачкычы «Стратегиянең» менә бу юлларына яшерелгән: «XXI гасыр башы Казан өчен пост индустриаль икътисад торгызыла башлау чорына әйләнде». Безнең көннәрдә «постиндустриаль» термины бары тик «мәгълүмати технологияләр» һәм «инновацион икътисад» төшенчәләре белән генә төрләнә. Без биредә дә репер нокталарын бик вакытлы ныгытып калырга өлгердек. Казанда инновацион икътисадны Россиядә иң зур ИТ-парк, шулай ук Европада иң зурлардан берсе булган «Идея» технопаркы гәүдәләндерә. 2016 елгы Мәскәү урбанистика форумы (URBAN INDEX MUF'16) тикшеренүе буенча, Россиядәге миллионлы шәһәрләр арасында Казан бәяләүнең өч

***Тормыш сыйфаты буенча Казан Мәскәү һәм Санкт-Петербургны артта калдырды, бу РФ Хөкүмәте каршындагы Финанс университетының 2017 ел нәтиҗәләре буенча хисабыннан күренә. Россиянең зур һәм уртача зурлыктагы шәһәрләрендә 2017 елдагы яшәү сыйфатын бәяләү халык фикеренә нигезләнә. Бәяләү критерийлары: медицина хезмәте күрсәтү сыйфаты; юллар һәм юл хуҗалыгы; мәдәният һәм мәгариф; торак хуҗалыгы; шәһәр хакимияте эше. 2017 елда Россиянең зур һәм уртача зурлыктагы шәһәрләрендәге тормыш сыйфаты интеграль индексы буенча, Төмәннән (100 балл) һәм Грозныйдан (99 балл) гына калышып, Казан 93 балл җыйды. Мәскәүнең нәтиҗәсе – 75 балл, Төньяк башкаланыкы – 85 балл.***



юнәлешендә дә – шәһәр мохите торышы, идарә сыйфаты һәм максатчан төркемнәрнең канәгатьлеге дәрәҗәсе – беренче урында тора.

Ә менә болары быелгы гыйнвар яңалыклары: «Тормыш сыйфаты буенча Казан Мәскәү һәм Санкт-Петербургны артта калдырды, бу РФ Хөкүмәте каршындагы Финанс университетының 2017 ел нәтиҗәләре буенча хисабыннан күренә. Россиянең зур һәм уртача зурлыктагы шәһәрләрендә 2017 елдагы яшәү сыйфатын бәяләү халык фикеренә нигезләнә. Бәяләү критерийлары: медицина хезмәте күрсәтү сыйфаты; юллар һәм юл хуҗалыгы; мәдәният һәм мәгариф; торак хуҗалыгы; шәһәр хакимияте эше – шәһәр хакимиятенә йогынты ясау мөмкинлеге, хакимиятнең шәһәр муллыгына керткән өлешен бәяләү, каладагы коррупция дәрәҗәсе. Мәгълүматлар социологик сораштырулар ярдәмендә туплана.


2017 елда Россиянең зур һәм уртача зурлыктагы шәһәрләрендәге тормыш сыйфаты интеграль индексы буенча, Төмәннән (100 балл) һәм Грозныйдан (99 балл) гына калышып, Казан 93 балл җыйды. Мәскәүнең нәтиҗәсе – 75 балл, Төньяк башкаланыкы – 85 балл».

## ПЛАННАН УЗЫП

Кайвакыт тормыш «Стратегия» планнарында каралмаган үзгәрешләрен дә кертә. Моңа ачык мисал – РФ Президенты В.Путинның Казанга килүе. Дәүләт башлыгы Ту-160М2 стратегик бомбардировщигының сынау очышын күзәтте. Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе (БАК) президенты Юрий Слюсарь БАКнең Казандагы төп проекты «Туполев» ГАҖ филиалы – Горбунов исемендәге Казан авиазаводында Ту-160 самолетын җитештерүне яңадан торгызу булачагын хәбәр итте. Слюсарь әйтүенчә, предприятие БАКнең үсеш стратегиясендә «стратегик авиация үзәге» буларак расланган. Корпорация президентыннан тагын бер яхшы яңалык: ерак авиациянең перспективалы авиация комплексын (ЕА ПАК) Казанда төзеячәкләр (элегрәк башка предприятиеләрне, мәсәлән, Иркутск авиация заводын да сайларга мөмкиннәр, дигән сүз йөргән иде). Юрий Слюсарь сүзләренә караганда, хәзер Ту-160М2 самолетына кертелә торган инвестицияләр «киләчәктә ЕА ПАК та да эшләячәк җитештерү моделе» өчен нигез булачак. Әмма бу әле 2027 елдан соң гына гамәлгә кертеләчәк.

Бер көннән соң исә Казан аэропортында «Россия почтасының» Идел буенда иң зур логистика үзәге ачылды, ул Кытайдан килгән посылкаларны кабул итәчәк, ягъни бөтен интернет онлайн сәүдәсенә хезмәт күрсәтәчәк. Нәтиҗә буларак – киләчәктә меңләгән эш урыны булдыру, һәм бу сан елдан-ел арта гына барачак.

Күнегелгән «Казан – Россиянең иң динамик үсешле шәһәре» гыйбарәсе генә хәзер инде беркемне дә канәгатьләндерми. Аңардан күбрәк нәрсә көтәләр, һәм гомумроссия форматында Казанны бәяләү критерийлары бик югары. Кемгә күп бирелгән, аңарга карата таләпләр дә катгыйрак. Мәсәлән, Татарстан башкаласында балаларның 75 %ы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре белән тәэмин ителгән, бу Россия дәрәҗәсеннән (63%) 12 %ка югарырак. Казанлыларның уртача гомер озынлыгы 73,6 ел, бу Россия буенча уртача күрсәткечтән югарырак. Казанда пассажирларның 76 %ы транспортта йөргән өчен электрон билетлар (яки транспорт карталары) белән түли, бу да башка миллионлы шәһәрләрдәгедән югарырак күрсәткеч. Соңгы ун ел эчендә шәһәрдә теркәлгән автомобильләр саны икеләтә арткан, һәм бүген 1 мең казанлыга 313 берәмлек машина туры килә, Россиядә исә әлеге күрсәткеч 293 берәмлеккә тәңгәл. Казанлыларның спорт корылмалары белән тәэмин ителеше дә югарырак, ә сәүдә биналары,



кибетләр, эш бизнес-үзәкләре саны буенча Казан Мәскәү белән Питердан гына калыша. The Calvert Journal басмасы махсус хисабы буенча, Казан 2016 елда Россиянең креатив шәһәрләре рейтингында беренче урынга куелган.

## ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘР

Республика хакимиятенең уңышлы сәясәте нәтиҗәсендә Казанда инновацион эшчәнлеккә ярдәм күрсәтә торган учреждениеләрдән инновацияләр экосистемасы каркасы төзелгән. Беренче чиратта, бу технология парклары һәм бизнес-инкубаторлар. Инновацион инфраструктура мәйданчыкларының күбрәк өлешен резидент предприятиеләр арендалый; соңгы елларда аларның кереме арта. Фәнни-тикшеренү һәм инновацион проектларны хуплап конкурслар оештыру һәм үткәрү системасы төзелгән; кече һәм урта бизнеска да билгеле бер ярдәм күрсәтелә. Мәсәлән, «Химград» технополисы – Казанның төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан заманча индустриаль парк. Проектка кертелгән дәүләт инвестицияләренең гомуми күләме 1,8 миллиард сум тәшкил иткән. 2007 елдан 2017 елга кадәр хосусый инвестицияләрнең тулаем күләме 18,2 миллиард сум тәшкил иткән. Шул рәвешле, дәүләт инвестицияләре мультипликаторы 10,1гә тәңгәл. Хосусый инвесторлар инде төзелгән бина һәм корылмаларны реконструкцияләүгә, бизнес-проектларын гамәлгә ашыру өчен технология линияләрен һәм үз объектларын төзүгә акча кертә.

Барлыгы 7878 кеше эшләгән 280 нән артык компания технополис резиденты булып тора, алар аз тоннажлы химия, полимерлар эшкәртү, нанотехнологияләр, ресурсларны саклау һәм энергетик нәтиҗәлелек, медицина технологияләре өлкәләрендә хезмәт куя.

2007 елдан 2017 елга кадәр чорда «Химград» резидентлары барлыгы 130,9 миллиард сумлык товар продукциясе җитештергән, төрле дәрәҗәдәге бюджетларга 16,9 миллиард сум салым түләгән. 2017 елның ноябрендәге күрсәткеч буенча, технополис резидентларының тулаем продукция күләме 23 миллиард сум, төрле бюджетларга салым суммасы 2,8 миллиард сум тәшкил иткән. Шул рәвешле, нәтиҗәлелек 1 эшләүчегә 1,92 миллион сумга тәңгәл.


Бу җәһәттән мин Казанның «Стратегия-2030» планында беренче тапкыр «шәһәр халкының кыйммәтләре» термины белән очраштым. Авыл муниципаль җирлекләренең бер эшләүчегә берничә йөз мең сум нәтиҗәлелек туры килә торган күрсәткечләрен башкала агломерациясендә яшәүченең нәтиҗәлелеге белән чагыштырыгыз – бик зур аерма булуы күренә. Мин шулай ук «үсә барган билгесезлек шартларында киләчәкне шундый итеп планлаштырырга кирәк ки, яшәүчәнлек – стресс һәм тетрәнүләр шартларында аерым затлар, бергәлекләр һәм системаларның яраклашу, исән калу һәм үсү, шартлар таләп иткәндә хәтта үзгәрү сәләтен формалаштырырлык булсын» төшенчәсен дә беренче тапкыр очраттым.

Шәһәр үсеше «Стратегиясен» өйрәнеп, мин мондый нәтиҗәгә килдем: «Казанның 2030 елга кадәр үсеше планы – өстәлдәге көндәлек белешмә, аның буенча үзеңнең киләчәккә адымнарыңның дөреслеген тикшерергә була».

Казан идарәчеләре дөньякүләм тенденцияләр белән таныш һәм җиһанның әйдәп баручы шәһәр планлаштыручылары – Greencity (Яшел шәһәр), Resiliencecity (Тотрыклы шәһәр), Globalcity (Глобаль шәһәр), Smartcity (Акыллы шәһәр) стилистикасын белеп файдалана... Ягъни «Казан, дөнья шәһәрләре шкаласы буенча өскә күтәрелүен дәвам итеп, Россия һәм халыкара дәрәҗәдә үзенең икътисадый йогынтысын көчәйтеп, үз позицияләрен яхшыртырга ниятле һәм әзер».




**35,8 млн тонна нефтьне Татарстан нефтьчеләре узган елда чыгарганнар (2016 ел белән чагыштырганда 101%).** Шул исәптән аның 28,5 млн тоннасы – «Татнефть» өлешенә, 7,2 тоннасы кече компанияләргә туры килгән. Республикада Россия нефте күләменең 6,5 %тан артыграгы табыла. Россиядә нефть табу күләме узган ел 546,7 млн тонна, ягъни 2016 ел белән чагыштырганда, 99,9 %ны тәшкил иткән.




**3,04 млрд сум акча узган ел Татарстанда дәүләт сатып алуларында янга калдырылган.** Бу турыда ТР Сатып алулар буенча дәүләт комитеты җитәкчелеге хәбәр итә. Бердәм мәгълүмат системасы белдерүенчә, республика заказчылары тарафыннан гомуми бәясе 127,6 млрд сумлык сатып алулар турында хәбәр ителгән. Шул исәптән муниципаль заказчылар тарафыннан хәбәр ителгән сатып алуларның гомуми суммасы 31 млрд сумнан артып китә.



**350 млрд сум – 2017 елда Татарстанда төзелеш күләме әнә шулкадәр суммага башкарылган.** Бу – республиканың тулай төбәк продуктыннан 9 %ны тәшкил итә. Шул ук вакытта Татарстан Идел буе федераль округында төзелеш локомотивларының берсе булып кала: И(б)ФО төбәкләре арасында ТРндагы төзелеш эшләре күләменең өлеше – 21,6 % (халык саны – 13,1 % тәшкил иткәндә).



**2 млн 403 мең кв. метр – 2018 елда торак төзелеше программасы буенча салынырга тиешле йортларның гомуми мәйданы әнә шуның кадәр булачак.** Нәтиҗәләр күрсәткәнчә, 2017 елда республикада 2 млн 408,1 кв. метр мәйданда торак йортлар төзелгән (ел бурычыннан 100,3 %). Федераль үзәк каршында торакны куллануга тапшыру буенча алынган барлык йөкләмәләр тулысынча үтәлгән.



**995 күпфатирлы йортка – аларның мәйданы 5,3 млн кв. метр тәшкил итә – 2018 елда капиталь ремонт ясалачак.** 224 меңнән артык гражданның торак шартларын яхшырту күздә тотыла. Программаны финанслау күләме – 6 млрд 76 млн сум.

**1,2 трлн сумнан артыграк – Татарстан нефть-газ комплексы предприятиеләре 2017 елда төяп-озаткан продукциянең бәясе әнә шул сумманы тәшкил иткән.** Комплексның база предприятиеләрендә бер кешегә уртача 14,5 млн сум күләмендә эш башкарылган. Төрле дәрәҗәдәге бюджетларга 272 млрд сумнан артыграк акча күчерелгән, аларның 58 млрд сумы – республиканың консолидацияләнгән бюджетына. Федераль бюджетка һәм бюджеттан тыш фондларга күчерелгән акчалары – 1,5 тапкырга, Татарстан бюджетына күчерелгәне 13 %ка гына арткан.



**260 млрд сум (үсеш – 5,1%) – 2017 ел нәтиҗәләре буенча Татарстанның тулай авыл хуҗалыгы продукциясе күләменең бәясе.** Авыл хуҗалыгында уртача хезмәт хакы узган ел 12 %ка арткан һәм якынча 21 мең сум тәшкил иткән.



**28 гомумбелем бирү мәктәбе (16 муниципаль һәм 12 коррекцион) 2018 елның белем бирү объектларын капиталь ремонтлау программасына кертелгән.** Финанслау күләме – 732,7 млн сум. Моннан тыш, 1 млрд 743,7 млн сумга 85 мәктәпкәчә яшьтәгеләргә белем бирү оешмасына ремонт ясалачак.



**120 амбулатория-дәваханә оешмасы бинасы 2018 елга республиканың капиталь ремонт программасына кертелгән.** Башкарыласы эшләрнең бәясе 3 млрд 195,7 млн сум тәшкил итәчәк. Әйтик, Казанда 21 амбулатория-дәваханә ошмасы бинасына, Яр Чаллыда – 15 бинага, Түбән Камада – 6 бинага, Әлмәттә 4 бинага капиталь ремонт ясау каралган. Программага республика муниципаль районнарындагы 74 дәваханә бинасы кергән.



**677 млрд сум, ТР Инвестицион үсеш агентлыгы бәяләвенчә, 2017 елда республика предприятиеләренең төп капиталына кертелгән булган.** Аның 59 %ы – җирле предприятиеләрнең үз акчалары, 41 %ы – җәлеп ителгән акчалар. Инвестицияләрнең зур өлеше эшкәртүче сәнәгатькә, авыл хуҗалыгына һәм төзелешкә кертелгән.





ЯР ЧАЛЛЫ ӨЧЕН 2017 ЕЛ ТАРИХКА ШАКТЫЙ УҢЫШЛЫ ЕЛ БУЛАРАК КЕРЕП КАЛАЧАК: АВТОКАЛА ИКЪТИСАДЫ ДИНАМИК ҮСЕШТӘ, АЛГАРЫШЛЫ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШ ТЕРРИТОРИЯСЕ (АСИҮТ) ТЕМПЛАРЫН АРТТЫРА, ЯҢА СОЦИАЛЬ-МӘДӘНИ ОБЪЕКТЛАР ТӨЗЕЛӘ, КИҢ МАСШТАБТА ЮЛЛАР ТӨЗЕКЛӘНДЕРЕЛӘ. ШӘҺӘРДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН БАРЛЫК ПРОГРАММАЛАР (ФЕДЕРАЛЬ, РЕСПУБЛИКА ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ) БУЕНЧА ЯР ЧАЛЛЫГА ӨСТӘМӘ РӘВЕШТӘ 8 МЛРД СУМНАН АРТЫК АКЧА ҖӘЛЕП ИТЕЛГӘН, БУ ШӘҺӘРНЕҢ ЕЛЛЫК БЮДЖЕТЫ БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРЫРЛЫК.

# *АЛГАРЫШЛЫ үсешкә ия кала*

Яңа инвесторларны Чулман ярындагы шәһәргә нәрсә җәлеп итә, алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе статусын алган шәһәр эшчәнлегенең төп нәтиҗәләре нинди, кала җитәкчелеге нинди үсеш юнәлешләрен алга сөрә – басмабызга биргән эксклюзив интервьюсында Яр Чаллы мэры Наил Мәһдиев шул турыда сөйләде.

**– Наил Гамбәрович, 2030 елга кадәрге перспективада Яр Чаллының үсеш Стратегиясендә төп өстенлекләрдәнниләрне атар идегез? Шәһәрнең үзенчәлекләре нәрсәдә, республика һәм гомумән ил күләмендәге көндәшлекле инвестицион пространствода алга китү өчен аларны ни рәвешле кулланырга мөмкин?**

– Яр Чаллы шәһәре «КАМАЗ» автогиганты кебек бөтенсоюз удар төзлеше елларында ук илебезнең төрле почмакларыннан яшь, амбициоз, кыю һәм креатив кешеләрне тарту үзәгенә әверелә. Аларга чип-чиста кырда бүген без яшәгән матур каланы төзү насыйп була. Бүген Яр Чаллы ярты миллион кеше яши торган матур калага әверелде, ләкин шулай да элеккеге кебек үк актив һәм эшлекле халык яши торган шәһәр булып кала.

2030 елга кадәрге шәһәр үсеше Стратегиясе турында сөйләгәндә, без аны республика муниципалитетлары арасында беренче булып һәм ил буенча да беренчеләр арасында 2016 елның 7 апрелендә раславык. Стратегия территориянең комплекслы үсешен күз уңында тота. Киләчәк моделен читтән тагып булмый. Бары тик үз үзенчәлеген табуга эчке ихтыяҗ гына миссия һәм стратегик максатның уникальлегенә китерә, хәтта ки алар гади, беренче карашка, аңлаешлы сүзләр белән формалаштырылса да: гражданнарның бүгенге һәм киләчәк

***– Бүген «Яр Чаллы» АСИҮТ резидентлары арасына 21 җитештерү компаниясе керә, бу Россия моношәһәрләрендә ачылган АСИҮТләр составында саналган резидентларның 21 %ка якыны дигән сүз. Хәзерге вакытта биредә Яр Чаллыда эшләнгән 13 проект тормышка ашырыла, бер проект – Чиләбе өлкәсеннән һәм икесе – Мәскәү өлкәсеннән, 5 проект чит ил компанияләренә (Германия, Төркия, Кытай) карый. АСИҮТ ачылу нәтиҗәсендә шәһәр ун елга беренче мәртәбә җәлеп ителгән чит ил инвестицияләре күләме буенча «Алабуга» МИЗны узып китте. Гамәлдәге резидентлар тарафыннан планлаштырылган инвестицияләрнең гомуми күләме 25 млрд сумны тәшкил итә, 5 меңнән артык яңа эш урыны булдырылыр, дип көтәбез. Узган елның 3 кварталы йомгаклары буенча резидентлар инде 13,7 млрд сум акча кертте, 2 меңнән артык яңа эш урыны ачылды.***

буыннарының тотрыклы үсештәге тормыш сыйфатын тәэмин итү, аның нигезенә җитештерүне, эшкуарлыкны һәм шәһәр пространствосын трансформацияләү салына. Стратегия шәһәр халкы, инвесторлар, бизнес, хакимият алдында перспективаны формалаштыра, шәһәрнең тарту көчен арттыра. Ул өч төп юнәлешне үз эченә ала: икътисадны, кеше капиталын, пространствоны. Әлеге өчлек бер-берсеннән башка гамәлдә була алмый.
Ике ел элек безнең шәһәр 319 моношәһәр арасында беренче булып алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе статусын алды. АСИҮТ – «яңа икътисад» тармакларын формалаштыручы инвестицияле проектларны җәлеп итүнең мөһим инструменты ул.
Стратегияне эшләүчеләрнең логикасы – базар, капитал, талантлар һәм игътибар өчен уңышлы көндәшлек итүче «Яр Чаллы мультиполисы – 2030» полиүзәкле агломерациясенә үзгәртеп коруның озакка исәпләнгән мастер-планы, «Кама икътисад зонасы» үзәге. Шактый зур потенциалга ия үзәк инфраструктур проектларны гамәлгә ашырганда уртак карарларның нәтиҗәлелеген күтәрергә, социаль шартларны тигезләү һәм халык тормышын яхшырту буенча чаралар үткәрергә мөмкинлек бирә.
Дөнья бик тиз үзгәрә. Без бөтен икътисадый һәм социаль ландшафтны радикаль үзгәртергә сәләтле принципиаль технологик үзгәрешләр эпохасына кердек. Шәһәрнең индустриаль үзәк буларак структурасы һәм үсеше тарихы 3.0 һәм 4.0 Индустриясе ысуллары нигезендә җитештерүне модернизацияләүнең, шәһәр пространствосын түбән чыгымлы «акыллы шәһәр» итеп трансформацияләүнең, эшчәнлекне катлауландырганда компетенцияләрнең төрлеләгән ачыклауның һәм формалаштыруның кирәклегенә китерә.
Кешегә, аны әзерләүгә, аның яраклашу сәләтенә таләпләр җитди үзгәреш кичерә. Шәһәрләр һәм илләр арасында иң яхшы кадрлар өчен көндәшлек арта. «Яңа кеше», үз чиратында, шәһәр пространствосына һәм инфраструктурасына таләпләрне үзгәртә.
Бизнес, инновацияләр, технологияләр, кеше капиталы тупланган нокталар буларак шәһәрләр әйләнә-тирәдә барган үзгәрешләрнең үзәгендә урнашкан. Шәһәрләр яңа карарларны уйлап табучы генераторлар да, аларны куллanучылар да булып торалар.
Безнең шәһәр әлеге үсеш баскычы буенча беренче адымны ясарга, көчле гравитация куәтенә ия миллионлы шәһәр – агломерациягә әверелергә тиеш.
Безнең шәһәрнең стратегиясе уникаль формат тәкъдим итә: «Яр Чаллы» агломерациясе – гамәлдәге күргәзмә һәм җитештерүнең иң яхшы технологияләре, пространстволы үсеш, кеше капиталын формалаштыру лабораториясе буларак карала.
Безнең Стратегиядә беренче тапкыр «халык башлыгы» формалаштырылган, ул шәһәрлеләрнең кала үсешенең түбәндәге юнәлешләренә карата карашларын чагылдыра: тормышны тәэмин итү, эшкуарлык, кеше капиталы, шәһәр бергәлеге. Без аны конкрет проектларда гамәлгә ашыра башладык: узган елда халык белән бергә җәмәгать урыннары проектларын тикшердек. Әйтик, архитекторлар белән уртак эш нәтиҗәсендә шәһәребездә уникаль объектлар – Шишкин һәм Тинчурин бульварлары, Г. Тукай яр буе пәйда булды.
Яр Чаллының үсеш Стратегиясе шәһәрнең Кама агломерациясенең рәсми булмаган башкаласы сыйфатында көндәшлеккә сәләтлелеген арттыруга, яшьләрне, креатив техник классны җәлеп итүгә һәм аларны биредә калдыруга юнәлдерелгән, ул рекреация зонасының табигый куәтен дөрес файдалануны, нәтиҗәлелекне арттыруны һәм икътисадны диверсификацияләүне күз алдында тота.

**– АСИҮТ кысаларында шәһәр үсеше нәтиҗәләренә нинди бәя бирәсез? Әлеге статуска бәйләнгән өметләр акланамы?**

– Бүгенге көндә «Яр Чаллы» АСИҮТ резидентлары арасына 21 җитештерү компаниясе керә, бу Россия моношәһәрләрендә ачылган АСИҮТләр составында саналган резидентларның 21 %ка якыны дигән сүз. Хәзерге вакытта биредә Яр Чаллыда эшләнгән 13 проект тормышка ашырыла, бер проект – Чиләбе өлкәсеннән һәм икесе – Мәскәү өлкәсеннән, 5 проект чит ил компанияләренә (Германия, Төркия, Кытай) карый. АСИҮТ ачылу нәтиҗәсендә шәһәр ун елга беренче мәртәбә җәлеп ителгән чит ил инвестицияләре күләме буенча «Алабуга» МИЗны узып китте.
Гамәлдәге резидентлар тарафыннан планлаштырылган инвестицияләрнең гомуми күләме 25 млрд сумны тәшкил итә, 5 меңнән артык яңа эш урыны булдырылыр, дип көтәбез. Узган елның 3 кварталы йомгаклары буенча ре-

Ел саен үткәрелә торган чәчәк фестивале шәһәрнең визит карточкасы булып тора.



зидентлар тарафыннан инде 13,7 млрд сум акча кертелде һәм 2 меңнән артык яңа эш урыны ачылды.
Резидентлар азык-төлек, химия сәнәгате, металл эшкәртү тармакларында, көнкүреш һәм авыл хуҗалыгы техникасын җитештерү өлкәсендә эшчәнлек алып бара.
Әгәр проектларны тормышка ашыру форматларын карыйбыз икән, өч проект («Чишмә», «ХАЙЕР ЛАУНДРИ МАШИН РУС», «Дарлетто») «greenfield» (ягъни яңа төзелеш) форматында эшли, ә калган унсигез проект – «brownfield» (ягъни элек булган җитештерү мәйданчыкларында) форматында, шуларның алтысы үз эшчәнлекләрен Европаның иң эре индустриаль паркларының берсе саналган «Мастер» КИП» территориясендә алып бара.
2017 елның иң мөһим вакыйгасы дип, без гомуми инвестицияләре күләме 59 млрд сум булган «ХАЙЕР РУС» Индустриаль паркы»н ачу максатында эшләгән инвестицияле проектны тормышка ашыра башлауны билгеләп үтәргә тиеш. Әлеге проект кысаларында биш мең яңа эш урыны ачу күздә тотыла.
Парк Haier компаниясенең кер юуу машиналарын, телевизорлар, суыткычлар һәм катыру җиһазлары, кухня электр техникасын чыгару буенча җитештерү куәтләрен урнаштыру өчен төзелә. Агымдагы елның апрелендә Яр Чаллыда кер юуу машиналарын җитештерү заводы төзелеше башланачак, заводны эшләтеп җибәрү 2019 елның июленә планлаштырыла.
Паркны ачу республика икътисадына чит ил инвестицияләрен җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк, шәһәр бюджетына салым керемнәренең артуына йогынты ясаячак.

**– Киләчәк бүген үк формалаша. Агымдагы 2018 елда социаль-икътисадый өлкәдә, инфраструктураны үстерүдә шәһәрне нинди үзгәртеп корулар көтә? Иң беренчел игътибарны көткән «авырту» нокталары инде билгеләнгәнме?**

– Безнең иң беренче чираттагы максат: моношәһәрне яңа мөмкинлекләр территориясенә әйләндерү, ә иң яхшысы – уңышлар территориясенә. Бу амбициоз һәм катлаулы, әмма чынга ашарлык бурыч. Әлеге максатка бары тик инвестицияле активлыкны җанландыру аша гына ирешергә мөмкин.
Проектны тормышка ашыручы инвестор өчен территориянең җәлеп итүчәнлеге ике юнәлештән тора: бер яктан – ул җитештерү һәм инженерлык, ә икенче яктан – социаль инфраструктура.
2017 елда федераль һәм республика программалары кысаларында социаль инфраструктура объектларын төзүгә һәм торак фондны капиталь төзекләндерүгә 8,3 млрд сум җәлеп ителде. Яр Чаллы төзелеш, капиталь ремонт һәм реконструкцияләү буенча 18 республика программасында катнаша.
«2018–2022 елларга ТР территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дип аталган дәүләт программасына керү өчен, без шәһәрдәге 556 ишегалды һәм җәмәгать территориясен тәкъдим иттек.
Хәзерге вакытта без шәһәрнең яңа микрорайонында күптән көтелгән мәктәпне төзү эшләрен алып барабыз, ул 1224 урынга исәпләнгән, шулай ук Гадел хөкем йорты төзелеше дә бара. Быел без торак төзелешенә, юлларны һәм дәваханәләрне, ресурс үзәкләрен, кадет мәктәпләрен һәм яшьләр үзәкләрен ремонтлауга аерым игътибар бирәчәкбез, һәм шулай ук «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» программасын тормышка ашыру дәвам иттереләчәк. Әлеге программа кысаларында автокаладагы ЗЯБ бистәсе паркын төзекләндерү планлаштырыла, Азатлык мәйданын ремонтлау да тәмамланачак.

**– Шәһәр алдында торган бурычларны чишүдә кече һәм урта эшкуарлыкның роле нинди? Мэрия һәм эшкуарлар арасында аралашу ничек бара? Стратегия-2030 бурычларына ирешүдә кече һәм урта бизнесның роле нинди?**

– 1993 елда «КАМАЗ»ның двигательләр заводындагы янгын шәһәр тормышына шактый үзгәрешләр кертте. Ул чакта меңәрләгән кеше урамда калды. Компаниянең күпчелек хезмәткәрләре белемле һәм максатчан кешеләр бит. Нәкъ менә алар, кече һәм урта бизнес предприятиеләренең көчле үсешенә юл салып, үз эшләрен ача башлый. Әлеге процесс бүген дә дәвам итә. Хәзер муниципаль дәрәҗәдә без нәрсә эшлибез? Бездә ике катгый кагыйдә эшли. Беренчедән, без комачауламыйбыз, икенчедән, ярдәм итәргә, бизнесны алып бару өчен кирәкле барлык шартларны тудырырга тырышабыз.
Эшкуарлар белән сөйләшүләр алып бару өчен «Эшкуарлык буенча кризиска каршы тору штабы» дип аталган шәһәр проекты эшләнде. Без Сәүдә-сәнәгать палатасында үз проектларын тәкъдим итә торган эшкуарлар белән очрашабыз. Аларга булдыра алган кадәр барлык ярдәмне оештыру безнең төп бурыч булып тора. Әйтик, 2015 елдан башлап, 77 утырыш үткәрелде һәм шәһәр хуҗалыгының төрле өлкәләренә кагылышлы 142 проект тикшерелде. Проектларның күпчелеге хуплану тапты.
Штаб эшчәнлегенң бер юнәлеше булып «Үсеш» сәнәгать паркында урнашырга дәгъва кылучы резидентларның гаризаларын карау тора. 2017 елда биш предприятие парк резиденты статусын алды. Инде быел үткәрелгән соңгы утырышта тагын ике резидентның гаризасы хупланды. Алар якын араларда төзелешкә тотынырлар, дип исәп тотабыз.
Гомумән алганда, узган елда эшкуарлар белән аралашу бизнес катнашлыгында узган эре шәһәр чаралары кысаларында барды, әйтик, Яр Чаллы шәһәре һәм ИННОКАМ рай-

Тинчурин бульвары.



оннары эшкуарлары съезды, Татарстан-төрек эшлекле форумы, Машина төзелеше кластеры форумы (җиде дистәгә якын чара).

Эшкуарлар белән диалог шулай ук «Бизнес һәм хакимият» проекты кысаларында да җайга салынган. 2017 елның августында Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Тимур Ногманов белән очрашу вакытында җир-милек мөнәсәбәтләре, төзелеш, сәүдә объектларын урнаштыру сораулары тикшерелде.

**– Күп кенә чаллылылар шәһәргә уңайлылык, җайлылык җитми дип саный. Бу иң беренче чиратта ишегалларына, ял итү урыннарына, яшел почмакларга кагыла. Соңгы елларда «Парклар һәм скверлар», «Җәмәгать урыннарын төзекләндерү» программалары нәтиҗәсендә без проблемаларның кискенлеге югалуын сизәбез. Әлеге эшне дәвам итү планлаштырыламы?**

– Сезнең белән килешеп бетмим. Шәһәргә килгән һәркем чисталыкка, «Горзеленхоз» хезмәткәрләре тырышлыгы белән барлыкка килгән матур чәчәк клумбаларына һәм композицияләргә хәйран кала. Яр Чаллы шәһәрендә йорт яны территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча максатчан эш алып барыла. Йортларның тирә-ягында Идарәче компанияләр хезмәткәрләре, яшәүчеләрнең көче белән тәртип булдырыла һәм саклана, үзенчәлекле җылылык тудырыла. Без боларның барысын да шәһәрнең визит карточкасына әверелгән һәм ел саен үткәрелә торган чәчәкләр фестивалендә эшләргә нәтиҗә ясаганда күрәбез. Фестивальдә төрле конкурслар оештырыла, шул исәптән шәһәр территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм чәчәкләр белән бизәү, һөнәри осталык, ТИҮләр арасында йорт яны территорияләрен матурлауга караган проектлар буенча да.

Быел Яр Чаллыда шәһәрнең ишегалды һәм җәмәгать территорияләренә инвентарьлаштыру уздырылды. Әлеге эш йомгаклары буенча шәһәр хуҗалыгына тулы бәя бирелде. 556 йорт яны территориясе капиталь ремонтка мохтаҗ дип табылды. Әлеге территорияләрне төзекләндерүгә караган муниципаль программаны тормышка ашыру өчен 1,7 млрд сумга якын акча таләп ителә. Хәзерге вакытта 2018 елда төзекләндерелергә тиешле ишегалды территорияләрен барлау бара, адреслы исемлек әзерләнә.

Шулай ук «2018–2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» муниципаль программасына керү өчен җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар һәм бульварлар) исемлеге төзелде.

Чаллы. Яңартылган ишегалларының берсе.



**– Шәһәр үсешендә ТИҮләрнең роле нинди, атап әйткәндә, ишегалды территорияләрен төзекләндерүдә, яшәү территорияләренә караган проблемаларны хәл итүдә халыкның инициативалылыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерүдә?**

– Инде өченче ел Яр Чаллыда төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча территориаль иҗтимагый үзидарәләр арасында шәһәр бәйгесе оештырыла. Шәһәрнең 2018 елгы бюджетында ТИҮләр арасында шәһәр бәйгесен үткәрү максатларына 5 млн сум акча каралган. Идарәче компанияләр гадәттә әлеге проектларны уртак финанслыйлар. Проектка һәм халык теләгенә ярашлы рәвештә грантлар конкрет йорт яны территориясен төзекләндерүгә юнәлдерелә.

Республика дәрәҗәсендә шулай ук йорт яны территорияләрен төзекләндерү буенча ТИҮләр арасында проектларга бәйге оештырыла. 2017 елда Чаллы ТИҮләре җиңүчеләр дип табылды һәм аларга тапшырылган грантларның гомуми суммасы 9 млн сумнан артып китте.

Яр Чаллының Автозавод районы территориаль иҗтимагый үзидарәләре үсешенә ярдәм күрсәтү ассоциациясе 2017 елда Россия Федерациясе Президентының 478 800 сумлык грантына ия булды, әлеге акчаларны йортларда асралучы этләр өчен мәйданчыкларны төзекләндерүгә (коймаларын ремонтлауга, өстәмә яктыртуга, этләрне өйрәтү өчен махсус җиһазлар урнаштыруга) тотылачак.

**– Узган елда шәһәр үсеше йомгаклары буенча Сез нинди нәтиҗәләр ясый аласыз?**

– Моношәһәр һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе статусларын алып, без яңа халәткә, яңа сыйфатка күчтек, тормышка ашырылуы шәһәрнең социаль-икътисадый тормышын тулаем реформалауны таләп итә торган бурычларны яңача аңлауга ирештек. Максат бер – без шәһәребезгә яңа ракурстан карарга, аның киләчәген күз алдына китерергә һәм шуңа омтылырга тиеш. Инвесторлар игътибарын көткән шәһәрләр Россиядә байтак. Ләкин безнең фикеребезчә, гаять көчле житештерү, фән һәм кадрлар куәтенә ия булганы гына инвесторларны үзенә тартырга, алар өчен иң яхшысы булырга тиеш. Беренчедән, бизнес өчен кызыктыргыч шартлар тудыру тәҗрибәсе – узган елда калабызның моношәһәр буларак та, икътисадый үсеш ноктасы сыйфатында каралган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе буларак та үсешенең мөһим нәтиҗәсе. Бу безнең стратегик максат. Икенчедән, шәһәр үсеше проблемаларын, яңа инвестицияләр җәлеп итү сорауларын федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәләрдә генә түгел, чит ил партнерлары белән тыгыз хезмәттәшлектә хәл итәргә кирәк. Һәрвакыт беренче булу өчен, безгә эшне оештыруның дөрес ритмын тоярга кирәк. Һәм без шулай эшләргә омтылабыз да!



# ПРЕЗИДЕНТ белән бер көн





Агымдагы елның 24–25 гыйнвары көннәрендә Россия Президенты Владимир Путин Татарстанга эш сәфәре белән килде. Визит барышында төрле очрашулар һәм чаралар оештырылды. Россия дәүләте башлыгының Казанга мондый гаять тыгыз графиклы сәфәренең әле булганы юк иде, мөгаен. 24 гыйнварда кич белән соң гына илнең мөселман руханилары белән очрашудан башланып, ул икенче көнне шулай ук соң гына «КАМАЗ-мастер» командасы экипажы белән аралашудан соң тәгәлләнде. Дәүләт башлыгы мөселман лидерлары, хәрби-сәнәгать комплексы инженерлары һәм авиаторлар, табиблар, студентлар, нефтьчеләр һәм автоузышчылар белән очрашырга өлгерде. Визитны эре штрихлар белән сурәтләгәндә шулай. Аны ике генә сүз белән «ачышлар көне» дип бәяләргә мөмкин, гәрчә, турысын әйткәндә, ике көн булса да.

Мөселман дин әһелләре белән очрашканда, Владимир Путин болай диде: «Һичшиксез, традицион ислам Россия мәдәнияте кодының мөһим өлеше булып тора, ә мөселман өммәте – күпмилләтле Россия халкының мөһим өлеше». Ул шулай ук Болгар ислам академиясе эшли башлавын югары бәяләде.

Казан авиация заводы аэродромында югары тизлекле яңа Ту-160М стратегик бомбардировщигының сынау очышын карагач, Владимир Путин киләчәктә бу машинаны җитештерүгә старт бирде. 2027 елга кадәр Казан предприятиесе РФ Оборона министрлыгына шундый ун самолёт тапшырырга тиеш. РФ Президенты шулай ук Ту-160ның граждан авиациясе версиясен чыгару мөмкинлеге турында уйланырга чакырды: «Мин ышанам, безнеке кебек искиткеч зур территориядә аңа ихтыяҗ булачак. Әлбәттә, монда зур хезмәт таләп итеlә, әмма бу чыннан да реаль». Президентның әлеге сүзләре авиация сәнәгатендә, ниһаять, ачык үсеш перспективалары барлыкка килде, дип исәпләргә мөмкинлек бирә. Вакытсызлык чоры үткәннәрдә калды.

РФ Президенты шулай ук «Бергәләп алга!» студентлар клубларының Бөтенроссия белем бирү форумын ачты, ул «Татнефть-Арена» спорт комплексы мәйданында узды. Форумга Россиянең 38 төбәгеннән 5 меңнән артык студент җыелган иде.













Фотолар tatarstan.ru сайтыннан алынды.

Яшьләргә мөрәҗәгать итеп, Владимир Путин аларны хаталар ясаудан курыкмаска өндәде. «Һәрвакыт аларны җиңеп чыгу һәм үзегезгә кирәкле чишелешләрне табу мөмкинлеген эзләгез, шунда сез, һичшиксез, бәхетле, уңышлы буын булырсыз», – диде ул активист студетларга.

Аннары РФ Президенты Казан федераль университетының Фундаменталь медицина һәм биология институтында булды. Анда Владимир Путин һәм федераль университетлар студентлары белән телекүпер оештырылды. Телекүпер Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург, Калининград, Ставрополь, Ростов-на-Дону, Симферополь, Архангельск шәһәрләрен тоташтырды. Федераль университетларның җитәкчеләре һәм студентлары Владимир Путин белән бергә академик мобильлек, вуз тәмамлаучыларны эшкә урнаштыру темасын һәм Россия студентлары тормышының башка аспектларын тикшерделәр.

Беркадәр соңрак Владимир Путин һәм Рөстәм Миңнеханов видеоконференцэлемтә аша Түбән Кама белән бәйләнешкә чыктылар, анда алар белән сөйләшүне «ТАНЕКО» белгечләре көтеп тора иде. «Башлагыз!» – дип команда биргән дәүләт башлыгының җиңел кулыннан Түбән Каманың «Татнефть» ГАҖ предприятиесендә ике яңа җитештерүгә старт бирелде. Болар – елына 1,1 млн тонна нафтаны гидрочистартуга көйләнгән җайланма һәм елына 420 мең тонна егәрлектә җиңел нефтьне изомерлаштыру җайланмасы.

Эш сәфәре ахырында Владимир Путин «КАМАЗ-мастер» командасында катнашучылар белән очрашты һәм аларны «Дакар-2018» ралли-марафонында җиңүләре белән котлады.

Казанга килгән вакытында, Россия Президенты Владимир Путинның Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән эшлекле очрашуы да булып узды. Гомумән алганда, РФ Президентының Казандагы вакыйгалар белән тулып торган көне ил җитәкчелегенең республикага карата игътибарын һәм Татарстанның, яңа югары технологияле җитештерүләр ачып, икътисадны, мәгарифне, социаль өлкәне үстереп, Россиядә әһәмиятле роль уйнавын күрсәтте.



Нияз ӘХМӘДУЛЛИН тексты.
Фотолар Яшел Үзән, Түбән Кама һәм Чистай муниципаль районнарының матбугат хезмәтләреннән алынды.

# АСИҮТ формуласы

РФ ХӨКҮМӘТЕ УЗГАН ЕЛ АХЫРЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЯҢА АЛГАРЫШЛЫ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШ ТЕРРИТОРИЯЛӘРЕН ТӨЗҮ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТТЕ. АСИҮТЛӘР БЫЕЛ ЯШЕЛ ҮЗӘНДӘ, ТҮБӘН КАМАДА ҺӘМ ЧИСТАЙДА ПӘЙДА БУЛАЧАК. НӘТИҖӘДӘ ӘЛЕГЕ МОНОШӘҺӘРЛӘРДӘ УН ЕЛ ЭЧЕНДӘ 7 МЕҢЛӘП ДАИМИ ЭШ УРЫНЫ АЧЫЛЫР, ДИП КӨТЕЛӘ. ЯҢА АСИҮТЛӘР 76ЛАП РЕЗИДЕНТНЫ ҖӘЛЕП ИТӘРГӘ ТИЕШ, Ә ИНВЕСТИЦИЯЛӘРНЕҢ ГОМУМИ КҮЛӘМЕ 23,7 МЛРД СУМНЫ ТӘШКИЛ ИТӘЧӘК, ШУЛ ИСӘПТӘН КАПИТАЛЬ КЕРТЕМНӘР КҮЛӘМЕ 19 МЛРД СУМ БУЛАЧАК.

Безнең республикада беренче АСИҮТ 2016 елда Яр Чаллы шәһәрендә ачылды. Бүгенге көндә биредә 17 резидент эшчәнлек алып бара, алар тарафыннан 3 млрд сумнан артык капитал салынган, 1,5 мең яңа эш урыны ачылган. ТР Премьер-министры Алексей Песошин сүзләренә караганда, киләсе ун елда Татарстанда АСИҮТләр хисабына 10 меңгә якын яңа эш урыны булдырылачак, җәлеп ителгән инвестицияләрнең гомуми күләме 38 млрд сумнан артып китәчәк.

Яңа АСИҮТләр булдыруның үз тарихы бар. Моношәһәрләрне үстерү буенча федераль фонд белән уртак эшчәнлек кысаларында моңа кадәр бераз алданрак сәнәгать парклары төзү максатында Яшел Үзәнгә – 1 млрд сумга якын акча, Түбән Камага 300 млн сумнан артык акча бирелгән иде инде. «Инвестор әзер инфраструктурага килә, салым ташламалары ала. Аның бурычы –

### АЛГАРЫШЛЫ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШ ТЕРРИТОРИЯСЕ РЕЗИДЕНТЛАРЫНА ТАШЛАМАЛАР

| Салым төрләре, иминият кертемнәре | РФнең гомуми шартлары | АСИҮТ резиденты |
|---|---|---|
| Табышка салым | 20% | 5 ел дәвамында 5% |
| Федераль бюджет | 2% | 5 ел дәвамында 0% |
| Төбәк бюджеты | 18% | 5 ел дәвамында 5% |
| Мөлкәткә салым | 2,2% | 0% |
| Җир салымы | 1,5% | 0% |
| Иминият кертемнәре | 30% | 10 ел дәвамында 7,6% |
| РПФ | 22% | 10 ел дәвамында 6% |
| СИФ | 2,9% | 10 ел дәвамында 1,5% |
| ММИФ | 5,1% | 10 ел дәвамында 0,1% |



җиһазларын урнаштыру, җитештерүне көйләп җибәрү һәм сату. Бүгенге көндә бу инвестицияле эшчәнлекне үстерүнең иң нәтиҗәле ысулы», – диган иде узган елның декабрь ахырында ул чактагы ТР икътисад министры Артем Здунов.

Яңа, көтеп алынган статусны алганнан соң муниципалитетлар нәрсәгә өметләнә ала? АСИҮТ нинди инвесторларны көтә? Нәтиҗәдә яшелүзәнлеләр, түбәнкамалылар һәм чистайлылар нәрсә алачак?

## ТҮБӘН КАМА

Түбән Камада АСИҮТ төзү нәтиҗәсендә 20 ләп резидентны җәлеп итү планлаштырыла, алар китергән инвестицияләр күләме – 7,5 млрд сумга якын һәм капиталь кертемнәре күләме якынча 6,5 млрд сум булырга тиеш. Шул ук вакытта инвестицияле проектны гамәлгә ашыру чорында «Түбән Кама» АСИҮТ резидентының капиталь кертемнәренең минималь күләме 15 млн сумнан да ким булырга тиеш түгел, 20 дән дә аз булмаган яңа даими эш урыннары ачарга тиеш, шул исәптән АСИҮТ резиденты реестрында юридик зат буларак теркәлгәннең беренче елында капиталь кертемнәрнең күләме 2,5 млн сумнан ким булмаска, яңа даими эш урыннарының саны 10 нан да аз булмаска тиеш.

Түбән Кама муниципаль районы башлыгы Айдар Метшин фикеренчә, АСИҮТ статусы Түбән Камага район икътисадының өстәмә «үзәген» эшләтеп җибәрергә, икътисадны диверсификацияләргә ярдәм итәргә, шәһәрнең инвестицион җәлеп итүчәнлеген күтәрергә, 3 мең даими эш урыны ачарга мөмкинлек тудырачак.

«Алда безне куелган максатларга юнәлдерелгән конкрет зур эш көтә. Һичшиксез, АСИҮТ статусын алу икътисадның кече һәм урта бизнес кебек секторын



Түбән Кама муниципаль районы башлыгы Айдар Метшин.

үстерүдә уңай чагылыш табачак. Безнең өчен 2017 ел икътисадның әлеге сегментын үстерүдә инде нинди-дер дәрәҗәдә алгарышлы булды, дип әйтәсем килә. Яңа юнәлешләр үсеш ала, өстәмә акчалар җәлеп итәлә, шул исәптән район территориясенә чит ил инвесторлары килү бәрабәренә дә», – дип басым ясый Айдар Метшин.

Яңа ел алдыннан Түбән Кама территориясендәге «Пионер» индустриаль паркында өслекле рулон прокат җитештерү заводын эшләтеп җибәрү буенча килешүгә кул куелды, әлеге килешүне Татарстанның Инвестицияле үсеш агентлыгы һәм Кытай инвесторы буларак «Камасталь» предприятиесе имзалады. «Проектка салынган инвестицияләр суммасы 400 млн сумны тәшкил итә, рулонлы корычны эшкәртү һәм буяу заводы инде быел ук эшләп китәргә тиеш. Һәм бүген безнең тарафтан инвестор каршына куелган бурыч – үзебезнең җирле белгечләрне

мөмкин кадәр күбрәк эшкә җәлеп итү», – дип билгеләп үтә Түбән Кама башлыгы. Сүз дә юк, әлеге мисал чит ил инвесторларының әлеге зонага карата кызыксынулары артуы турында сөйли. АСИҮТ ачылу белән инициативалы эшкуарлар өчен җитди стимуллар барлыкка килә. Һәм чит илләр өчен генә түгел, үз эшкуарларыбыз өчен дә.

Шәһәр җитәкчелеге хакимиятне эшлекле климатны яхшырту, административ каршылыкларны җиңү, кече һәм урта бизнесны үстерү эшчәнлегенә юнәлдерә. «Безнең бурыч – куелган максатка ирешү өчен кулдан килгәннең барысын да эшләү», – дип басым ясый Айдар Метшин.

**НӘТИҖӘЛЕЛЕК КОЭФФИЦИЕНТЫ**
**«Түбән Кама» АСИҮТ үстерү кысаларында 2017 елда 73 яңа эш урыны ачу планлаштырылган, 2017 елга бу сан 300 даими югары технологияле эш урыны буларак үсәргә тиеш. Шул ук вакытта инвестицияләр күләме 2017 елга – 798 млн сумны, ә инде 2027 елга 7,5 млрд сумны тәшкил итәргә тиеш.**

## НӘТИҖӘЛӘР НИНДИ...

Мөһим үзенчәлек – алгарышлы үсеш территориясендә шәһәр булдыручы предприятиеләр эшчәнлеге тыелган. Шуңа күрә бизнес вәкилләрендә үзләренең әлегә эшкә җигелмәгән акчаларын АСИҮТ предприятиеләренә салуга карата кызыксыну уяныр, дип көтелә. Шәһәр булдыручы предприятиеләр дә үзләренең буш акчаларын альтернатив җитештерүләргә кертү мөмкинлегенә ия булачаклар.

Шәһәрдә АСИҮТ ачу яңа җитештерү кластерлары оешуга нигез булып торыр һәм Түбән Каманың социаль-икътисадый үсешенә, сервис икътисадын үстерүгә этәргеч булыр, дип ышаналар, шул исәптән кече һәм урта бизнес өлешен арттыруга шартлар тудыру юнәлешендә дә. Бүгенге көнгә «Түбән Кама» АСИҮТнең потенциаль резидентларының 15 инвестицияле проекты бар, әлеге инвесторлар язма формада яңа җитештерүләрне эшләтеп җибәрүгә әзерлекләрен расладылар. Мэрия исәпләүләре буенча, эшкуарлык эшчәнлегенең яңа төрләрен үстерү хисабына шәһәр икътисадының диверсификация дәрәҗәсе 2%ка үсәргә, гомумшәһәр күләмендә төяп-озатылган продукция күләмендә шәһәр булдыручы сәнәгать предприятиеләренең өлеше 78%тан 62%ка кадәр кимергә тиеш.

Бюджет системасының барлык дәрәҗәләрендәге бюджетларына керми калган һәм төшеп калган керемнәр күләме өлешен инвестицияле проектларны гамәлгә ашыру барышында резидентлар тарафыннан алынган өстәмә керемнәр хисабына каплау күздә тотыла.

**АСИҮТ төзү нәтиҗәсендә 2027 елга Түбән Кама бюджеты – 98 млн сум күләмендә, Татарстан Республикасы бюджеты 127 млн сум күләмендә өстәмә керем алачак. Федераль бюджетка 3,7 млрд сумга якын өстәмә керем керәчәк.**

## ПОТЕНЦИАЛЬ РЕЗИДЕНТЛАР

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый һәм инвестицион үсеш буенча урынбасары Радмир Беляев сүзләренә караганда, бүгенге көндә мэриягә АСИҮТ резиденты статусын алырга теләк белдерелгән 4 гариза кергән. Аларда югары әзерлек дәрәҗәсендәге проектларны гамәлгә ашыру күздә тотыла. Алар арасында «Камасталь» ҖЧҖ, «Метакам» ҖЧҖ, «Бакелит» ҖЧҖ һәм «Түбән Кама» сәнәгать паркы бар. «Быел без 15 резидентны җәлеп итүне максат итеп куябыз», – дип билгеләп үтте ул журналистлар белән очрашуда. Керү шартларына килгәндә, Радмир Беляев аларны Яр Чаллыдагы АСИҮТ резидентлары өчен каралган таләпләр белән чагыштырды: «Бездә резидентлар беренче елны бары тик 2,5 млн сум гына кертем кертергә тиешләр, ә алга таба – 15 млн сум. Мисалга, күршебез Яр Чаллыда кертемнәр күләме беренче елда 5 млн сум булырга, ә алга таба бу сумма 50 млн сумга җитәргә тиеш. Хәзерге вакытта шәһәрдә инде ике сәнәгать мәйданчыгы ачылган: «Пионер» индустриаль паркы һәм «Түбән Кама» сәнәгать паркы. Тагын ике сәнәгать паркын ачарга ниятлибез».





Яшел Үзән муниципаль районы башлыгы Александр Тыгин.

## ЯШЕЛ ҮЗӘН

Район хакимиятләре АСИҮТ мөмкинлекләрен куллану муниципалитетта ун ел эчендә 2,5 мең яңа эш урыны ачарга мөмкинлек бирер, дип планлаштыра. АСИҮТтә исә барлыгы 15 ләп резидент урнашыр, алар 7,6 млрд сумнан артык күләмдәге инвестиция алып килер, дип көтелә.

АСИҮТ районда кече һәм урта бизнес үсешенә яңа җитди этәргеч бирәчәк, дигән ышаныч яши бирелә. Әйтик, узган ел Яшел Үзән муниципаль районы башлыгы Александр Тыгин салым ташламалары Казан бизнесын да җәлеп итәр, дип билгеләп үткән иде. «Без алырга тырышкан АСИҮТ статусы, – дигән иде ул чакта башлык, – һичшиксез менә дигән салым преференцияләре китерәчәк». Ул эшкуарларның Казаннан Яшел Үзәнгә таба күчү процессы башланачагына ышанычын белдерде. «Чөнки Казанда кече бизнес өлеше 40 проценттан артып китә, ә бездә бары тик 20 проценттан бераз гына күбрәк», – дип аңлатты ул.

Яшел Үзән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Светлана Кадыйрова болай дип билгеләп үтте: «АСИҮТ резидентлары яхшы салым преференцияләре алалар. Атап әйткәндә, аларга табышка һәм мөлкәткә салым, җир салымы буенча ташламалар бирелә. Моннан тыш, бюджеттан тыш фондларга бара торган кертемнәр дүрт тапкырга диярлек кыскара».

Җитештерүләрен урнаштыру өчен резидентларга салым преференцияләре каралган өч территорияне тәкъдим итәләр.

Беренчесе – **«Яшел Үзән» сәнәгать мәйданчыгы.** Мәйданы 110 гектарны тәшкил иткән сәнәгать мәйданчыгы Яңа Тура янында, М-7 федераль трассасы һәм Казан – Яшел Үзән трассасы киселешендә урнашкан. Бүгенге көндә территория кирәкле барлык ресурслар белән дә тәэмин ителгән. Федераль һәм республика бюджетларыннан инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары төзелешенә 1,1 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Төзелеш чорына җир кишәрлекләре бушлай бирелә. Ләкин бинаны кулланышка тапшырганнан соң, кишәрлекләрне аларның кадастр бәясенең 10–15 процентын түләп сатып алу күздә тотыла. Янәшәдәге «Радужный» һәм «Салават күпере» торак микрорайоннары яңа җитештерүләрне эшче көчләр белән тулысынча тәэмин итәргә булышыр, дип ниятләнелә.


Резидентларга тәкъдим ителә торган тагын бер территория – **«Дулкын» сәнәгать мәйданчыгы,** ул Казан – Йошкар-Ола федераль трассасына якын урнашкан. Хәзерге вакытта 60 гектар муниципаль җир буш. Элегрәк бирелә «Тандер» («Магнит» супермаркетлары челтәре) бүлү үзәгенең инвестицияле проекты гамәлгә ашырылган иде инде.

Өченче кишәрлекне **Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге** биләп тора. Аның территориясе – 244 га. Логистика үзәге «Европа – Көнбатыш Кытай» халыкара транспорт коридорында төрле транспорт белән китерелә торган йөкләрне комплекслы эшкәртү объектларын урнаштыру өчен ачылды. Территория «Волга» М-7 федераль автомагистрале һәм Казан – Буа – Ульяновск федераль трассасы янәшәсендә урнашкан. Кишәрлеккә аны эре магистраль белән тоташтыручы тимер юл сузылган.

Яшел Үзән муниципаль районы башлыгы Александр Тыгин шәһәрне үстерү перспективалары турында сөйләгәндә, АСИҮТ статусы алу аркасында ирешеләчәк шактый зур нәтиҗәлелеккә исәп тота: «2017 елда Яшел Үзәнгә 85 ел булды. Ул сәнәгать остаханәләреннән үсеп чыккан кала, аңа шулай ук Советлар Союзының иң яхшы проектантлары «тире тамган». Безнең горурлыгыбыз – сугыш елларында да директорлары алмашынмаган ике завод («А.М. Горький ис. завод», «Серго ис. завод» – ред.). Без хәрби шәһәргә әйләндек – шулай килеп чыкты. Хәзер безнең бурыч – яңа икътисад төзү. Һәм яңа проектларыбыз нәкъ менә шуңа юнәлдерелгән. Бүген без логистиканы, фармацевтиканы, авыл хуҗалыгы эшкәртүен үстерү турында сөйлибез. Алгарышлы үсеш территориясе статусы яңа мөмкинлекләр ача, иң беренче чиратта салым йөген җиңеләйтә. Асылда, АСИҮТ форматы ирекле икътисадый зоналарга караганда да әйбәтрәк. Без әлеге статус маятниклы миграцияне 10 процентка киметергә, эшсезлекне 1 процентка кадәр (0,8 процент) кыскартырга, шәһәр икътисадын 22 процентка диверсификацияләргә мөмкинлек бирер, дип көтәбез.

Шуңа күрә, минем уйлавымча, алгарышлы үсеш территориясе статусы – ул алга таба бик җитди адым. Шуны билгеләп үтәсем килә: алгарышлы үсеш территориясе – Россия Президентының бер стратегик инициативаларының берсе. Димәк, бу әле Яшел Үзәнгә күрсәтелгән югары ышанычны да дәлилли».

Яшел Үзән шәһәре манзарасы.





## ЧИСТАЙ

АСИҮТ төзү турында РФ Хөкүмәте Карарына кул куелу турында хәбәр алынганнан соң, Чистай шәһәре активы каршында чыгыш ясап, муниципаль район башлыгы Дмитрий Иванов яңа статус алу өчен башкарылган эшнең күләмен билгеләп үтте. Ул уртак эшкә республика хакимиятенең барлык дәрәҗәләре тарафыннан зур көч куелуына басым ясады: «Чистайда алгарышлы үсеш территориясе ачу максатында ТР Президенты, ТР Хөкүмәте, ТР Икътисад министрлыгы, Чистай хакимияте тарафыннан гаять зур күләмдәге эш башкарылды. Хәзер безнең алда потенциаль инвесторларның һәрберсе белән җитди эшләү бурычы тора. Без бүген АСИҮТ статусы алуга караган өметләребез чынга ашарлык һәм шәһәребездә ул яңа предприятиеләр ачылуга этәргеч булырлык итеп эшләргә тиешбез».

Чистайда АСИҮТ төзелү, фаразлар буенча, 38 резидентны җәлеп итәргә тиеш, кертелгән инвестицияләр күләме 8,5 млрд сумнан да ким булмас, дип көтелә, шул исәптән капиталь кертемнәр күләме 6 млрд сумга якын булырга тиеш.

Шәһәр җитәкчелеге АСИҮТ статусы инвесторларга шактый салым ташламалары бирә, дип саный. Потенциаль резидентлар да моны таный. Югарыда без табышка, мөлкәткә, җиргә салымнарның күпмегә кимегәнен атап үткән идек инде. Һичшиксез, хезмәткә түләү фондыннан бюджеттан тыш фондларга күчерелә торган акчаларның күләме кимү дә җитди ярдәм булып тора. Дөрес, шунда ук сорау да туарга мөмкин: болай да шәһәр һәм район ихтыяҗларын канәгатьләндерергә җитеп бетмәгән һәм муниципаль бюджетка күчәргә тиешле, ләкин төшеп калган керемнәрне ничек компенсацияләргә?

Администрациядә мондый шикләнүләрне таратырга тырыштылар. Җирле хакимиятләр Чистай шәһәренең Пенсия һәм башка бюджеттан тыш фондларына зыян килмәячәк, дип аңлаталар, чөнки нәкъ менә резидентлар ачкан яңа эш урыннары хисабына өстәмә салым керемнәре булачак, алар төшеп калган керем күләмен каплаячак та. АСИҮТ резиденты булырга теләгән һәр инвестор 10 нан да ким булмаган эш урыны ачуны һәм 2,5 млн сумнан ким булмаган күләмдәге инвестицияләр кертүне күз уңында тоткан проектын тапшырырга тиеш бит. Ләкин эре инвесторлар, кагыйдә буларак, эре җитештерүләр ачалар, димәк, 10 түгел, 100 һәм аннан да күбрәк эш урыны булдырылачак.

Бүгенге көндә Чистайда инде инвестицион проектларын гамәлгә ашыру ниятен белдергән 23 потенциаль резидент исәпләнә. Алар 900 гә якын эш урыны ачарга уйлый. Проектлар буенча инвестицияләр күләме 6 млрд сумга якын, капиталь кертемнәр күләме – якынча 4 млрд сум.

Шәһәр территориясендә бизнесны үстерү өчен барлык коммуникацияләре дә китерелгән 4,5 млн квадрат



метрлы буш җитештерү мәйданы бар. Шәһәр администрациясе потенциаль резидентларга бизнес алып бару өчен буш җир кишәрлекләре бүлеп бирергә әзер. Шулай итеп, Чистай өчен АСИҮТ статусы яңа эш урыннары ачуны, яңа җитештерүләрне эшләтеп җибәрүне вәгъдә итә. Нәтиҗәдә шәһәр төп предприятиеләргә бәйлелеген киметә һәм муниципаль бюджетка өстәмә керемнәр дә ала.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов
«Чистай» индустриаль паркы эше белән таныша.





Чистай муниципаль районы башлыгы Дмитрий Иванов.

**Инде берничә ел эшләп килгән «Чистай» индустриаль паркы шулай ук АСИҮТкә кертелде. Парк территориясе инженерлык инфраструктурасы эшләнгән 292 гектарлы мәйданны тәшкил итә. Бүгенге көндә мәйданның 187 гектары гамәлдәге һәм потенциаль резидентларга бирелгән, 104 гектары әлегә буш. Парк территориясендә 4 резидент эшли, 3 инвестицион проект гамәлгә ашырылган.**

Агымдагы ел башында Чистай районы җитәкчелеге якын киләчәктә «Чистай» АСИҮТ резиденты булырга ниятләгән эшкуарлар белән очрашу оештырды. Киңәшмәгә моношәһәрнең эре, кече предприятиеләре җитәкчеләре һәм шәхси эшкуарлар чакырылган иде. Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасары Виктор Шурыгин катнашучыларга АСИҮТ резиденты буларак эшчәнлекне ничек алып барырга, алар өчен нинди салым ташламалары һәм преференцияләре каралуы, нинди таләпләр куелуы турында җентекләп сөйләде. Аңлатылып киткән салым ташламаларыннан тыш, шәһәр хакимияте юридик һәм оештыру сорауларын хәл итүдә һәрьяклы ярдәм күрсәтүне вәгъдә итте. Документлар пакетын әзерләүнең гадиләштерелгән тәртибе дә резидентларны җәлеп итүгә эшли, моннан тыш, аларга хакимиятнең төбәк һәм муниципаль органнары, Моношәһәрләрне үстерү фонды ягыннан тиешле ярдәм күрсәтеләчәк.

Инвесторлардан нәрсә таләп ителә соң? Мөгаен, әлеге сорау булачак резидентлар өчен төп әһәмияткә иядер. «Чистай» АСИҮТ резидентлары азык-төлек, текстиль, агач эшкәртү, химия, металл эшкәртү сәнәгате, машина төзелеше һәм электр җиһазлары җитештерү кебек тармакларга 2,5 млн сумнан да ким булмаган күләмдә капиталь кертемнәр кертергә һәм 10 лап яңа эш урыны ачарга тиеш. Шунысын күз уңында тотарга кирәк: АСИҮТ составына йә яңа, йә инде гамәлдәге, әмма бер ел эчендә эш урыннарын ике мәртәбәгә арттырырга сәләтле проект кертелә ала.

«Безнең бурыч – АСИҮТ режимыннан тулысынча файдалану һәм мөмкин булганча күбрәк яңа эш урыннары ачу», – дип нәтиҗә ясады эшкуарлар белән очрашуга район башлыгы.



**45 муниципаль берәмлектәге 68 объект 2017 елда «Җәмәгать урыннары» программасын тормышка ашыру кысаларында төзекләндерелгән.** Быел 57 объект (26 парк, 17 пляж, 6 урам, 3 сквер, 3 бульвар һәм бер мәйдан) төзекләндереләчәк. Шул ук вакытта җәмәгать урыннары проектларын сайлаганда халыкның турыдан-туры тавыш бирүе күздә тотыла. Процедура җәмәгать муниципаль комиссияләре тарафыннан оештырылачак.



**146 белем бирү объекты (шул исәптән 36 мәктәп, алардан – 7 се коррекцион мәктәп һәм 110 мәктәпкәчә яшьтәгеләр оешмасы)** 2017 елда белем бирү объектларына капиталь ремонт ясау программасы буенча төзекләндерелгән.



**5,2 млн тонна бөртекле ашлык (уңыш 34,2 ц/га) узган ел республика аграрийлары тарафыннан җыеп алынган.** Чөгендер игү тарихында беренче тапкыр 3 млн тоннадан артык тамыразык үстерелгән (уңыш 408 ц/га). Гомумән алганда, үсемлекчелектә тулай продуктның чагыштырма үсеше 11 %ны тәшкил иткән (140,4 млрд сум).




**28 авыл клубы 2018 елда республикада социаль-мәдәният объектларын төзү һәм капиталь ремонтлау программасын тормышка ашыру кысаларында төзеләчәк.** Моннан тыш, 10 җирлек Советы (башкарма комитетлары) бинасы, 44 фельдшер-акушерлык пункты төзү күздә тотыла.




**13,2 мең сум – 2017 елда Татарстандагы эшләмәүче пенсионерларның картлык буенча уртача еллык иминият пенсияләре әнә шул күләмдә булган.** Узган ел эшләмәүче 800 меңгә якын пенсионерның иминият пенсиясе 5,8 %ка арттырылган.

**300 дән артык хуҗалык соңгы дүрт елда республиканың терлекчелек объектларына капиталь ремонт ясау программасыннан файдаланган.** Бу чорда 1193 сыер абзары ремонтланган (352 се – 2017 елда), 540 силос-сенаж траншеясы төзелгән (129 объект – 2017 елда).



**2 меңнән артык техника берәмлеге республикада 5 млрд сумнан артыграк бәягә АСКларны техник модернизацияләү программасы кысаларында сатып алынган.** Хуҗалыклар гомуми егәрлеге 40 мең ат көчен тәшкил иткән көчле 107 тракторга ия булган. Болар барысы бергә энергия белән тәэмин ителешне 100 га чәчүлек җиренә 158 а.к. күләменә җиткерү мөмкинлеген биргән.



**2 млрд сумнан артыграк акча Татарстанда узган ел авылларда хуҗалык итүнең кече формаларына булышуның төрле программалары өчен бүлеп бирелгән.** Алардан шәхси ярдәмче хуҗалыкларны субсидияләү өчен бирелгәне генә дә 730 млн сум тәшкил иткән. Гаилә фермаларын булдыру өчен грантларны 121 крестьян-фермер хуҗалыгы алган (грантларның суммасы – 375 млн сум).



**478 мини-ферма Татарстанда узган елда төзелгән.** Бүгенге көндә алар барысы – 1300. Мини-фермаларда 7,3 мең сыер асрала.




**1825 мең тонна сөт (үсеш – 102,9%) республикада 2017 елда җитештерелгән.** Шул исәптән авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре һәм КФХ тарафыннан – 1268 тонна. Татарстан сөт җитештерү буенча Россиядә беренче урынны алып тора (бөтенроссия күләменең 6 %ы). Республика авыл хуҗалыгы оешмаларында җитештерелә торган товарлыклы сөтнең чагыштырма авырлыгы ягыннан республика шулай ук Россиядә беренче урында.






Резеда **ВӘЛИЕВА** текстЫ. Автор фотолары.

# *КЕЧКЕНӘ дә төш кенә*

ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН АГРОСӘНӘГАТЬ КОМПЛЕКСЫ ХУҖАЛЫК ИТҮНЕҢ ТӨРЛЕ ФОРМАЛАРЫ БЕЛӘН АЕРЫЛЫП ТОРА. БУ ҮЗЕНЧӘЛЕК РЕСПУБЛИКАНЫҢ БУА РАЙОНЫ МИСАЛЫНДА ДА АЧЫК ЧАГЫЛА. МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКНЕҢ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ТАРМАГЫНДА АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ ТЕРРИТОРИЯЛӘРЕНЕҢ КҮПЧЕЛЕГЕНДӘГЕ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРЕ ЧЕЛТӘРЕН БЕРЛӘШТЕРҮЧЕ ЭРЕ АГРОФИРМАЛАР ДА, АЕРЫМ МӨСТӘКЫЙЛЬ КҮМӘК ХУҖАЛЫКЛАР ЯКИ, ЭЛЕККЕЧӘ ӘЙТСӘК, КОЛХОЗЛАР ДА БАР.

Заман таләбе, күп укладлы икътисад шартларында хуҗалык итүнең үзенчәлекле кече формалары – крестьян яки фермер хуҗалыклары барлыкка килде. Халыкта аларны фермерлар дип кенә йөртәләр, һәм үз-үзләренә эшләүче мондый авыл кешеләренең саны елдан-ел артуга таба бара. Читтән караганда, фермер үзенә үзе хуҗа, беркемгә дә бәйле түгел кебек тоелырга мөмкин. Шулай да бу иллюзия генә. Чынлыкта исә фермер хуҗалыгының эшчәнлегендә бөтен гаилә һәм туган-тумача катнаша.

Фермерларның һәркайсы әлеге катлаулы юлны төрле сәбәпләр аркасында сайлап алган. Кемнеңдер мөстәкыйльлеккә омтылышы көчле булган, кемнедер җирне, хайваннарны яратуы, җир эшенә иyләшкән булуы фермерлык эшенә этәргән. Бер сүз белән әйткәндә, кешенең җир эшенә кулы ятарга тиеш монда. Аларның күбесенә эшне оештырып җибәрү җиңел бирелмәгән, бүген аякларында нык басып торганнарына да уңышка ирешү өчен шактый тир түгәргә туры килгән. Әмма аларның барысын берләштерә торган сыйфат бар. Беренче чиратта, бу – ихтыяр көче, үз-үзеңә ышаныч һәм хезмәт сөючәнлек. Фермер үз эше өчен янып яши. Шуңа да аларның фермаларында һәрвакытта да чиста, коры, сыерлар да, бозаулар да караулы, техника эшләп тора. Авыл хезмәтчәннәре, ял көннәрсез, бәйрәмнәрсез эшләсәләр дә, зарланмыйлар.

Фермер хуҗалыкларына бүген ихтыяҗ зур. Алар агросәнәгать комплексының үсешендә әһәмиятле роль уйный. Ныклы хуҗалыклар, гаилә фермалары, авыл җирендә яшәүче халыкны эш белән тәэмин итеп, аларның керемнәрен арттыруга гына булышып калмый, ахыр чиктә, авылны саклап калуга да өлеш кертә, авыл кешесенең туган җиреннән китүен дә туктатып тора.

Буа муниципаль районында 80 кече һәм урта фермер хуҗалыгы эшли, алар барысы бергә 26 мең гектар мәйданда эшчәнлек алып бара. Иң киң тарал-



Буа районы Боерган авылыннан Миләүшә белән Иршат Гайнетдиновларның гаилә фермасын районда белмәгән кеше юктыр.



Боерган авыл җирлеге башлыгы Ирина Малышева (уңнан беренче) Гайнетдиновларны эшсөяр, җаваплы, намуслы кешеләр буларак бәяли, кече ватаннарының язмышы өчен кайгыртучанлык күрсәтәләр, дип саный.

ган эшчәнлек төре – үсемлекчелек. Сөрү җирләренең 20 проценттан артыгында алар үсемлекчелек белән шөгыльләнә, бөртеклеләр һәм шикәр чөгендере җитештерү дә якынча шулкадәр мәйданда алып барыла.

Районда терлекчелек белән шөгыльләнүче биш фермер хуҗалыгы бар. 7 фермер терлекчелек белән үсемлекчелекне бергә алып бара. 14 гаилә фермасы уңышлы гына эшләп киткән. Фермер хуҗалыкларындагы мөгезле эре терлекнең баш саны 332гә җиткән, шул исәптән 182се – савым сыеры, 110 баш ат асрала. Кошкортның баш саны мең ярымнан артыграк исәпләнә. 2017 елда фермер хуҗалыклары тарафыннан 6479 центнер сөт һәм 480 центнер ит җитештерелгән.

Буа районы Боерган авылыннан Миләүшә белән Иршат Гайнетдиновларның гаилә фермасын районда белмәгән кеше юктыр. Хәзерге вакытта әлеге гаилә 103 баш мөгезле эре терлек асрый, шулардан 35е сыер, 12се тана, 56 баш яшь мал симертүгә куелган. Үз эшләрен алар 2012 елда 40 бозауны симертүгә алудан башлаган. Яңа эш башлаган фермерларга булышлык итү өчен бирелгән 1,5 миллион сумлык грант акчасына мал асрау бинасы төзегәннәр.

Узган елда Гайнетдиновларның фермер хуҗалыгында

Фермер үз эше өчен янып яши. Шуңа да аларның фермаларында һәрвакытта да чиста, коры, сыерлар да, бозаулар да караулы, техника эшләп тора.



102,6 тонна сөт, 19,9 тонна ит җитештерелгән, 91 тонна сөт һәм 3 тонна ит продукциясе сатылган. Акчалата табыш 5 миллион сумга якын булган. Гаиләнең барлык әгъзалары да эш белән мәшгуль. Моннан тыш, сезон вакытында алар тагын 2–3 кешене эш белән тәэмин итә.

Фермер хуҗалыгының 271 гектар җире бар, анда үз ихтыяҗлары өчен бөртекле һәм азык культуралары үстерәләр, уңышлы елны артык калганы сатуга китә. 2017 елда, мәсәлән, фермерлар 667 тонна бөртекле, 1320 тонна азык культурасы, 1758 тонна шикәр чөгендере җыеп алганнар. 152 тонна ашлык һәм барлык шикәр чөгендерен дә сатып, 3 миллион 184 мең сум акча эшләгәннәр. Бу саннар артында олы хезмәт ята.

– Хайваннар балалар кебек ул – тәүлек әйләнәсе карарга кирәк, игътибар таләп итәләр. Без иртән торып фермага киткәндә, авылдашларның күбесе йоклый әле, кич кайтканда да кайберләре инде йоклаган була, – дип җавап бирә крестьян-фермер хуҗалыгы башлыгы Миләүшә Гайнетдинова «Фермер булу ничегрәк?» дигән сорауга.

Уңган гаиләне кыенлыклар куркытмый. Гайнетдиновлар алга таба да эшләргә ниятли, киләчәккә оптимизм белән карый, планнар кора – «КФХ базасында гаилә фермалары үсеше» гранты бәйгесендә катнашырга һәм нәселле маллар сатып алырга җыеналар.

Әлеге гаилә Иршатның бертуганы – Ринат Гайнетдинов белән кулга-кул тотышып эшли. Ул да фермер хуҗалыгы башлыгы, үсемлекчелек белән шөгыльләнә. Ринат Боерган мәктәбендә көтеп алынган кунак, ул мәктәпкә җиһазлар белән, уку әсбаплары белән ярдәм итә. Узган ел, мәсәлән, мәктәп укучыларына интерактив такталар бүләк иткән.

Раил Хисамов – районда бердәнбер ат фермасының хуҗасы, атларны яшьтән ярата. Ферма шул ук Боерган авыл җирлегендә урнашкан. Ат фермасы хуҗасы – район һәм республика Сабантуйларындагы ат ярышларының даими катнашучысы. Шулай ук Боерган Сабантуенда ат ярышларының алыштыргысыз оештыручысы да ул. 2015 елда Раил Хисамов атчылык юнәлешенә 900 мең сум күләмендә грант алган. Һәм менә өч ел узуга, өч төрле



«Чикләре булмаган тәҗрибә» дигән темага авыл җирлекләре башлыклары өчен үткәрелгән күчмә семинарларның беренчесе Боерган авыл җирлеге базасында оештырылган.



Раил Хисамов (уртада) – райондагы бердәнбер ат фермасының хуҗасы, яшьтән үк атлар белән мавыга.

токымлы (рус, литва һәм совет авыр йөк аты токымнары) 28 баш атның саны 60ка якынлашып килә. Фермер арендага 26 гектар җир алган. Планында – атларның баш санын йөзгә җиткерү. Хатыны Зөлфия дә – шәхси эшкуар. Ат итеннән төрле ризыклар ясау белән шөгыльләнә.

– «Лизинг-грант» программасы буенча авыл хуҗалыгы техникасы аласым килә. Казылык һәм ат итеннән башка төр ризыклар җитештерәчәкбез, – дип, планнары белән уртаклаша Раил Хисамов.

Алар җитештергән продукциягә ихтыяҗ зур – авыл кибете киштәләрендә һәм сәүдә нокталарында озаклап ятмый икән. Сатып алучылар хәтта күрше районнардан да киләләр.

Боерган авыл җирлеге башлыгы Ирина Малышева фермерларны эшсөяр, җаваплы, намуслы кешеләр буларак бәяли, кече ватаннарының язмышы өчен кайгыртучанлык күрсәтәләр, дип саный.

– Безнең җирлектә ат фермасы, гаилә фермасы эшли, тагын 5 фермер үсемлекчелек белән шөгыльләнә. Алар – безнең иң беренче ярдәмчеләребез. Алардан башка безгә, җирле хакимият вәкилләренә, бик кыен. Аларның финанс ярдәменнән башка бер генә чара да узмый. Юлларны үз вакытында кардан чистарту, чишмәләрне төзекләндерү, юл читендәге посадкаларны, урамнарны, стадионнарны (әйе, бездә стадион да бар, анда без зурдан кубып Акатуй үткәрәбез) карау – боларның барысы да менә шундый хуҗалыкчыл авылдашларыбызның ярдәме белән башкарыла. Алар – безнең терәгебез.

Бер авыл җирлегендә уңышлы эшләп килүче җиде фермер хуҗалыгы – игътибарга лаеклы үрнәк. Нәкъ менә шуның өчен былтыр районда «Чикләре булмаган тәҗрибә» дигән темага авыл җирлекләре башлыклары өчен үткәрелгән күчмә семинарларның беренчесе Боерган авыл җирлеге базасында оештырылды. Безнең уртаклашыр тәҗрибәбез бар.

– Бары тик авыл кешеләренең эшлеклелек активлыгын күтәрү, аларның үзмәшгульлеген арттыру һәм даими үсеш шартларында гына без авылны саклап кала, авыл кешесенең шәһәргә китүен туктата алабыз, – дип саный Буа муниципаль районы башлыгы Марат Җәббаров. – Районда «Чикләре булмаган тәҗрибә» семинарын оештыруның максаты да шул: ныклы хуҗалыкларны күрсеннәр, аларның үрнәгенә иярсеннәр.

Үрнәк итеп китерерлек фермерлар районда аз түгел. Алар үсемлекчелек, терлекчелек белән шөгыльләнә, эшчәнлекнең башка өлкәләрендә дә эшкуарлар бар. Җирле үзидарә органнарының бурычы – аларга төрле яклап булышу һәм аларны үстерүгә ярдәм итү. Моның өчен республикада авылга ярдәм итүгә юнәлтелгән программалар гамәлгә ашырыла. Алар арасында яңа эш башлаучы фермерларга грантлар бирү, лизинг аша ярдәм итү кебекләре бар. Бу программаларның әһәмияте һәм аларның дәвам иттереләчәге турында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та ТРның Дәүләт Советына Юлламасында басым ясады.

Соңгы биш елда Буа районының 11 фермер хуҗалыгы дәүләт ярдәменнән файдаланды. Җидесе, яңа эшли башлаган фермер буларак, гомуми суммасы 10,87 миллион сум акча алды, дүртесе, фермерлык эшчәнлеген үстерергә дип, – 9,75 миллион сум.

Кече һәм урта эшкуарлык, авыл кешесенең активлыгы җирлек башлыклары өчен генә терәк түгел. Бу кешеләр авылның киләчәгенә ышанычны ныгыта. Районның авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүдә фермерларның, хуҗалык итүнең башка формаларының өлеше елдан-ел артуын исәпкә алганда, шәхси ярдәмче хуҗалыклары һәм крестьян-фермер хуҗалыклары продукциясен сатуны югары дәрәҗәдә оештыру кирәклеге көн тәртибенә баса. Авыл кешеләренең шәхси ихаталарында 7970 баш мөгезле эре терлек асрала, шул исәптән – 3354 баш сыер,

***– Үрнәк итеп китерерлек фермерлар районда аз түгел. Алар үсемлекчелек, терлекчелек белән шөгыльләнә, эшчәнлекнең башка өлкәләрендә дә эшкуарлар бар. Җирле үзидарә органнарының бурычы – аларга төрле яклап булышу һәм аларны үстерүгә ярдәм итү. Моның өчен республикада авылга ярдәм итүгә юнәлтелгән программалар гамәлгә ашырыла. Алар арасында яңа эш башлаучы фермерларга грантлар бирү, лизинг аша ярдәм итү кебекләре бар.***




Яшевка авылы район үзәгеннән ерак урнашкан, сөт җыючылар монда ук килми, шуңа күрә Петр Лапшин авылдашларына ярдәм итә: хуҗалыклардан артып калган сөтне дә җыя.



2015 елда Петр Лапшин арендалаган бинаны сатып ала, аңа ремонт ясый. «Яңа эш башлаучы фермер» бәйгесендә катнашып, 3 миллион сумлык грант ота. Грант акчасына МТЗ-82 тракторы ала.

атлар саны 500гә якын. Елдан-ел ихаталарында 5–6 баш мөгезле эре терлек асраучы гаиләләр саны арта. Мондый гаиләләр – потенциаль фермерлар. Шәхси хуҗалыкларда савым сыерлары көтүенең баш санын арттыруга этәргеч бирү максатыннан район җитәкчелеге тарафыннан ихатада сыерлар санын арттырган өчен район бюджетыннан бер башка 3 мең исәбеннән субсидия бирү турында карар кабул ителгән.

Шәхси ихаталардан җыеп алынган сөт күләме елына – 11 тоннадан, ит күләме 1,5 мең тоннадан артып китә. 14 гаилә фермасы эшли. Шуңа да бүген районда агросәнәгать паркына ихтыяҗ гаять зур, ул булса, авыл хезмәтчәннәре курыкмыйча үз эшләрен башлар, ит һәм сөт ризыклары җитештерер, яшелчә, җиләк-җимеш үстерү белән шөгыльләнер иде.

Фермерлар арасында үзләрен яңа өлкәдә сынап карарга теләүче бик кызыклы кешеләр бар. Шуларның берсе – Чувашия Республикасының Яльчик районында туып-үскән Петр Лапшин. Белгечлеге буенча – тракторчы-машинист. Язмышы аны 2007 елда Буа районының Яшевка авылына алып килә, Лапшин урман хуҗалыгына эшкә урнаша. Үзенең ихатасында үгезләр асрый башлый: баштарак 2–3 не, аннан соң кәсебенә кереп китеп, баш санын 12–15 кә җиткерә. Әкренләп азык әзерләү өчен техникасын да булдыра: ихатада трактор, сабан, культиватор, чапкыч, тырма, пресслаучы җайланма барлыкка килә. Шул рәвешле шәхси хуҗалык төп эш урынына әйләнә.

Узган елның декабрендә Тәтеш районында узган семинарда иң яхшы фермерларны котлау тантанасында. Уңнан өченче – Петр Лапшин.



– Тора-бара шуны аңладым: сыер асрау табышлырак икән, шуннан соң савым сыерлары сатып алырга карар иттем, – дип, фикерләре белән уртаклаша Петр Николаевич.

Гаилә өч сыер асраудан башлый, әкренләп көтүнең баш саны 16 га җитә. Урын җитми башлый, шуңа да элеккеге күмәк хуҗалыкның ферма бинасын арендага алалар. 2015 елда Петр Лапшин КФХ терки, арендага алган бинаны сатып ала, аңа ремонт ясый. «Яңа эш башлаучы фермер» бәйгесендә катнашып, 3 миллион сумлык грант ота. Грант акчасына МТЗ-82 тракторы һәм 30 савым сыеры сатып ала. Узган елның декабрендә Тәтеш районында авыл кешеләренең эшлеклелек активлыгын күтәрүгә багышланган республика семинарында Петр Лапшин ТРДәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов кулыннан бүләк ала. Ул «Иң яхшы фермер» номинациясендә җиңүче була. Бу фермерның җиңел булмаган хезмәтенең лаеклы бәһасе.

Бүген фермерның хуҗалыгы шактый саллы инде: 46 савым сыеры, 30 бозавы, 105 гектар җире, тракторы бар. Болар артында зур эш тора: бизнес-план эшләү, подрядчылар белән эшләү, башка мәшәкатьләр. Хәзерге заман фермеры бик күп эшләрне эшли белергә тиеш! Кем әйтмешли, үзе ура, үзе суга...

– Безнең Яшевка авылы район үзәгеннән ерак урнашкан, сөт җыючылар монда ук килмиләр. Петр Николаевичка рәхмәт, ул сөт эшкәртү предприятиесенә үз хуҗалыгы сөтен генә илтми. Авылдашларының соравы буенча, шәхси ихаталардан артып калган сөтне җыя, – ди Яшевка авыл җирлеге башлыгы Сергей Бахтинов. – Һәр эштә дә ул безгә бер карусыз ярдәм итә. Авылның киләчәге – шушындый булдыклы кешеләр кулында.

Фермерларның көнне төнгә ялгап эшләгәннәренә карап, алар башкарган эшнең күләмен күреп, аларның мөстәкыйльлегенең һәм бәйсезлегенең бәһасен аңлыйсың. Аларның кытыршы куллары – «фермер» сүзенең «эшсөяр» һәм «хезмәт батыры» сүзләренә синоним булуына ышандырырлык дәлил.



**86 млрд сум – узган ел республикага федераль программалар кысаларында җәлеп ителгән акчаларның күләме нәнә шуның кадәр сумманы тәшкил итә.** Бу күрсәткеч узган ел белән чагыштырганда 18 %ка арткан (2016 елда – 72,7 млрд сум). Республика РФнең 26 дәүләт программасында һәм 17 федераль максатчан программада катнашкан.




**25 млрд 733 млн сум узган ел Татарстан таможнясы тарафыннан федераль бюджетка күчерелгән.** Бу суммадан читкә чыгару пошлинасына – 142,7 млн сум, импорт түләүләренә – 25 млрд сум, башка төр түләүләргә 494 млн сум туры килә. 2016 ел белән чагыштырганда, таможня түләүләренең суммасы 1 млрд 386 млн сумга арткан.



**247 мең Татарстан гаиләсе махсус федераль программа гамәлдә булган 10 ел дәвамында ана капиталы алу турында гариза биргән** (70 млрд сум күләмендә 243 меңнән артык сертификат бирелгән). Ана капиталын тотуда иң популяр юнәлеш булып торак шартларын яхшырту тора – 93,8%. 153 мең гаилә ана капиталы белән өлешчә яисә тулысынча торак кредитларын түләгән. Моннан тыш, 12 мең гаиләнең гаризасы – балаларны укыту, 52 гариза акчаны ананың тупланма пенсиясенә күчерү өчен кабул ителгән.



**7 меңнән артык җир биләмәсе Казанда күп балалы гаиләләргә бирү өчен җитми.** Проблеманы алга таба хәл итү өчен Россия Хөкүмәте гомуми мәйданы 639 га булган федераль җир биләмәләре белән идарә итү һәм файдалану вәкаләтләрен республика карамагына тапшырды. Алардан 2,5 меңнән артык биләмә булдыру күздә тотыла.



**10,8 мең урам яктырткычын Татарстан авылларында 2017 елда модернизацияләгәннәр.** Тиешле программа гамәлдә булган дүрт ел дәвамында 46200 энергия саклагыч лампалар яңартылган, 1726 электр щиты куелган һәм 1300 километрга якын озынлыкта изоляцияле чыбыклар сузылган. Программа авыл җирлекләренә электр энергиясе өчен түләүдә җитди экономия ясарга ярдәм итә.



**18 %ка якын урман җирләре бүгенге көндә Татарстанның кадастр исәбенә куелган.** Хәзерге вакытта урман фонды җирләрендә кадастр эшләре 8 урманчылык территориясендә алып барыла. Урман фонды җирләрен рөхсәтсез biләп алу, урманны кисү һәм шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрен үзләштерү очраклары ачыкланган.



**63 машина-трактор паркына, 127 ашлык чистарту комплексына, бөртекле ашлык саклау урыннарына һәм ябулы ашлык токларына, 227 сыер абзарына, 15 яшелчә саклагычка** быел капиталь ремонт ясалачак. Моннан тыш, 123 силос-сенаж траншеясы төзү күздә тотыла.



**68 % – эш белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе – Татарстанда узган ел нәтиҗәләре шул санны күрсәтә.** Чагыштыру өчен: И(б)ФОнда уртача мәшгульлек дәрәҗәсе – 65 %, Россиядә – 66 %. Республикада гомуми эшсезлек дәрәҗәсенең күрсәткече – иң түбән саннардан берсе санала – 3,5 % (Россия буенча 6 нчы урын). 2017 ел нәтиҗәләре буенча, 2016 ел белән чагыштырганда, югары квалификацияле белгечләр өлеше 16 %ка арткан, бу республикада инвестицион проектларны тормышка ашыру белән бәйле.



**86 яңа универсаль спорт мәйданчыгы һәм 16 модульле чаңгы базасы республикада быел барлыкка киләчәк.** Узган ел белән чагыштырганда, яңа спорт объектларының саны беркадәр кыскарачак. 2017 елда 120 спорт мәйданчыгы һәм 11 чаңгы базасы төзелгән булган.



**8 яңа бассейн һәм 6 спорт базасы республикада 2018 елда төзеләчәк.** ТР спорт министры Владимир Леонов әйтүенчә, Татарстан муниципалитетларында йөзү бассейннары һәм спорт заллары төзү программасы уникаль күренеш булып тора – Россиянең бер генә төбәгендә дә мондый эш гамәлгә кермәгән.



Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ тексты. Андрей ТИТОВ фотолары.

# БИЕКТАУ климаты: эшлекле һәм актив

ТАТАРСТАНСТАНТ МӘГЪЛҮМАТЛАРЫ БУЕНЧА, СОҢГЫ УН ЕЛДА РЕСПУБЛИКАДА АВЫЛ КЕШЕЛӘРЕНЕҢ САНЫ 45 МЕҢ КЕШЕГӘ КИМЕГӘН. ХАЛЫКНЫҢ АЕРУЧА НЫК КИМҮЕ ТӘТЕШ, КАЙБЫЧ, БАЛЫК БИСТӘСЕ ҺӘМ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННАРЫНДА КҮЗӘТЕЛӘ. ХАЛЫК САНЫНЫҢ ҮСЕШЕ БАРЫ ТИК ТАТАРСТАННЫҢ ЭРЕ ШӘҺӘРЛӘРГӘ ЯКЫН ТОРГАН МУНИЦИПАЛИТЕТЛАРЫНА ГЫНА ХАС.

Бу яктан караганда, Биектау муниципаль районы мисалы үрнәк булып тора, соңгы сигез елда биредә яшәүчеләрнең саны сигез мең кешегә арткан. Шул ук вакытта бүгенге көндә рәсми рәвештә 51 мең кеше яшәгән бу районда соңгы алты ел дәвамында халыкның уңай табигый үсеше күзәтелә.

## НЫК ТОРМЫШЛЫ МУНИЦИПАЛИТЕТ

Семиозёрка авыл җирлегендә халык саны елдан-ел артып бара. Ул үз эченә Озёрный һәм Якты Күл бистәләрен, шулай ук Семиозёрка, Шигали, Макаровка һәм Тёплый Ключ авылларын да ала. Хәзерге вакытта аларда 1439 кеше теркәлгән. Шул ук вакытта халык саны 2017 елда гына да 450 кешегә арткан. Тагын 1400 кеше биредә теркәлмәгән килеш яши. Дача сезоны башлангач, халык саны бермә-бер арта – муниципалитет территориясендә 27 бакчачылык ширкәте бар.

– Әлбәттә, җирлекнең Казанга якын булуы үзен сиздерә, – дип сөйли Семиозёрка авыл җирлеге башлыгы Рамил Гусамов. – Халыкның артуы шуның белән аңлатыла. Шигалида шәхси төзелеш алып бару өчен бөтен коммуникацияләре булган 650 гектар җир бүлеп бирелде. Хәзер актив рәвештә бу җирләрне үзләштерү бара.

Бер үк вакытта җирлекнең социаль структурасы камилләштерелә. Мәсәлән, 2015 елда Шигали авылында һәм Озёрный бистәсендә модульле фельдшер-аку-

Семиозёрка авыл җирлеге башлыгы Рамил Гусамов тумышы белән Ульяновскидан. Муниципалитет белән 2016 елдан җитәкчелек итә.





Узган елның сентябрь аенда Шигали авылында 80 урынлы «Айгөл» балалар бакчасы ачылган.



«Авылның киләчәге – хуҗалык итүнең кече формаларына бәйле», – дип саный Биектау муниципаль районы башлыгы Рөстәм Кәлимуллин.



МТЗ тракторын ТР Муниципаль берәмлекләре Советы оештырган конкурс нәтиҗәләре буенча откан 1 миллион сумлык грант акчасына сатып алганнар.

шерлык пунктлары ачыла. Бер елдан соң Озёрныйда Мәдәният йортына капиталь ремонт ясала, ә 2017 елда Президент программасы кысаларында биредә 13 тренажёры булган универсаль спорт мәйданчыгы төзелә. Аның белән янәшәдә генә үзара салым акчасына балаларга уен мәйданчыгы булдырыла. Узган ел сентябрь аенда Шигали авылында 80 урынлы «Айгөл» балалар бакчасы ачыла.

Соңгы ел ярым эчендә мондагы торак пунктларда урамнарны яктырту мәсьәләсе өлешчә хәл ителә. Начар юллар да инде акрынлап үткәннәрдә кала бара. Быел гына да җирлектә 1200 метр озынлыктагы асфальт юлны тәртипкә китерү, 1600 метр грунт юлга комташ җәю күздә тотыла. Киләсе җәйдә җирлекнең Озёрныйдагы бердәнбер мәктәбенә икенче тормыш бүләк ителергә тиеш. Җирле хакимиятләр шулай ук Шигалида су белән тәэмин итү системасын тәртипкә китерергә җыена.

– Планнар зурдан, барысын да сөйләп бетереп булмый, – ди Рамил Гусамов. – Аларны тормышка ашыруда безгә өлешчә үзара салым программасы ярдәм итә. Шәһәр яны җирлеге булуыбызга карамастан, ул бездә үз урынын тапты. Быел аның кысаларында җирлекне тагын да яхшыртуга һәм торак пунктларда юлларны ремонтлауга керешәчәкбез. Аерым алганда, Семиозёрка һәм Шигали үз балалар уен мәйданчыкларына ия булачак. Шигалида шулай ук янгын гидрантлары урнаштырачакбыз.

Муниципаль берәмлекләрне үстерүгә җирле бюджет акчалары актив җәлеп ителә. «СафПласт» заводы, «Биектау» логистика паркы, «Трак Центр» федераль автотехүзәге һәм башка кайбер оешмалардан кергән салымнар хисабына – бюджет ярлы түгел. Шуңа күрә дә 2013 елда җирлектә яңа автогрейдер сатып ала алганнар, кышкы чорда биредәге күпсанлы юлларны чистарту өчен бик тә кирәкле транспорт. Ә 2017 елда муниципалитетның машина-трактор паркына заманча МТЗ тракторы өстәлә. Машинаны ТР Муниципаль берәмлекләре Советы оештырган конкурс нәтиҗәләре буенча откан 1 миллион сумлык грант акчасына сатып алганнар.

– Трактор сатып алу өчен грант акчалары гына җитмәде, әлбәттә, – дип әйтеп куйды Семиозёрка авыл җирлеге башлыгы. – 170 мең сумны үзебездән өстәдек, тагын 210 мең сумга төяү җайланмасы һәм кар бушаткыч алдык. Техника эшсез тормый. Бигрәк тә быелгы кышта. Тракторны автогрейдер белән кереп булмый торган тар урамнарда кулланабыз. Техникада бер кеше эшли. Ул хезмәт хакын җирле бюджет хисабыннан ала. Алга таба тагын бер машинист алырга җыенабыз.

Шәһәр яны территориясендә җитмәгән нәрсә – ул да булса, хуҗалыкларда терлек-туарның булмавы. Рамил Гусамов әйтүенчә, җирле халык акрынлап терлек асраудан бизә бара. Шул ук вакытта муниципалитетта терлекчелек белән шөгыльләнүче ике крестьян-фермер хуҗалыгы бар. Шулай ук Семиозёрка ирләр монастыре зур булмаган терлекчелек хуҗалыгы тота.

## ЗАРИПОВЛАР ГАИЛӘСЕНЕҢ СӨТ ЕЛГАЛАРЫ

Әлдермеш авыл җирлегендә, киресенчә, авылча яшәешне саклап кала алганнар. Бу яктан аеруча Сая авылы кешеләре уңган, анда хәзер 165 хуҗалык исәпләнә.

– Биредә безнең хезмәт сөючән һәм сабыр халык яши, – дип сөйли Әлдермеш авыл җирлеге башлыгы Тәлгать Сабиров без карлы авыл юллары буйлап машинада Мидхәт белән Замирә Зариповлар гаиләсенә барган чакта. – Шәхси ярдәмче хуҗалыкларда 189 баш мөгезле эре терлек асрала, шуларның 138е – сыерлар. Ике фер-

мер хуҗалыгында тагын 100 баш мөгезле эре терлек, шул исәптән 26 сыер бар. Биш гаилә җитди рәвештә сарык асрау белән шөгыльләнә. Корбан бәйрәменә 1000 гә якын корбан сарыгы саталар.

Зариповларның ярдәмче хуҗалыгы бүгенге исәп белән бик кечкенә түгел: сигез сыер, ике буаз тана. Бозауларны да санасаң, зур булмаган мини-ферма килеп чыга, гомумән алганда, бүген анда 15 баш мөгезле эре терлек «теркәлгән».

Узган ел хуҗалары алар өчен силикат кирпечтән яңа йорт төзеп куйганнар. Бер якка авыш түбәле шактый иркен һәм якты бу капиталь корылма гаилә бюджетына 700 мең сумга төшкән.

– Без инде утыз еллап сөт терлекчелеге белән шөгыльләнәбез, – дип сөйли гаилә башлыгы Мидхәт Зарипов. – Дүрт сыердан башлаган идек, аннары акрынлап баш санын арттыра бардык. Күпмедер вакыттан соң хуҗалык корылмаларын киңәйтү турында уйлана башладык. Шул чакта безнең бәхеткә сөтчелек мини-фермалары төзү программасы барлыкка килде. Без тәвәкәлләргә булдык һәм район җитәкчелеге ярдәме белән анда катнашуга ирештек. 200 мең сумлык грант оттык һәм менә нәтиҗәсе – шатланып туя алмыйбыз. Дәүләт ярдәменнән башка бу төзелешкә көчебез җитмәс иде.

– Авыл җирендә, ни генә әйтсәң дә, шәхси хуҗалыксыз булмый, – дип сүзгә кушыла Замирә Зарипова. – Сөт, эремчек, каймак, кортны без Казанга сатарга алып барабыз. Ялт итеп алып бетерәләр. Анда безнең даими клиентларыбыз бар инде. Җәй көне продукциябезне җирле дача ширкәтләрендә дә сатабыз. Бюджетыбыз өчен яхшы гына ярдәм була ул.

Беркадәр яшерә хуҗабикә, бүген үзләре җитештергән сөт һәм сөт ризыкларының Зариповлар гаиләсенең төп керем чыганагы булуын ачыктан-ачык әйтеп бетерми. Сөтне күп саву сезонында – майдан июльгә кадәр – минем яңа танышларым аны сатудан аена 90 мең сумга кадәр акча эшли. Кыш көне керем күләме, аңлаешлы сәбәпләр аркасында, сизелерлек кими. Әмма савым сыерлары тәүлегенә бирә торган 30–40 литр сөтне дә сатып алучылар табыла.

Мидхәтнең 77 яшьлек әнисе Илсөя апа да көченнән килгәнчә хуҗалыкны алып барырга булыша. Хәзер КФУда укучы кызлары Эльмира да әти-әнисенә ярдәм итәргә һәрвакыт әзер. Шулай да терлек карауның төп авырлыгы Мидхәт белән Замирә җилкәсенә төшә.

– Авылның киләчәге – хуҗалык итүнең кече формаларына бәйле, – дип саный Биектау муниципаль районы башлыгы Рөстәм Кәлимуллин. – Шәхси ярдәмче



2017 елда Биектау игенчеләре бөртеклеләрдән рекордлы уңыш җыйган – тулай җыем 96,5 мең тоннаны тәшкил иткән.

хуҗалыкларны үстерү өчен генә дә соңгы 11 елда безнең халык гомуми бәясе 530,2 миллион сум тәшкил иткән 2460 кредит алды. Моннан тыш, ШЯХларны үстерү буенча муниципаль максатчан программаны тормышка ашыру кысаларында узган ел район бюджетыннан шәхси хуҗалыкларга сыерлар сатып алу (өченче һәм аннан да күбрәк) һәм асрау өчен 2 миллион сум акча бүлеп бирелде.

Шул ук вакытта, «Гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» буенча республика программасы кысаларында, 2011 елдан башлап, районда 26 гаилә фермасы төзелде һәм үзгәртеп корылды, аларның 14е – югары технологияле. Шулай ук биш ел гамәлдә булган «Эш башлаучы фермерларга ярдәм» программасы буенча Биектау фермерлары гомуми суммасы 33,8 миллион сум тәшкил иткән 20 грант отты.

## АЧЫШЛАР ВАКЫТЫ

Кече һәм урта бизнесның эшлеклелек климаты һәм эшлеклелек активлыгы рейтингында Биектау муниципаль районы инде танылган әйдәп баручы булып тора. Узган ел җирле кече һәм урта предприятиеләрнең әйләнеше 13 процентка үсеп, 15 миллиард сум тәшкил иткән.

Районда уңышлы эшләүче 11 резиденты булган өч сәнәгать мәйданы эшли. Хәзерге вакытта «М7 – Биектау» индустриаль паркы проектын тормышка ашыру буенча эш алып барыла, аның базасында дүрт меңнән артык яңа эш урыны булдыру күздә тотыла.

– Узган 2017 ел безнең өчен катлаулы, ләкин һәрьяктан нәтиҗәле булды, – ди Рөстәм Галиуллович. – Бөртеклеләрдән рекордлы уңыш җыйдык – тулай

Әлдермеш авыл җирлеге башлыгы Тәлгать Сабиров.



«Авыл җирендә, ни генә әйтсәң дә, шәхси хуҗалыксыз булмый», – дип саный Замирә һәм Мидхәт Зариповлар.





2017 елның 1 сентябрендә Биектау авылында 500 урынлы урта мәктәп ачылган.

җыем 96,5 мең тонна тәшкил итте, сөт җитештерү арты. Бүгенге көндә без бу күрсәткеч буенча республикада җиденче урында торабыз.

Районның төзүчеләре дә уңышлы эшләде. 2017 елда бездә 80 мең кв. метр мәйданда торак төзеп тапшырылды, бу пландагы күрсәткечтән 125 процент тәшкил итте. Биектау авылында 500 урынлы яңа 4 нче номерлы мәктәп ачылды. Аның стеналарында С.Сәйдәшев исемендәге балалар сәнгать мәктәбе дә урын алды. Аның белән янәшәдә «Казан арты» ял паркы төзелде. 2017 елның яңа төзелешләре исәбеннән Берёзка авыл җирлеге башкарма комитеты бинасын, Дачное бистәсендәге 200 урынлы авыл мәдәният йортын, Кече Солабаш авылындагы фельдшер-акушерлык пунктын, Биектау авылындагы өч универсаль спорт мәйданчыгын, Зур Кызыл урамындагы паркны һәм тагын башка берничә социаль объектны телгә алырга кирәк.

Быел районның Зур Кавал авылында 200 урынлы Мәдәният йорты төзеләчәк. Шушында ук җирле бюджет хисабыннан авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы төзелергә тиеш. Моннан тыш, Биектау авылында ял паркы, түбәсе ябулы йөзү бассейны төзү, гомуми практика табибының модульле офисын ачу, Казаклар авылында модульле ФАП урнаштыру, район хастаханәсе поликлиникасын, гомуми практика табибы офисын һәм хатын-кызлар консультациясе бинасын капиталь яңарту, шулай ук күпфатирлы 15 йортка ремонт ясау күздә тотыла.

Озакламый Чыпчык авылы үзәгендә яңа табиблык амбулаториясенең модульле бинасы ачылачак. Чыпчык авыл җирлеге башлыгы Илшат Җиһаншин әйтүенчә, амбулатория якын тирәдәге 7,5 мең кеше яшәгән 14 торак пунктына хезмәт күрсәтәчәк.

– Яңа амбулатория безгә бик тә кирәк, – дип басым ясый җирлек башлыгы. – Моңа кадәр ул 1897 елда төзелгән земский хастаханә бинасында урнашкан иде, ул күптән инде авария хәлендә. Өстәвенә, иске амбулатория тимер юлның аръягында, бу халык өчен аерым кыенлыклар тудыра иде.

Яңа медицина учреждениесе белән янәшә 2015 елда ачылган ветеринария пункты, яңартылган күпфункцияле үзәк урнашкан. Соңгысы үз түбәсе астына 80 урынлы балалар бакчасын, китапханәсе дә булган мәдәният йортын, шулай ук авыл җирлеге башкарма комитетын сыйдырган. Бу ел ахырына кадәр биредә спорт комплексы эшли башларга тиеш, һәм җирле халык волейбол һәм зур теннис белән шөгыльләнә алачак.

Җирлектә халык арасында сәламәт яшәү рәвешен булдыру максатында актив эш алып барыла. Өч ел элек муниципалитет муниципаль берәмлекләр арасында оештырылган «Сәламәтлек территориясе» дигән беренче республика конкурсында бүләккә лаек булган. Бүләк акчасына Чыпчык Мәдәният йорты каршында заманча урам тренажёрлары урнаштырылган.



Чыпчык авыл җирлеге башлыгы Илшат Җиһаншин.



Озакламый Чыпчык авылы үзәгендә яңа табиблык амбулаториясенең модульле бинасы ачылачак.

## Марат ӘХМӘТОВ, ТР Премьер-министры урынбасары – ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры (2018 елның 7 февралендә Биектау муниципаль районының хисап сессиясендәге чыгышыннан):

– Һәр муниципаль районның үз өстенлекләре һәм проблемалары бар. Биектау районы да – искәрмә түгел. Әмма елдан-ел кыенлыклар җиңелә бара. Шәһәргә якын булу үз өстенлекләрен биргән кебек, кыенлыклар да тудыра. Шуңа да карамастан, Биектау районы республика тормышында үз урынын тапкан. Һәм районның соңгы еллардагы үсеше сөендерә. Сезгә, бик үк эреләрдән булмаса да, үз инвесторларыгызны табу насыйп булган. Социаль-икътисадый үсеш буенча район 17 нче урында тора, әмма башка күрше районнар түбәнрәк позицияләрдә. Рейтингта нефть районнары гына сездән югарырак…



# ҖИРЛЕ хакимият: проблемалар һәм чишелешләр

РЕСПУБЛИКА МУНИЦИПАЛИТЕТЛАРЫНДА ЭШЛӘРНЕҢ ТОРЫШЫН МОНИТОРИНГЫН ТОРМЫШКА АШЫРУ, БУЛГАН ПРОБЛЕМАЛАРНЫ АЧЫКЛАУ ҺӘМ АЛАРНЫ ЧИШҮ ЮЛЛАРЫН ТАБУ МАКСАТЫНДА УЗГАН ЕЛ АХЫРЫНДА МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ АРАСЫНДА ТРАДИЦИОН СОРАШТЫРУ УЗДЫРЫЛДЫ. АНОНИМ НИГЕЗДӘГЕ БУ ТИКШЕРҮДӘ ТАТАРСТАНДАГЫ БАРЛЫК 956 МУНИЦИПАЛИТЕТНЫҢ ДА ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ КАТНАШТЫ.

Алынган нәтиҗәләрнең анализы күрсәткәнчә, җирле муниципалитет җитәкчеләре җирле үзидарәне үстерүдә аеруча мөһим проблемаларның берсе дип, тиешле чыгымнарны финанслау өчен җирле бюджетларга күчерелә торган акчаларның нормативы түбән булуны саный. Респондентларның 68,7 %ы шундый фикердә. Муниципаль район башлыкларының 91 %ка якыны дәүләт вазыйфаларын башкару өчен субвенция күләмнәре җитешмәүдән зарланды.

Болардан тыш, соралучылар муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче гражданнарның социаль активлыгы түбән булуны, керем базасын үстерүдәге кыенлыкларны, кадрлар кытлыгын, контроль-күзәтү органнарының аклап булмый торган тикшерүләрен, җирле үзидарә өлкәсен көйләүче законнарның даими үзгәреп торуын эшкә аяк чала торган факторлар исәбенә кертә.

Муниципалитет башлыкларының күпчелеге фикеренчә (61 %), җирле үзидарәнең Татарстан моделен муниципаль һәм дәүләт хакимиятләренең конструктив үзара бәйләнеше аерып тора, бу һәр ике якка да мәсьәләләрнең күпчелеге буенча килешүгә ирешү мөмкинлеге бирә. 21,5 %ы килешүгә бөтен мәсьәләдә дә ирешелә, дип саный. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: муниципаллар һәм дәүләт хакимиятенең башкарма органнары арасындагы мөнәсәбәтләр закон нигезендә көйләнгән. 2013 елның 13 ноябрендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы арасында үзара эш итү турында» республика законы кабул ителгән. Ә инде 2015 елның 1 июлендә Совет тәкъдиме белән «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында»гы республика законына кайбер үзгәрешләр кертелгән, шуларга таянып, Совет вәкилләренә ТР Хөкүмәте утырышларында катнашу, башкарма хакимиятнең теләсә кайсы органына җирле үзидарә мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итү хокукы бирелә, башкарма хакимият органнарына Совет мөрәҗәгатьләре буенча чаралар күрү бурычы йөкләтелә.

Тикшерү барышында респондентларга шулай ук халыкның җирле үзидарәдә ничек катнашуын һәм гражданнарның җирле үзидарәне үзгәртеп кору юнәлешендә үз хокукларын ничек яклавын бәяләргә дә тәкъдим ителде. Сораштырылганнарның 72,6 %ы гражданнарның муниципаль идарәдә катнашуы аерым бер мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек бирә, дигән фикердә. Муниципалитет башлыкларының 16,2 %ы халык

муниципаль берәмлек үсешенә зур өлеш кертә, дип саный. 10,6 %ы кына гражданнар сизелерлек роль уйнамый, дип белдерде. Мониторингта катнашучыларның калганнары җавап бирергә кыенсынды.

Шул ук вакытта сораштырылганнарның 72,8 %ы халыкның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә актив катнашуына комачаулый торган төп сәбәп – әзергә өметләнү гадәте икәнлеген раслый. Респондентлар фикеренчә, җирле үзидарәгә кешеләрнең уртак эшләргә карата битарафлыгы, белемнәре җитмәве, компетентлы булмаулары, халыкның кабул ителә торган карарларга тәэсир итә алуына ышанмавы, вакыт җитмәү һәм кешеләрнең җирле үзидарә органнарына ышанмавы комачаулый.

Сораштырылганнар җирле хакимиятнең халык белән үзара бәйләнешенең аеруча нәтиҗәле формалары исемлегенә муниципаль берәмлек җитәкчеләренең гражданнар белән очрашуларын керттеләр. Шулай ук гражданнар белән конференцияләр һәм җыелышлар үткәрү, гражданнар арасында сораштырулар һәм гавами тыңлаулар оештыру да гомуми эшкә үз өлешен кертә. Шул ук вакытта респондентлар җирле үзидарә органнары эшендә җәмәгать оешмалары вәкилләренең катнашуы тиешле нәтиҗә бирмәвенә ышана.

Респондентлар Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән 2013 елдан башлап тормышка ашырыла торган гражданнарның үзара салым акчаларын өстәмә финанслау буенча республика программасын уңай бәяли. Узган вакыт дәвамында ул авыл кешеләрен үз авылларындагы тормышны яхшыртуга җәлеп итүнең нәтиҗәле чараларыннан берсенә әверелде. Муниципалларның 94 %ынан артыграгы шушы фикердә тора. Бу аңлашыла да, чөнки биш ел эчендә үзара салым кысаларында авыл инфраструктурасын үстерүгә (1 сумга 4 сум исәбеннән республика субсидияләрен исәпкә алып) 2,8 млрд сумнан артык акча кертелгән. Бу акчага урыннарда юллар төзелә һәм ремонтлана, муниципалитет территорияләре яхшыртыла, су белән тәэмин итү һәм урамнарны яктырту системалары яңартыла, зиратларда тәртип ясала, спорт һәм балалар мәйданчыклары корыла, һәм шулай ук авыллардагы башка көн кадагындагы мәсьәләләр хәл ителә.

Шунысы да игътибарга лаек: Татарстанның үзара салым программасын үстерү тәҗрибәсе федераль дәрәҗәдә дә кызыксыну уятты. Россия Президенты каршындагы Җирле үзидарәне үстерү советының узган елның августында Киров шәһәрендә узган утырышында Россия Президенты Владимир Путин гражданнарга үзара салымны оештыруда Татарстан тәҗрибәсен илдә алдынгыларның берсе буларак билгеләп үтте һәм аны башка төбәкләрдә дә таратырга тәкъдим итте.

Сорашуда катнашучылардан муниципаль берәмлекләрне оптимальләштерү турындагы фикерләрен белдерүне сорадылар. 39,1 % бу мәсьәлә буенча карар җирле үзидарә органнары тарафыннан, конкрет муниципаль берәмлек халкының фикерен искә алып, мөстәкыйль кабул ителергә тиеш, дип җавап бирде. 36,6 % оптимальләштерүгә каршы чыкты. 24,3 % муниципаль берәмлекләрне оптимальләштерү процессы озаклап өйрәнүне таләп итә, дип исәпли.


Урыннарда кешеләрне аеруча борчый торган мәсьәләләрдән респондентлар хезмәт хакларының, пенсияләрнең түбән булуын, ТКХ хезмәтләренә, азык-төлеккә, беренче чираттагы кирәк-яракка бәяләр күтәрелүен, шулай ук эш урыннары җитмәвен һәм эшсез калудан куркуларны күрсәтте. Сораштырылганнар фикеренчә, гражданнарны шулай ук (сирәгрәк очракта) медицина хезмәтенең сыйфаты, эш хакының вакытында түләнмәве, эчкечелек, наркомания, тиешле уңайлыклар булмау, урамнар һәм ишегалларын җыештыру, яшьләр һәм үсмерләр белән эшнең начар оештырылуы да борчый.

Респондентларның авылны үстерүгә ярдәм чаралары турындагы сорауга җаваплары кызыклы. Күпчелек авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ташламалы кредит бирү механизмын камилләштерү кирәклеген белдерде. Авыл хуҗалыгы кулланучылык кооперациясен үстерү дә авылларыбызга иkенче сулыш бирә алыр иде. Урыннарда җирне сату яисә арендага бирү башлыча авыл хуҗалыгын алып баруны күздә тотып эшләнергә тиеш.

Тикшерүдә катнашучылар авыл җирлекләренә грантлар бирү конкурсын үткәрүдәге кыенлыклар турында да үз фикерләрен белдерделәр. Тискәре факторлар исәбенә алар документлар төзү һәм муниципаль сәүдә не оештыру белән килеп туган катлаулылыкларны, шулай ук подрядчылар белән проблемаларны кертте. Искә төшереп үтәбез: конкурс барган биш ел дәвамында анда 520 авыл җирлеге җиңүче булды, аларның һәркайсы 1әр миллион сум акча алды. Бу максатчан акчалар бистә юлларын ремонтлауга, су белән тәэмин итүгә, авылларны яхшырту өчен төрле техника сатып алуга һәм башка җирле социаль әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылды.

Шул ук вакытта 2018 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр Татарстан кешеләре җирле үзидарә һәм халыкка хезмәт күрсәтүче башка учреждение органнары эшчәнлегенә үз бәяләрен бирә ала.

Халыктан сорашу баннеры дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм «Рәсми Татарстан» порталында, Татарстан Хөкүмәте рәсми порталының беренче битләрендә, Муниципаль берәмлекләр порталында һәм шулай ук ТР Икътисад министрлыгының mert.tatarstan.ru сайтында урнаштырылган. Сораштыруда катнашу өчен түбәндәге сылтама аша үтәргә кирәк: https://open.tatarstan.ru/polls/.





«ТАТАРСТАНДА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ МУНИЦИПАЛЬ ХАКИМИЯТ ӨЧЕН ИҢ ӘҺӘМИЯТЛЕ ЯҢА ЗАКОННАРГА ҺӘМ НОРМАТИВ АКТЛАРГА, ШУЛАЙ УК ФЕДЕРАЛЬ ҺӘМ РЕСПУБЛИКА ЗАКОННАРЫНА КЕРТЕЛГӘН СОҢГЫ ҮЗГӘРЕШЛӘРГӘ КҮЗӘТҮ ЯСЫЙ.

**«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 27 ноябрендәге 355-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Үзгәрешләрдә каралганча, электрон мөрәҗәгатькә җавап электрон почта адресы буенча гына җибәрелә. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны бары тик электрон рәвештә генә беркетә ала.

Элек электрон мөрәҗәгатькә җавапны электрон рәвештә дә, язма рәвештә дә бирү мөмкинлеге каралган иде. Граждан кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә генә беркетеп түгел, ә язма рәвештә дә җибәрә ала иде. Билгеләнгән срокларны үтәүдә исә шуның аркасында кыенлыклар туа килде.

Билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылышлы мөрәҗәгатькә җавапның тиешле дәүләт органы һәм җирле үзидарә органы рәсми сайтына урнаштырылу мөмкинлеге каралган.

Әгәр язма мөрәҗәгатьтә җавабы сайтка урнаштырылган сорау булса, гражданга аның электрон адресын хәбәр итәләр. Моннан тыш, шул органның рәсми сайтына урнаштырылган җавап гражданга язма рәвештә дә җибәрелергә мөмкин.

Әгәр язма мөрәҗәгатьнең текстыннан тәкъдимнең, гаризаның яки шикаятьнең асылын билгеләп булмаса, аңа җавап бирелмәячәк, һәм карау өчен ул дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка юлланмаячак. Бу хакта гражданга 7 көн эчендә хәбәр ителә.

**«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 36 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 5 декабрендәге 380-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган муниципаль берәмлек башлыгы аны вазыйфасыннан җибәрелү турында төбәкнең иң югары вазыйфаи заты (федерация субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) чыгарган хокукый актка суд тәртибендә шикаять бирелгән очракка караган кагыйдәләр билгеләнгән. Мондый очракта, суд карары законлы көченә кергәнче, вакытыннан алда сайлаулар билгеләргә яки башлыкны сайлау турында карар кабул итәргә ярамый.

Вазыйфадан җибәрелү турындагы актка суд тәртибендә шикаятьне ул чыгарылган көннән алып 10 көн эчендә бирергә мөмкин. Эшне суд тарафыннан карауга да шундый ук срок куела. Суд карары кабул ителеп беткән көннән алып 10 көн эчендә аңа шикаять бирелергә мөмкин. Апелляция шикаятьләре дә, күрсәтмә дә шундый ук срокта карала.

**«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1 һәм 56 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 5 декабрендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Гражданнар тарафыннан үзара салым кертү һәм шул акчалардан файдалану тәртибе төгәлләштерелде.

Төзәтмәләрдә гражданнар тарафыннан үзара салым кертү һәм шул акчалардан файдалану турында карарларны аерым муниципаль берәмлек территориясе чикләрендәге җирле референдумда гына түгел, ә гражданнар – җирлек, шәһәр округы, шәһәр эчендәге район, шәһәр эчендәге федераль әһәмияттәге территория составына керүче

яисә муниципаль район чикләрендә авылара территорияләрдә урнашкан аерым торак пунктлар халкы җыенында да кабул итү мөмкинлеге каралган.

**«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә карарлар кабул итүдә гражданнарның катнашу мөмкинлекләре киңәйтелде. Сүз муниципаль берәмлекләрнең генераль планнары проектлары, җирдән файдалану һәм биналар төзү кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру документлары проектлары турында, шулай ук җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы һәм рөхсәт бирелгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы мәсьәләләр буенча фикер алышу турында бара.

Шулай, гражданнар катнаша алган гамәлдәге рәвештәге гавами тыңлаулар белән беррәттән яңа форма – җәмәгатьчелек фикер алышулары кертелде. Алар дистанцион рәвештә, шул исәптән рәсми сайтта, дәүләт мәгълүмат системасында яки дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең төбәк порталында үткәрелә. Күрсәтелгән ресурсларга һәркемнең бертигез керә алуы күпфункцияле үзәкләрдә яки хакимият органнары һәм алар карамагындагы оешмалар биналарында тәэмин ителергә тиеш.

Яңа форманы кертү белән бергә гамәлдәге процедура да камилләштерелгән. Ике формада да (фикер алышулар/тыңлаулар) проектлар кайсы территориягә кагылышлы әзерләнгән, шул территориядә даими яшәүче гражданнар гына, җир кишәрлекләренә/капиталь төзелеш объектларына (алардагы урыннарга) хокук ияләре генә катнаша ала. Процедураларның икесендә дә катнашучыларны идентификацияләү каралган.

Фикер алышулар/тыңлаулар үткәрү тәртибе, аерым алганда, хәбәр итүне, проект экспозициясен Интернетка урнаштыруны, экспозициягә килүчеләргә консультацияләр бирүне, катнашучыларның проект буенча тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр кертүен, аларны карауны, фикер алышулар/тыңлаулар беркетмәләрен төзүне һәм аларның нәтиҗәләре буенча бәяләмә язуны үз эченә ала.

**«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» Федераль законның 14 һәм 14.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Җирле үзидарә органнарына муниципаль милеккә караган начар хәлдәге мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләве тәртибен мөстәкыйль билгеләү хокукы бирелә.

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерелде, аларда исә РФ субъекты дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә җирле үзидарә органнарының милек белән идарә итү вәкаләтләрен кертү рөхсәт ителми һәм муниципаль мөлкәткә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү мәсьәләләрендә РФ Конституциясе һәм аның нигезендә кабул ителә торган җирле үзидарә органнары актлары нигезендә җирле үзидарә органнарының мөстәкыйль булуы билгеләнә.

**«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау җирле вәкиллекле органнарның махсус компетенциясенә кертелде.

Кагыйдәләрдә төзекләндерүгә, аның өлешләренә карата таләпләр, чаралар исемлеге, аларны үткәрү тәртибе һәм ешлыгы күрсәтелгән булырга тиеш. Төбәк законнарында, муниципаль берәмлекләрнең табигате-климаты, географик, социаль-икътисадый һәм башка үзенчәлекләре нинди булуга карап, кагыйдәләр белән җайга салына торган башка мәсьәләләр каралырга тиеш.

Федераль әһәмияттәге шәһәрләрдә төзекләндерү кагыйдәләре аларның законнарына ярашлы рәвештә раслана. РФ Шәһәр төзелеше кодексында «территорияне төзекләндерү», «янәшәдәге территория», «төзекләндерү өлешләре» төшенчәләре билгеләнгән. Бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы зат (җир кишәрлекләре төзелмәгән яки җир кишәрлекләре аларда салынган йортларның чикләренә туры китереп төзелгән җир кишәрлекләрендәге күпфатирлы йортлардагы урыннарның законлы хуҗаларыннан тыш), төзекләндерүнең җирле кагыйдәләренә туры китереп, янәшәдәге территорияләрне тәртиптә тотуда катнашырга тиеш (шул исәптән финанс ягыннан).

**«Россия Федерациясе Урман кодексына, урман кишәрлекләрен биреп һәм бирмичә, урманнардан файдалану тәртибен камилләштерү өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 471-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Урман утыртмаларын сату-алу, дәүләт һәм муниципаль урман кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзү хокукына торглар оештыру тәртибе камилләштерелде. Дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге урман кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына йә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрү турында карар дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан, шул исәптән гражданнарның һәм юридик затларның гаризалары буенча кабул ителә. Мондый гариза кәгазьгә язылган рәвештә яки гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелә. Гариза алынган очракта, аукцион үткәрү турында карар бер ай эчендә кабул ителә, һәм ул аны кабул иткән орган сайтына урнаштырыла. Аукцион үткәрелү турында мәгълүмат torgi.gov.ru сайтында бирелә.

**«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 31 декабрендәге 503-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге вәкаләтләре төгәлләштерелде. Җирле үзидарә органнарына каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарын (мәйданнарын) булдыру һәм тәртиптә тоту, аларны урнаштыру схемаларын төзү һәм аларның реестрын алып бару, экологик тәрбия бирүне оештыру һәм каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә экологик культура булдыру вәкаләтләре бирелә.

Федераль законда шулай ук:

– калдыклар белән эш итүнең территориаль схемасының эчтәлегенә карата куелган таләпләр төгәлләштерелә;

– калдыкларны туплау урыннарына (мәйданнарына) карата таләпләр куела;

– экологик җыемны исәпләп чыгару һәм түләү, шулай ук экологик җыемнан тупланган федераль бюджет акчаларын тоту тәртибе төгәлләштерелә;

– региональ операторларның каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча вәкаләтләре төгәлләштерелә;

– каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә тарифлар билгеләү һәм аларны түләгәндә ташламалар билгеләү кагыйдәләре төгәлләштерелә.

**«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 13 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.**

Өлешле төзелештә катнашучыларның хокукларын яклауның өстәмә механизмнары өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче йорт төзүчеләрнең мәҗбүри күчерелә торган акчалары (кертемнәре) хисабына махсус компенсация фондын («Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясе) төзү аша федераль дәрәҗәдә кертелгән.

Моңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны яки башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча бирелгән дәүләт вәкаләтләре исемлеге төгәлләштерелде.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 19 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.**

Үзгәрешләр АХБ турында ТР кодексында билгеләнгән административ хокук бозуларның кайберләренә карата административ җәза чараларын йомшартуны күз алдында тота.

Шулай итеп, гражданнар, вазыйфаи затлар, юридик затлар тарафыннан җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү, урамда сатуны оештыру тәртибен бозу яки муниципаль төзекләндерү кагыйдәләрен, муниципаль калдыклар белән эш итү кагыйдәләрен бозу кебек гамәлләр кылынган очракта, хәзер аларга җәзаны кисәтү рәвешендә билгеләү мөмкинлеге каралган.

АХБ турында РФ кодексында билгеләнгәнчә, кисәтү – физик яки юридик затка рәсми шелтә белдерүдән гыйбарәт административ җәза чарасы ул.

Тәүге тапкыр кылынган административ хокук бозу өчен кисәтү кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә, хайваннар һәм үсемлек дөньясы объектларына, әйләнә-тирә мохиткә, РФ халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкарьләргә), дәүләт иминлегенә зыян китерелмәгәндә яисә зыян килү куркынычы барлыкка килмәгәндә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл куркынычы яна-

маганда, шулай ук мөлкәткә зыян килмәгәндә билгеләнә.

**Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасының берничә муниципаль районы, шәһәр округы территориясендә гавами чаралар уздыруны килештерү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 18 октябрендәге 01-02/125 номерлы боерыгы.**

Татарстан Республикасының берничә муниципаль районы, шәһәр округы территориясендә гавами чара уздыруны килештерү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү тәртибе һәм стандарты билгеләнә.

Хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар – юридик һәм физик затлар. Дәүләт хезмәтен ТР Юстиция министрлыгы күрсәтә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә гавами чараны уздыруны килештерү йә аны килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителә, ул юстиция министры күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелә. Дәүләт хезмәте гавами чара уздыру турында хәбәрнамә алынган көннән алып өч эш көне эчендә күрсәтелә. Федераль закон таләпләре һәм хәбәр итү тәртибе бозылу ачыкланса, сроклар күчерелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның, шулай ук хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була торган шартларның тулы исемлеге бирелгән.

Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә.

Хәбәрнамә һәм документлар (документларның күчермәләре) Юстиция министрлыгына квалификацияләнгән электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, аларны башкару эзлеклелеге һәм сроклары, аларны башкару тәртибенә карата таләпләр регламентлаштырылган.

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр), табылган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә гавами чаралар уздыру тәртибен раслау турында» ТР Министрлар Кабинетының 2013 елның 4 декабрендәге 953 номерлы карары белән расланган Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр), табылган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә гавами чаралар уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 25 гыйнварындагы 37 номерлы карары.**

Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) территорияләрендә дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутаты, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тарафыннан гавами чара уздырылу турында дәүләт органнарына хәбәр итү тәртибе һәм сроклары беркетелгән.

Депутат үзенең эшчәнлеге турында сайлаучыларга мәгълүмат бирү максатларында мондый чараны (ялгыз пикетлардан тыш) уздыруы хакында хәбәрнамәне аны уздыру көненә кадәр иң күбе ун көн кала һәм иң азы биш көн кала тапшыра.

Гавами чараның максаты фикерләрне иректә белдерүдән һәм аларны булдырудан, илнең сәяси, икътисадый, социаль һәм мәдәни тормышындагы төрле мәсьәләләр һәм тышкы сәясәт мәсьәләләре буенча таләпләр куюдан яки сайлаучыларга үзенең эшчәнлеге турында мәгълүмат бирүдән гыйбарәт.

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү турында үтенеч формасын һәм аның белән бергә бирелә торган документлар составын раслау хакында» ТР Министрлар Кабинетының 2006 елның 25 октябрендәге 523 номерлы карары белән расланган җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү турында үтенеч формасын һәм аның белән бергә бирелә торган документлар составына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 29 гыйнварындагы 49 номерлы карары.**

Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү турында үтенеч белән бергә тапшырыла торган документларның исемлеге төгәлләштерелгән.

Шулай итеп, сорала торган җир кишәрлегендә федераль әһәмияттәге объектларны (федераль транспорт, оборона һәм куркынычсызлык, энергетика, югары белем бирү һәм сәламәтлек саклау кебек өлкәләрдә), җирле әһәмияттәге объектларны, республика әһәмиятендәге объектларны урнаштыру фаразы территориаль планлаштыруның расланган документларына туры килгән очракта, җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчергәндә муниципаль берәмлекнең эш башкару-бүлү органы белән килештерелергә тиеш.

Килештерү кәгазе белән бергә тиешле дәрәҗәдәге территориаль планлаштыруның расланган документыннан шартлы билгеләр, сорала торган җир кишәрлегенең чикләре күрсәтелеп төшерелгән күчермәсе бирелә, ул вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзаланган булырга тиеш.



# АСК өстенлекләре








Агросәнәгать комплексы хезмәткәрләренә, авыл хуҗалыгы предприятиеләре, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп, ТР Президенты аларның игътибарын төп бурычны үтәүгә – алда торган чәчү кампаниясен уңышлы үткәрүгә юнәлтте. Чыннан да, күптән түгел генә уңыш җыю тәгәлләнгән иде, инде офыкта яз күренә. Чәчү алдының соңгы айлары техниканы, орлык фондын әзерләүгә һәм башка шундый зарури эшләргә багышлана. АСКларның узган елгы эш нәтиҗәләре һәм бу елга куелган бурычлары ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясенең 14 февральдә узган йомгаклау утырышында каралды.

Рөстәм Миңнеханов тармакның рентабельлелеген күтәрү кирәклегенә игътибар итте. «Киң күләмле җитештерү өчен рентабельлелек 10 процент түгел, 15–20 процент булырга тиеш. Моның өчен хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү өстендә эшләргә кирәк, ә бу квалификацияле белгечләр булуын таләп итә». Татарстан терлекчелек тармагын үстерүгә аерым әһәмият бирә, дип дәвам итте республика башлыгы. 2020 елга сөт җитештерүне – 2 млн тоннага, ә ит җитештерүне 600 мең тоннага кадәр арттыру бурычы куелды. Мондый нәтиҗәгә интенсив рәвештә заманча терлекчелек комплекслары төзү һәм югары продуктлылыклы терлекләр өлешен арттыру аша ирешергә мөмкин.

Шул ук вакытта, ТР Президенты белдерүенчә, узган ел нәтиҗәләре буенча 18 район мөгезле эре терлекләрнең баш санын киметүгә юл куйган. Болар: Мөслим, Арча, Түбән Кама һәм тагын кайбер районнар. Минзәлә, Кама Тамагы, Тукай һәм Арча районнарында сөт саву күләменең кимүе күзәтелгән. «Әгәр сез бу мәсьәләләр белән кызыксынмасагыз, авыл хуҗалыгы оешмалары белән тыгыз хезмәттәшлек итмәсәгез – файда булмаячак», – дип кисәтте аутсайдер районнарның башлыкларын Рөстәм Миңнеханов.

Президент республикада әле ун ел гына элегрәк һәр 100 хуҗалыкка 54 сыер туры килсә, бүген баш санының нибары 21 гә генә калуына (2,5 тапкыр кимрәк) басым ясап белдерде. «Хуҗалык итүнең кече формалары линиясе буенча зур эш алып барыла, зона киңәшмәләре уздырыла, без ярдәм күрсәтү чараларын табабыз. Тик иң мөһиме – урыннарда эшләү».

ТР Президенты сөт эшкәртүне, үсемлекчелекне үстерү өлкәсендәге бурычларны билгеләде. Коллегиядә катнашучылар үсемлекчелек продукциясен тирән эшкәртү күләмен арттыру, авыл хуҗалыгы предприятиеләренә яшь белгечләрне җәлеп итү, куллану кооперациясе системасын үстерү белән бәйле мәсьәләләрне һәм бүгенге көндә тармакны борчый торган башка проблемаларны тикшерделәр.

Фотолар tatarstan.ru сайтыннан алынды.


Сельхозпредприятие
Мощность
Азнакаевский
ООО "Союз Агро"
3800 (III оч. на 900 г.)
Алексеевский
НП "Алексеевское"
3000
К-з "Алга"
800
ООО "Тукаевское"
1200
Атнинский
ООО "Дусым"
510
СХПК "Тан"
1000
Мамадышский
ООО "АПК "Продпрограмма"
2400
Алькеевский
ООО "Хузангаевское"
2400
Альметьевский
ОАО им. Токарликова
1070
Черемшанский
ООО "Ильхан"
1000
Кукморский
СХПК "Урал"
600
Всего 11 объектов на 17.8 тыс.гол. молочного скота














# *Татарстан муниципаллары журналы*







**Язылу индекслары:**

**П2268**
**татар телендә**

**П2258**
**рус телендә**

**Журналга барлык элемтә бүлекләрендә язылырга була**